PRESSA

1926—1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2019 АПРЕЛЬ № 4

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ӘНИ ДӘ, ӘТИ ДӘ
ир бала янында әти булмаса

ХЫЯНӘТ
хисләргә киртә бармы

«ЯКУТ» МУЕНСА
үзебез ясап карыйк

Гөлнара ЯРУЛЛИНА:

ТУГАН ТЕЛ ЕРАКТА КАДЕРЛЕРӘК...

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә...
...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза!
Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Равил ФӘЙЗУЛЛИН

* * *

Матурлар күп.
Тик алар
кереп югалалар тыкрыкларга,
күмеләләр куаклар артында,
калалар тукталышларда,
утырып китәләр йә...

Ә син минем
гел янымда! –
Һәрчак үзем белән!

Матурлар күп.
Ә син –
матурларның иң матуры.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Миңлебикә Фәйзуллина (шагыйрә Бикә Рәхимова). 1965 ел.
10 апрельдә Бикә РӘХИМОВАның туусына – 80 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

04’2019



Фото: Ксения Богданова

Баш мөхәррир өчен
Л.Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова

Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина

Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Гөлнара Ярullина
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова

Фотокорреспондент
Анна Арахамия

Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева

Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 28.03.2019 ел
Заказ О-842
Тираж 5453

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002









Фото: Ксения Богданова

Фәннур САФИН

Яз килә

Йөгерә-йөгерә буран эзләреннән,
Гөрләвекләр булып яз килә.
Һаваларны иңләп, кырлар тулып
Шатлык килә җиргә, наз килә.

Һавалардан аңкый яшен исе,
Урман исе, чәчәк исләре.
Язга күкрәк ачкан болын төсле,
Яшәрә җан, йөрәк хисләре...

Бар дөньяны тутырып көләсең, яз,
Сүнмәс ал таң булып көләсең.
Бәхет кенә кирәк миңа бүген,
Ни бәхетләр алып киләсең?

Безнең тышлыкта



«Без, татар яшьләре, хыялларны чынга ашырабыз.»



30
Мәскәү татарча сөйләшә
Эльмира Закирова

Заман һәм без



6
Татар Конституциясе
Чулпан Галиәхмәтова

Үткәннәр кала хәтердә... 10
Рәмзия Зарипова



Әни дә, әти дә 14
Чулпан Галиәхмәтова

18
«Минем хобби – язмышлар»
Фирая Бәдретдинованың тормыш кагыйдәләре
Эльмира Закирова әзерләде

Татар дөньясы

– Татар феминизмы...
– Милләт аналары? 26
Ландыш Әбүдәрова




34 Сөендереп яшик әле!
Ландыш Әбүдәрова

Мәдәни тормыш



40 Сары роза
О. Генри

Яшәеш



46 «Әни җырлап китте...»
Гөлнур Сафиуллина



50 Мәңгелек туң илендә
Алсу Хәлимова

Хатын-кыз галәме



58 Чыхыртма – азәрбайҗан ашы



62 Күләгә гөле

»





« Мин дип сөйләшик, МИН һәм без дип. Сез дип түгел. »

Фото: Анна Арахамия

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

ТАТАР КОНСТИТУЦИЯСЕ

Нәрсә кирәген белеп яшәгәннәр морадына тиз ирешә, зур үрләр яулый. Бүгенге көн хакында гына уйлап яшәгәннәр, нигездә, мәсәлдәге энә карагы хәлендә кала. Хәзерге глобальләшү заманында йотылып, югалып калмас өчен безгә дә тупланырга вакыт җитте кебек. Себерке сындырып карарга киңәш иткән әкияттәге зирәк картны искә төшерү дә җитә... Бурычны үз алдыңа гына түгел, милләт алдына кую да зарур. Аны үтәү өчен үзеннән-үзе берләшәсең, кулга-кул тотынасың. Россиянең яңа тарихында татарларны Татарстан Республикасының суверенитетлы булуы рухландырып торды. Тик соңгы вакытта искән сәясәт җилләре суверенитетны да, шартнамәне дә, хәтта мәктәпләрдә татар теле дәресләрен дә «очыртып» алып китте бездән. «Бетәбез» дип яшәргә яраткан татарлар, монысы инде чын бетү дип кабул итеп, хафага төште. Хәтта чаң суга башладылар.
Юк, бетмибез икән әле! Чүгелә башлаган тезне әкрен генә турайту юлында икән бит без. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов узган елгы парламентка юлламасында татар халкының үсеш стратегиясен булдыру идеясе белән чыкты. Бу эш Бөтендөнья татар конгрессына йөкләнде. Бер төркем зыялылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре җиң сызганып эшкә алынды. Мондый хәлнең булганы юк иде әле. Тирән тарихлы, бай мәдәниятле, сәяси аренада үз сүзен әйтә алган, чит илләрдә үзен таныткан татарның үсеш стратегиясе моңа кадәр язылмады. Бу – тарихи вакыйга! Һәм ул бик кирәк иде. Ел башыннан бирле Россиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарларга стратегия эскизын тәкъдим итәләр. Дөнья буйлап та тәкъдимнәр җыела. Чит төбәкләрдәге халык, бәйрәм үткәрү өчен генә түгел, милләт язмышын хәл итү өчен дә җыелып фикерләшә ала икән бит.
Бу – үзе үк берләшүгә юл. Стратегия 2050 елга кадәр төзелә. Ул мөһим документ булып, һәр татарның кыйбласына әйләнеп, «юл карта»лары төзелеп, аны югарыдагылар (балыкның башы да шулар бит!) хөрмәт итсә, милләт өчен олуг эшләр башкарылса, бу – татарларның яңа гасырдагы күтәрелеше, гади итеп әйткәндә, яңадан тууы булачак. Әгәр дә инде хисап өчен генә ясалган чираттагы документ булып, тузан җыеп ятса, стратегия эшләмәсә, аңа бармак аша гына карасалар, гафу итегез, бу инде – «бетәбез» юлында баруның төп расламасы. Һәм ул һәр татарның намусына кара тап булып ятачак. Әлегә исә якты хыяллар белән яшибез. Стратегия кабул ителү белән татарлар өчен кояш икенче яктан чыга башламас, билгеле, чөнки аны гамәлгә ашыру һәрберебезгә йөкләнә. Әйткәнемчә, бергәлектә генә көч! Бик тырышса да, чын федерализмга барып җитә алмаган Россия хакимиятендә башка милләтләргә карата язгы җылы җилләр исүе якын елларда гына көтелми кебек. Үзебезгә үзебез булышмасак, безгә кем булышыр?! «Сез түгел, без дип сөйләшергә кирәк», – ди Татарстан Республикасының премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисе **Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ**. Бу эшне милләт белән тотынганда гына башкарып булачагына өмет баглый ул. Уйланулары да әнә шул хакта...

Татар кешесе – милләте өчен янып, милләте белән горурланып яши. Россиядә 193 мең милләт бар. Татар халкының – дөньяда үз лаеклы урыны. Тарихы, шәхесләре, дине... Иң мөһиме: бүгенге көндә тамырларыңны югалтмаска кирәк. Татарча белми, нинди татар булсын ул дип әйтү дә дөрес булмас. Рух бар бит әле! Татарларны аеру түгел, берләштерү зарур.

Үз вакытында Татарстан моделе Россия белән хезмәттәшлектә, бәйләнешләрдә үрнәк булды. Ул чорда халкыбыз бердәмлектә сыналды. Татар халкын саклап калу, берләштерү максатыннан Бөтендөнья татар конгрессы төзелде. **27 ел дәверендә берничә мәртәбә татар милләтенең үсеш стратегиясен булдыруга омтылып карадык. Аны язу буенча да, эшләү буенча да төрле проектлар булды. Тик алар бер генә өлкәгә кагылышлы иде: мәгариф белән мәдәниятне генә яктырттылар.** Кызганыч, төрле юнәлешләрне күздә тотып, нигезләп эшләнгәне булмады. Ел ярым элек шушы вазыйфага сайлаганда, конгресс эшчәнлегенең стратегиясен булдыру зарурлыгын әйткән идем, ә Татарстан Президенты тагын да зуррак бурыч куйды: татар халкының үсеш стратегиясе булырга тиеш диде ул.

Татар милләтен саклап калу турында сүз бармый, без үсеш стратегиясе язабыз. Әгәр дә саклап калу хакында гына сөйләшсәк, иртәгәсе көн турында инде уйлый алмыйбыз дигән сүз бу. Бүген көн үтсә, ни буласын иртәгә карарбыз әле дип яшәү дөрес түгел.

Стратегияне тәкъдим иткән чакта һәрвакыт әйтәм: **«Мин дип сөйләшик, мин һәм без дип. Сез дип түгел».** Россиядә 5 миллион 300 мең татар яши. Алар барысы да «Мин – татар» дип яши икән, тагын нәрсә кирәк инде?!

Узган ел декабрьдә Россия Президенты Владимир Путин да Дәүләт милли сәясәте стратегиясенә кергән үзгәрешләрне имзалады. Безнең туып кына килгән стратегияне ул йотмасмы дигән шөбһәле фикерләр, икеләнүләр ишетелә башлады. **Бүредән курыксагыз, урманга бармагыз. Эшне бервакытта да куркып башларга ярамый**.

Стратегияне язганда авылга яки шәһәргә игътибар күбрәк бирелергә тиеш дигән бурыч куелмады. Кулдагы биш бармакның кайсын тешләсәң дә, үзәк өзелә. Татар халкы кайда гына яшәсә дә, тормышкөнкүреше өчен уңайлы шартлар булдыру мөһим. Саннар менә нәрсә сөйли: 1920 елда Татарстанда 2 миллион 900 мең кеше яшәгән. Бүгенге көндә – 3 миллион 900 мең. Йөз ел эчендә бер миллионга арттканбыз. 1920 елда халыкның 86 проценты авылда яшәсә, хәзер ул сан 76 процент тәшкил итә. Безнең өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә проблема: авылда яшәргә теләүчеләр саны сизелерлек кими. Барыбызның уңайлы шартларда көн итәсе килә. Хәзер инде авыллар-



да да бөтен уңайлыклар өйдә. Ләкин авыл җирендә эшләргә кирәк! 24 сәгать буе! Чөнки төп бурычы шул.

Авыл – татар халкының моң бишеге дигән гыйбарәне хупламыйм да, кире дә какмыйм. Хәзер авыл моннан 30, 40 яки 70 ел элек булган функцияне алып бара алмый. Монысын да аңларга кирәк. Без кечкенә чакта каникулга кайткан шәһәр балаларын ике айда татарлаштыра идек. Бүген андый потенциал юк. Хәзер оныклар әбиләрен урыслаштырып китә. Ләкин авыл яши. Аның – үз тормышы.

Татарча укырга шартлар бар, тик алар уңайлы түгел дип әйтәләр. Болай әйтмәс өчен иң элек әти-әнинең баласын татар телендә укытасы килү теләге булырга тиеш. Мин, мәсәлән, мәктәпкә алты чакрым җәяү йөреп укыдым. Монда барысы да теләктән тора. Башта биш чакрымны ерак диярләр, аннан бер чакрым, 500 метр да ерак тоелыр. Соңыннан подъездддан чыгып торасылары килмәс, өйгә килеп укытсалар яхшырак булыр иде дип әйтә башларлар. Уңай шартлар дигәндә, мөмкинлекне күз алдында тотарга кирәк.

Татар булып калуны иң элек гаилә саклый дигән фикердә мин. Мәсәлән, егет белән кыз очрашып йөриләр, ди. Син өйләнәсе (кияүгә чыгасы) кеше татарча беләме? Гаиләдә әти-әнисе белән татарча сөйләшәме? Ләкин мәхәббәт башны әйләндергән вакытта бу хакта бөтенләй уйламыйсың, игътибар итмисең. Соңыннан туй, никах... Аларның нинди телдә узуы да бик мөһим бит. Бергә яши башлыйлар. Әле бит бала тусын өчен тугыз ай көтәргә кирәк. Алар шул вакытта бер-берсе белән татарча сөйләшәме? Бала тугач аңа нинди телдә эндәшәләр? Балага 3 яшь тулганчы дәүләт берничек тә кысылмый. Әгәр дә без шушы вакытта аның белән татарча сөйләшсәк, рухы нык булачак. Ә шартлар җитәрлек хәзер: татарча театрлар, мультфильмнар, китаплар...

Иртән «әни» дип киткән балаң, балалар бакчасыннан «мама» дип кайта икән, балага ияреп китмәү мөһим! Тик ата-аналар, баланы интектермик инде, фикерләрен чуалтмыйк, дип, бер генә телдә сөйләшергә тырыша. Бу һич дөрес түгел, чөнки чит илләрдә 3-4 яшьлек балалар берничә тел белә. Кешенең баш мие шундый зур мөмкинлекләргә ия. Без балаларга ияребез икән, көндәлек сөйләшүебездән туган телебез төшеп калачак. Барысы да үзебездән тора. Ә без һәрвакыт сәбәп эзлибез. Гаеп урамда, мәктәптә, дәүләттә... бары үзебездә генә түгел.

Карагыз, кайбер гаиләләр урамда ничек матур итеп татарча сөйләшеп йөри. Аларга бит дәүләт күрсәтмә бирми, аларның ул йөрәктән чыга. Башкача сөйләшүне күз алдына да китерә алмыйлар, кирәк дип тә тапмыйлар. **60, 70 яшьтә дә матур булып калу өчен чарасын яшьтән үк күрә башлыйсың бит. Туган тел белән дә шулай. Бик аңлыйм, авыр бу.**

Милләтнең киләчәге әниләр кулында, булачак стратегиядә ник аларга тиешле урын бирелмәгән дип әйтүчеләр бар. Без бит гаилә диюгә хатын-кызны күз алдына китерәбез. Туйда да егеткә казның башын, кәләшкә муенын тоттыралар. Муен кая борса, баш шул якка борыла.

Стратегиягә карата бик күп тәкъдимнәр килә. Араларында бердәм дәүләт имтиханын татарча бирү мөмкинлеген булдыруны сораучылар да очрый. **Федераль канун бар. Риза булсак та, булмасак та, аның буенча яшибез. Дөрес, татар халкының мәкален дә онытмыйк – «өметсез шайтан гына», диләр.** Шулай да саннарга карыйк. Бүгенге көндә республикада 9 нчы сыйныфны тәмамлаган укучыларның 40 проценты гына 10 нчы сыйныфка бара. Калганнары урта һөнәри белем бирү уку йортларына китә. Аларга югары белемне бердәм дәүләт имтиханнарыннан тыш кына алырга мөмкинлек туа. Татарстан халкының 53 проценты татар, дип әйтәбез. Димәк, 40 процентның яртысы гына татар баласы. Глобаль проблема дип карыйбыз, ләкин ул күп кешегә кирәк түгел икән.

Стратегиядә милли кадрлар хакында да сүз бар. Аларны бары тик милли университет кына әзерли ала. Халкыбыз алга барсын өчен бар өлкәдә дә милли кадрлар кирәк, әлбәттә. Алар булмаса, без милләтне үзебез теләгәнчә саклый алмаячакбыз. Милли Шура, билгеле, университетлар ача алмый. Без бу фикерне җиткерәбез, ә хөкүмәт ягы безне ишетергә тиеш. Татар университеты оештыру өчен республиканың сәяси ихтыяри көче җитәчәк. Иң мөһиме – канупнар комачау итми. Стратегияне кабул итик, аннан соң күз күрер. Без бу җәһәттән параллель эшне инде алып барабыз.

Стратегиядә милләтне алга алып бару өчен интернет киңлекләре ресурсларын куллануга да исәп тотыла. Хәзерге заманда яшьләр өчен иң кызыклы урын. Ул инде яшәү рәвешенә әйләнеп бара... Виртуаль тормышка. Анда уку-сызу гына түгел, төрле татарча кушымталар, тулы куәтенә эшләүче татар телендәге Википедия, шул ук тәрҗемәләр булырга тиеш. Лаеклы урын алмасак, анда яшьләр булмаячак.

Стратегия күпме булырга тиеш: 100 битлеме, 500 битлеме? Инде бер алынгач, томлап язылык дигән фикерләр дә бар. Тик хәзер халык күләмле әйберләр укымый. Кыскалык эзли. Шуңа күрә стратегия 40–50 биткә сыеп бетәргә тиеш. Ә менә соңыннан ясаласы «юл картасы» бер мең битле дә була ала. **Стратегия – ул үзаңны үстерү өчен юнәлеш күрсәтү.**

«Юл картасы» ясау өчен муниципалитетлар, министрлыклар, автономияләр җәлеп ителәчәк. **Әлегә акча хакында уйламыйбыз. Без яшь балалар кебек.**

Алар да бит акча турында уйламый, чөнки ата-анасы тәэмин итә. Безнең дә бюджет бар, татар балалар бакчасы бар, татар мәктәпләре, мәдәният сарайлары, театрлар, милли басмалар бар. Бөтенесе дә бер механизм кебек эшли. Ә акча бар, каралган инде ул.

Стратегияне тәкъдим итүне Арчадан башладык һәм 2050 елда шунда ук җыелышып, нәтиҗәләр хакында сөйләшәчәкбез дип килештек. **Ә ул очрашуда бер гаиләдән дүрт буын катнашырга тиеш. Димәк, дүрт буын «мин – татар» дип яши икән, бу милләтнең үсүе хакында сөйли.**

Зур теләгебез: стратегияне кабул итеп, бастырып чыгаргач, ул һәр татар гаиләсе өстәлендә ятсын, горурлык тудырсын, көндәлек кебек булсын иде.

Татар теле ул кухня белән урам теле түгел, ул – дәүләт теле. Стратегияне язуның да үз законнары бар. Ул фәнни телдә булырга тиеш. Шуңа кайбер урыннары аңлашылып та бетмидер. **Кабул иткәннән соң, аңлатмалар белән язарга уйлыйбыз.** Һәр гади кеше төшенерлек итеп.

Татар элитасы бар, ләкин ул тупланмаган. Стратегия ярдәмендә аларны бергә җыеп булыр дип өметләнәм. Элита дигәндә Forbesны күз алдына китерергә кирәкми. Аларга бөек шәхесләр дә, үрнәк гаиләләр дә кирә.

Стратегия кабул итү нәрсә бирәме? Татар алга барачак. Милләт булып сакланып калачак. **Безнең төп бурыч – арту! Сан буенча гына түгел, рух буенча да.** Урамда татарча сөйләшеп йөриләр икән, бу, минемчә, милләт саклану дигән сүз.

Кабул ителгән стратегия законга нигезләнергә тиеш. Шуңа күрә тузга язмаган, закон боза торган тәкъдимнәр бар икән, аларны карап та тормыйбыз. **Без бернәрсә дә уйлап чыгармадык. Бары тик ничә еллар буе хыялланып йөргән, үзебез игълан иткән теләкләрне бергә җыйдык. Кайберәүләр стратегия кабул ителә дә, могҗиза булачак дип уйлый. Могҗиза безнең күңелдә булырга тиеш.** Кабул ителгән стратегия ул татарларны рухландырырга, шул ук вакытта мөмкинлек тә бирергә, алар алдына бурыч та куярга тиеш.

Һәрберебез үзенә шундый бурыч алсын: татар дөньясында татар халкы татарча сөйләшергә тиеш. Халыкны уятырга кирәк! Үзебез сөйләшмәсәк, башка милләт кешеләре килеп, безне татарча сөйләшергә өйрәтмәячәк. **Бөтен нәрсә МИНнән башлана. Ләкин «мин» булу бик авыр, чөнки без һәрвакыт уңайлылыкка омтылабыз.** Кешенең асылы шундый: ул һәрвакыт җиңеллек эзли. Ә барысы да җиңел барыр дип беркем вәгъдә бирми.



Фәндәс САФИУЛЛИН, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, 1990–2003 елларда ТР Югары Советы, Дәүләт Советы, РФ Дәүләт Думасы депутаты:

Татар халкының үсеш стратегиясе милләтнең данлыклы киләчәген билгели торган бөек тарихи документ булсын иде. Минем фикеремчә, аның төп максаты татар халкының үлемсезлегенә ирешү булырга тиеш. Әгәр Милли стратегия татарны алдынгы халыклар дәрәҗәсенә күтәрү максатын иң югары тарихи бурыч итеп куеп, халыкта шуңа омтылыш уята алса, стратегик план китапханә киштәләрендә генә калса да җитә. Халыкның яшәеш мәгънәсенә әверелгән рухи омтылышына инде планнар төзеп торуның кирәге калмый. Стратегиядә, кызганыч, бүгенге хәлебезгә анализ һәм диагноз юк. Совет чорыннан исән калган һәм 90 нчы елларда ачылган татар мәктәпләребез русча укытуга күчәргә мәҗбүр. Бердәм дәүләт имтиханнары рус телендә генә булгач, татар балаларын туган теленнән баш тартырга этәрү, туган теле итеп рус телен сайларга мәҗбүр итү дигән сүз бу. Үз дәүләте, үз милли вазгыяте булмаган халыкның мәктәбе бетсә, теле дә бетә; теле бетсә – халык үзе дә милләт буларак юкка чыга.

Милли стратегиябезнең тагын бер җитешсезлеге – аны әзерләүне һәм тормышка ашыруны иҗтимагый оешмаларга гына йөкләү. Бөтен Татарстан, халык, барлык хакимият органнары милләтне саклап калу һәм үстерү бурычын үз өсләренә алмаса, ул ниятебез матур итеп язылып, кәгазьдә генә калачак.

Күпмилләтле илдә тел проблемасы – ул, әлбәттә, сәясәт. Татар телен саклап калуны гаиләгә генә йөкләп калдырырга ярамый. Сүз дә юк, гаилә – телнең нигезе. Ләкин туган тел университетлар дәрәҗәсендәге фән, югары мәдәният һәм әдәбият, сәясәт – тормышның төрле өлкәләрендә идарә итү теле булганда гына сакланып кала ала.

Тарихи һәм сәяси вазгыять шулай килеп чыкты: туган телебезне, халкыбызны милләт буларак саклап калуның иң җаваплы, иң авыр проблемасын хәл итү бүгенге буынга йөкләнде. Вакыт ашыктыра. Аны киләчәк буыннарга калдыру инде соң булырга да мөмкин...






ҮТКӘННӘР КАЛА ХӘТЕРДӘ...

Әгерҗедән 120 чакрым ераклыктагы Нарат авылына барганда эчтән генә гел бер җыр көйләдем:
Юллар, юллар, авыр булса булсын,
Тик соңгысы гына булмасын...

Рәмзия
ЗАРИПОВА

...Беренче тапкыр Наратка шушы җырның авторы, күренекле якташыбыз Ләбиб Айтугановның туган нигезен эзләп 1980 нче елларда килгән идем. Авыл урамында очраган абзыйдан бу йортка юлны күрсәтүен сорагач:

– Әрибә апаның «штаб-квартирасы» менә шушы инде. Авылга кем килсә дә, язучымы, журналистмы, энесе Ләбибне белгән артистмы – барысы да иң беренче шушы йортка юл тота. Әрибә апаның белмәгәне юк. Наратның һәр кешесенең нәселнәсәбе турында сәгатьләр буе сөйли ала, – диде.

Бу «штаб-квартира»ның хуҗабикәсе белән тәүге тапкыр танышканда аңа 60 яшьләр тирәсе иде. Ул чакта Әрибә апа танылган шагыйрь, композитор, Татарстан радиосында эшләгәндә бик яшьли вафат булган энесе Ләбиб турындагы матур истәлекләрне тәфсилләп сөйләп таң калдырган иде...

Менә тагын юллар мине шушы авылга, Ләбиб Айтуганов исеме

Гел халык арасында, халыкны агарту, рухи хәзинәләргә тарту эшендә ул.

ТАССР Празднование 100-летия Татарской АССР Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү 1920-2020

кушылган урамга алып килде. Кызлары Нурзилә һәм Нурсөя тырышлыгы белән төзелгән яңа йортында, 90 яшен тутырып, тыйнак кына көн күреп ята Әрибә апа. 1929 елда әти-әниләре Актаныш районының Иске Бикчәнтәй авылыннан күчеп килгәч, күрше авылдан 1916 елда төзелгән йортны күчереп салганнар. Айтугановлар нәселе турында матур хатирәләр саклый торган әлеге агач йорт бүген дә үз урынында. Гасыр кичергән бу йортны сүтү турында сүз кушарга да кыймыйлар, чөнки, Әрибә апа әйтмешли, үзе үк тарихи мирас бит ул.

Үзем дә уйга калдым: тиздән Татарстан Республикасы оештырылуга 100 ел була. Якынча биш гасыр элек нарат урманы эченә салынган бер татар авылының менә шушы бер йортына да – 100 ел. Кайдадыр еракта заманалар алышынган: үзәк шәһәрләрдә революцияләр кабынган, ерак җирләрдә сугышлар барган, законнар, реформалар чыккан, сәяси көрәшләр кызган, килешүләр төзелгән, үзгәртеп корулар, зур төзелешләр колач алган. Әмма аралар никадәр ерак булмасын, бу вакыйгаларның көчле давыллары Нарат авылына да килеп җитеп, кеше язмышларында, шул исәптән шушы йортта яшәүче гаилә язмышында җуелмас эзләр калдырган.

Әрибә апаның гомер юлы Татарстан күләмендәге тарихи вакыйгаларның аерым кешеләр язмышында чагылышын ачык күрсәтеп тора. Ул да шушы вакыйгаларның шаһиты гына түгел, аларда катнашучы да дияр идем. Шушы авылның тормышын, халкының гореф-гадәтләрен, рухи-әхлакый кыйммәтләрен сакларга тырышып, аларны замана үзгәрешләренә җайлап коручы-оештыручыларның берсе ул.

– Синең үзеңне дә Наратның тарихы, энциклопедиясе диләр бит, – дип сүземне башлыйм.

– Бәләкәй чактан ук әби-бабайларның узган заманнар турында сөйләгәннәрен тыңлап тору кызык иде безгә. Үсә төшкәч, моңа аңлы рәвештә керештем. Авыл мәктәбе укытучысы Галимә апа Закирова белән 1967 елда, революциянең 50 еллыгына кулдан язып альбом эшләдек. Шуннан бирле авылда булган бар нәрсәне теркәп бару гадәтемә керде. Шул язмаларымны тәртипкә китереп, авыл тарихын яздым. Китап инде әзер диярлек, бизәлеш ягын эшлибез, – дип шаккаттырды мине Әрибә апа.

Унынчы дистәсен ваклаучы гап-гади авыл апасының мондый гаять катлаулы, җаваплы эшкә алынуына, тәвәккәллегенә, авыл вакыйгалары турында бүген дә көнен-елын, авыл кешеләренең исемен-нәселен төгәл атап сөйләвенә исең китәр. Сөбханалла, дип әйтергә генә кала.

«Республиканың 100 еллык тарихы – ул һәркайсыбызның тарихы. Безнең Нарат кебек кечкенә авыллардан туплана инде ул. Китапта үзем гомер буе җыйган мәгълүмат урын алды. Бөтен авыл буйлап фоторәсемнәр җыйдык. Билгеле, бу эшем күбрәк авылдашларым өчен, тик шунысы да бар: бәлки кемнәрдер үз авыллары турында язарга рухланыр», – ди Әрибә апа.

Әрибә апаның шулкадәр сәләтле, гыйлем иясе булуы, зыялылык сыйфатлары кайдан килгән соң? Указлы мулла нәселенең затлы бер кызы икән бит ул! Әткәсе Мөхәмммәткәрам – борынгы муллалар нәселенең 26 нчы буыны. Әнкәсе Әминә дә – мулла кызы. Яшь мулла Мөхәмммәткәрамны Нарат авылына мулла итеп чакыргач, аны алып кайтырга җигүле ун ат җибәрәләр. Мулла белән абыстайның бар мөлкәте ике ат чанасына сыеп беткәч, гаҗәпкә калалар. Кулларында өч бала: Нәкыйп, Ягъсуб, иң кечесе – өч айлык Әрибә. Нарат авылына күчкәч, тагын ике бала – Әдилә һәм Ләбиб дөньяга килә.

Тиздән авылга 30 нчы еллар шаукымы килеп ирешә. Иң зур гаеп, әлбәттә, социализм өчен чит элемент – муллага төшә.

– Бай муллалар нәселеннән икән дип уйласагыз, бик ялгышасыз. Безнең әткәй дин юлын аңлы рәвештә сайлаган, дингә бирелгән кеше иде. Дингә каршы заманалар башланып, әткәйне кулга алырга килгәч, мулла йортында конфискация ясарлык әйбер тапмаганнар. Әткәйне Казанга алып китеп япканнар. Нарат халкы мулланы шулхәтле хөрмәт иткән, күрәсең, әткәйне төрмәдән чыгаруларын үтенеп хат юллаган. Безнең бәхеткәдер инде, әткәйгә шартлы срок биреп кайтарып җибәргәннәр. Әткәй, кайткач, безнең киләчәк өчен кайгырып, дингә кагылышлы язмаларын мәчеткә кертеп куйды, – дип хәтер йомгагын сүтә Әрибә апа.

Әмма биш баланың әтиле гомере кыска була. Күп тә үтми илгә-көнгә, шул исәптән бу гаиләгә дә Бөек Ватан сугышы фаҗигасе килеп кагыла. Ишле гаилә башлыгы ике улы белән сугышка китә. Өч иргетнең берсе – Нәкыйп абыйлары гына, фронтта бер аягын калдырып, исән кайта. Гаилә өчен җаваплылык авыру әнисенең иң зур таянычы булып калган олы кыз җилкәсенә төшә. Укырга теләге зур була, әмма кая инде авыру әнисен, аның күзенә карап торучы кече туганнарын ташлап калага китү... Сеңлесе Әдилә белән энесе Ләбибне укытып кеше итә, үзенә югары уку йортларында уку бәхете тәтеми. Сугыш елларында 13 яшеннән колхозда эшләүдән башланган хезмәт юлы 56 (!) елга сузыла мулла кызының.

Тарихның тагын бер сәхифәсенә – сугыштан соңгы авыр елларга килеп җиттек... Илне аякка бастыруга Нарат авылы кешеләре дә үз өлешен кертә. Яшь чагында ук нинди генә җаваплы эшләр башкармаган Әрибә апа: заем җыючы, комсомол, аннан – партия оешмасы җитәкчесе, агитатор, пропагандист, лектор, депутат – бушлай җәмәгать эшләре. 1946 елдан – уку йорты (из-

«Мулла кызыннан башка мәчет төзеп булмас дип уйладым», – дип шаярта ул.

бач) мөдире. 1947 елда – 18 яшьтә – депутат, ике авылны берләштергән авыл советы секретаре булып 12 ел эшли. 1960 елдан – клуб, 1966 елдан – китапханә мөдире. Авылның уңган, юмарт, кешеләргә ярдәм кулы сузарга ярата торган агроном егете Нуруллага кияүгә чыккач, яшьлек хыялын өлешчә чынга ашыра: Алабуга мәдәният-агарту училищесын читтән торып тәмамлый.

Китапханәне беренче көннән үк үзе оештыра, фондына 7000 китап җыя. Авылдашлары китапханәдәге китапларны «Әрибә китабы» дип йөртә башлыйлар һәм ул елларны әле дә сагынып искә алалар.

– Китапханәдә озын чират тезелә иде. Әрибә апа өлкәннәрдән дә, балалардан да китапның кыскача эчтәлеген сөйләтмичә яңасын бирми. Ык-мык килеп торсаң, яхшылап укыгач китерерсең, дип, китабыңны кире тоттырып җибәрә. Әдәби китап уку көндәлек эш кебек иде безнең өчен. Китапханәдәге кайсы гына китап турында сорасаң да, шунда ук кызыксындырырлык итеп сөйли башлый ул. Киштәләрдәге җиде меңләп китапны ничек укып өлгерде икән ул дип әле дә аптырыйбыз. Аның да бит җилкәсендә авыл хатынының мең төрле мәшәкатьле гаилә тормышы... Авыл кешесе көн саен диярлек китапханәгә кич утырырга җыела. Әрибә апа ил, республика, район хәлләре белән таныштыра, теге яки бу мөһим вакыйганы җентекләп аңлата. Китап алырга гына түгел, эч серләрен уртаклашырга, гаиләдәге хәлләргә төпле киңәш алырга да Әрибә апа янына килделәр. Аның белән серләшеп-сөйләшеп алганнан соң, күңеленә дәва табасын һәркем белә иде. Ир белән хатынны, егет белән кызны татулаштыручы да ул булды, – дип искә ала ветеран мөгаллимә Халисә апа Хәлиуллина.

Авыл халкы катнашында куелган концерт-кичәләрне, Сабантуйларын, клубтагы бәби туйларын, хезмәт алдынгыларын хөрмәтләү, яшьләрне беренче буразналарына, армиягә озату бәйрәмнәрен, спектакльләрне оештыруда Әрибә апа башлап йөри, клуб мөдирләренә гел ярдәмгә килә. Сценарий язучы да, режиссер да, халыкны сәхнәгә тартучы да була. Басуларда, фермаларда агитбригада белән концертлар кую, халыкара хәлләр турында лекцияләр уку, стена газеталары чыгару... Суд утырышчысы, халык дружиначысы, ревизия ясаучы – санап бетергесез җәмәгать эше алып бара. Барысына да өлгерә, барысына да күңел җылысын сала.

– Әрибә апабызның оештыру сәләте көчле. Бик оста психолог, халык педагогы ул. Шуңа күрә аның «штаб-квартира»сыннан әле дә халык өзелми. Олының да, кеченең дә күңеленә ачкыч таба белә. Шул ук вакытта гомер буе туры сүзле, гадел булды. Колхоз җыелышларында теге яки бу карарны кабул иткәндә халык еш кына колхоз рәисеннән бигрәк, Әрибә апа фикеренә таяна иде. Акны кара димәгәне өчен түрәләр арасында аны өнәп бетермәүчеләр дә аз булмады. Әмма аның белән бар да санлашты, – ди авылның ветеран мөгаллимәсе, Әрибә апа белән бергә авыл тормышында кайнаган елларын искә алып.

Әрибә апа китапханәдә өзлексез 30 ел эшләп пенсиягә чыга да... авылның балалар бакчасында тәрбияче булып тагын сигез ел эшли. Җәмәгать эшләре, әлбәттә, дәвам итә. Чөнки нәкъ шул вакытта үзгәртеп кору чоры башлана, колхозлар таркала... Авыл тормышын яңача коруда да актив катнаша ул.

Хәзерге вакытта да Әрибә апа вакыйгаларга турыдан-туры катнашмаса да, һәрнәрсәдән хәбәрдар, күзәтеп-теркәп бара, авылның киләчәге өчен борчыла.

Шунысын да әйтик, Әрибә апа – авылда мәчет төзүне оештыручыларның берсе. Мәчет 2006 елда, элеккеге урынында – мулла йорты каршына төзелә. Әрибә апа бүген, бәләкәй чагындагы кебек, һәр иртә тәрәзәдән мәчет манарасына карый.

Язмыш бу көчле, укымышлы, булдыклы хатынны да гомере буе сындырырдай итеп сыный: якын кешеләрен күп югалта ул. Ире Нурулла абый да 48 яшендә мәңгелеккә китеп бара. Ничек кичергәндер... Гел кеше арасында, гел эштә булуы ярдәм иткәндер, мөгаен.

«Авыр чакларымда авыл кешеләре гел ярдәм итте, хуҗалык эшләрендә булыштылар. Барысына да чиксез рәхмәтлемен», – ди Әрибә апа.

– Яшьлегемдә зур шәһәрләрдә укый алмавым гомерлек үкенеч булды. Тол булсам да, ике кызымны да укытырмын дигән максат куйган идем, – дип искә ала ул.

Максатына ирешкән, шөкер, кызлары йөз аклыгы, горурлыгы бүген. Нурзиләсе Удмуртиядә Республика салым идарәсендә җитәкче урыннарда эшләп, ялга чыкты. Нурсөясе – Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең ярдәмчесе, танылган журналист, берничә китап авторы. Оныгы Нәргиз дә Айтугановлар нәселенең дәвамчысы, горурлыгы булырга охшаган. Өч-дүрт чит телдә иркен сөйләшә. Англиядә белем алды, мәдәни мирас белгече.

«Әниегезгә яңа йортны Казан тирәсенә саласыгыз калган, кайтып йөрергә дә якын булыр иде», дип әйтүчеләргә җаваплары әзер: «Туган нигезне ташлап китүне әни дә, без дә күз алдына китерә алмыйбыз. Безне шушы бабайлар нигезенә бәйләп, үзенә тартып торган кадерле җепне ничек өзәсең инде?!» Дөрестән дә, тарихка кереп калган зыялы Айтугановлар нәселе нигезе бит ул. Әнә энесе Ләбибнең кызы, танылган шәхес, «Татаркино» директоры Миләүшә Айтуганова да балачагыннан бирле, җае чыккан саен, әтисе йөргән сукмакларны, Әрибә апасын сагынып, балаларын ияртеп Наратка кайтып йөри.

...Нараттан кузгалып киткәч, Ләбиб Айтугановның шушы юлларда язылган тагын бер җыры искә төште:

Күңелемнән чыкмый һич тә –
Истә, туган як истә...

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Руслан Ахунов. Уфа.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз. Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак. Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.



ӘНИ ДӘ, ӘТИ ДӘ



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Ялгыз гына бала үстерүче әниләр бүгенге җәмгыятьтә гадәти күренеш дип кабул ителә. Чөнки хатын-кызлар үз-үзен генә түгел, балаларын да тәэмин итеп яши алырдай көчле затлар. Тәэмин итәр анысы. Ләкин әле тәрбиялисе бар бит. Әтисезлек бигрәк тә ир балалар тормышында тирән эз калдырырга мөмкин. Акыллы ананың бөтен теләге – тудырган сабыен бәхетле итү, тормышны алып бара алырдай чын ир-ат үстерү. Ә бу бик зур көч һәм зирәклек таләп итә. Ярый ла әни кеше тормыш тәҗрибәсе туплаган хатын-кыз булса, яшьлекләре белән бу хакта уйламаучылар да бар. Баланы карында чакта ук тәрбияли башларга кирәк, юкса соңга калуың бар, диләр. Ялгыз әниләргә баланы тәрбияләү вакытында психолог, сексопатолог ярдәме дә кирәк шул...

Кызым укыган сыйныфта малайлар бик күп. Барысы да шуклар. Араларында берсе бүре баласы кебек. Хәтта күзләрендә дә зурлар карашы: кечкенә генә булса да, бәяләп карый. Сугышуны да ул башлый, дәрес тә аның аркасында өзелә. Алар башка мәктәпкә күчте... Берәр елдан соң очраклы гына әнисе белән күрештек. «Яңа мәктәпкә ияләштегезме?» – дип сорыйм. «Ияләштек, иң мөһиме – аңлаштык», – диде Алия. Сораулы карашымны сизеп булса кирәк: «Безнең бит әти юк. Мин аны үзем генә тәрбиялим», – диде. Авырлы икәнен белгәч, яратып йөргән кешесе ташлап китә аны. Яше дә барган Алия сабыен үзе өчен табарга була. Әтисез бала, кимсенеп үсмәсен дип, бар назын, вакытын аңа багышлый. Иң элек улыма, аннан соң гына үземә дип яши. Ә бала һаман канәгать түгел. Ташлап киткән әтисенә үпкәсе бик зур була аның. Ул үпкә бөтен дөньяга тарала. Нишләргә белмәгән улы белән психологка бара. Аның киңәше буенча улын бокс секциясенә бирә. Беренче дәрестән үк тренер килеп: «Улыгыз ир-атларны куралмый. Әтиегез юкмы әллә?» – дип сорый. Алиягә баш кагарга гына кала. Малай белән уртак тел табар өчен тренер бер ай көрәшә һәм үзенекен итә. «Хәзер улым бокска барырга ашкынып тора, теленнән тренер исеме төшми, характеры үзгәрде», – ди ана. Малайларга әни генә җитми, янында ир заты булу да мөһим икән бит! Ничек кенә тырышмасын әни кеше әти ролен ала алмый. «Әни әни булып калырга тиеш», – ди психолог Алсу Ханнанова. Ялгыз аналар проблемасының үтә актуаль булуын әйтә. Баланы кечкенәдән үк әтисез тормышка әзерли башларга кирәк. «Әгәр дә балага һәр яшь аралыгында ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек тәрбия бирелә икән, үсмерлек чорында проблемалар булмый», – ди белгеч. Дөрес, психологиядә һәр кешегә туры килерлек билгеле бер формула юк. Шулай да Алсу Ханнанова фикеренчә, балага әни әтисез генә тәрбия бирә ала, әгәр дә ул түбәндәгеләрне эшләсә.



Алсу ХАННАНОВА: «Кагыйдә буларак, ялгыз әниләр белгеч янына үсмер малайларын ияртеп килә. Тик бу вакыт җиткәч кенә чаң кага башлау дөрес түгел.

ИРЕК БИРСӘ Сабый беренче адымнарын ясый башлагач дөньяны өйрәнә. Тегендә бара, моны тотып карый. Ә без, әниләр, аның тормышы өчен куркып, тизрәк чикләр куя башлыйбыз. «Ярамый» дип кисәтеп кенә торабыз. Мондый чикләр бала үскәч тә бетми, ә мөстәкыйльлек әкренләп-әкренләп юкка чыга.

БАЛАДА МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК СЫЙФАТЫН ҮСТЕРСӘ Ул 3-6 яшь арасында мөһим. Гади генә мисал: балага бер футболка ошый, ә ана башканы әзерләгән. Бала елый, карыша, аның үзе сайлаганны киясе килә. Нигездә, бу көрәштә әниләр җиңә. Ләкин бу бик үк дөрес түгел икән. Шуның нигезендә диктатор әниләрнең уллары белән аңлашылмаучанлыклары яшүсмер чагында башлана. Дөресме-түгелме, үсмер һәрвакыт үзенекен тәкрарлаячак, йә инициативасы булмаган, үз мәнфәгатьләрен кайгырта белмәгән кешегә әйләнәчәк. Билгеле бер чорга кергәч, алар шәхес буларак үзен идентификацияләргә тели. Төрле агымнарга эләгү – шуның билгесе. Моны да кабул итә белергә, баланы ничек бар шулай итеп яратырга өйрәнү мөһим. Кайчак хаталанырга мөмкинлек бирү дә кирәк. Без бит тормышны үз хаталарыбыз аша гына өйрәнәбез.

УЛЫ ЯНЫНДА ҮРНӘК ИР ЗАТЫ БУЛДЫРСА Әти юк – үрнәк юк. Бала өчен, бигрәк тә малайлар өчен эталон булырдай кеше кирәк. Ярый ла тирә-ягында бабасы, абыйсы йә әтиле гаилә дуслары булса. Бала чын гаилә моделен күреп, белеп үсәргә тиеш. Шуңа күрә гаилә традицияләре булдыру мөһим. Мәсәлән, ял көннәрендә җыелышып чәй эчү кебек гадәтләр. Бала ир-атлар белән аралашып үссен.

СТАБИЛЬЛЕК ТУДЫРСА Кечкенә чакта балага режим кирәк, үсә төшкәч, аралашу мохитендә тотрыклылык булу шарт. Әгәр ул бозыла икән, балада стресс булачак. Ялгыз ана, билгеле, үз тормышына бик куярга тиеш түгел. Табигать үзенекен итә ул: хатын-кыз пар эзләми калмый. Ләкин ул ир-атларны перчатка кебек алыштырырга кайтып калмасын иде. Бала яңа кешегә күнегеп беткәч кенә аның юкка чыгуы күңеленә яра салачак. Малайның аңына азып-тузып йөрергә ярый дигән фикер кереп калырга мөмкин. Шуңа күрә очрашкан һәр кеше белән баланы таныштыру дөрес гамәл түгел. Балага күрсәтмичә генә аралашу, чынлап та синең кешеме, түгелме икәнен аңлау зарур.

ХИСЛӘРНЕ КҮРСӘТҮНЕ ТЫЙМАСА Күп вакытта балаларны, бигрәк тә малайларны «Елама, син бит егет кеше», дип оялтырга тырышабыз. Бу дөрес түгел. Без аның эмоцияләрен тыябыз. Ә бу зур тормышта кыенлыклар китереп чыгарачак. Күз яшьләре дә төрлечә булырга мөмкин, әлбәттә. Һәрхәлдә, үзсүзләнеп елау турында сүз бармый инде.

ЯРДӘМЧЕ ҮСТЕРСӘ Балада шәфкатьлелек хисе уяту мөһим. Дөрес, һәр кешегә карата түгел. Иң элек үзеңә ярдәмче үстерегез. Әтисе юк дип җәлләп, дөньяның бар байлыгын бирергә әзер аналарның уллары, гадәттә, эгоист булып үсә. Начар юлга кереп китүе дә ихтимал.

Фото: www.pixabay.com

PRESSA

СПОРТ СЕКЦИЯЛӘРЕНӘ ЙӨРТСӘ Спорттан битәр, үз тренерыңны табу бәхет. Бу Алия кебек әниләргә зур бер ярдәм. Аның да тирә-ягында улына үрнәк булырдай бер ир заты булмаган. Бала тренерда әти образын тапкан. Спорт белән шөгыльләнгәч, үз эченә йомылып үсми инде ул, ташып торган энергиясенә дә урын табыла.

Әти-әниләрдән аерылу процессы психологиядә сепарация дип атала. Вакыты җиткәч, әни баланы үзеннән җибәрергә тиеш. Җибәрми икән, бала булдыра алганча үз чикләрен билгели (аерым бүлмә сорау менә шушы башлангычның бер билгесе инде). Мондый аерылу булмаса, бала әнисенең иренә әйләнә. «Шәхси мөнәсәбәтләр кора алмаган кайбер ир-атлар белән сөйләшә башлагач, проблеманың тамыры әнә шул икәне аңлашыла», – ди Алсу. Ир ролен алып, ул һәрвакыт әнисен карый, янында булырга тырыша, әни иң абруйлы кеше булып кала, хәтта аның фикере буенча гына яши башлый. Гаилә корса да хатыны белән мөнәсәбәтләре тиз бозыла. Гадәти ир-ат өйләнгәч тә, беренче елны аның өчен әнисе абруйлы кеше була әле. Хатынның бурычы – әнә шул абруйны яулап алу. Шул вакытта гына ир бала әнисе канаты астыннан чыгачак. (Моны әни белән баланы аеру дип кабул итү һич дөрес түгел. Ул бары тик яхшы мәгънәдә. Зирәк хатын беркайчан да ике араны бәйләп торган «җепне» өзмәячәк.) Барлык конфликтларда да утырып сөйләшү зарур. Бары шул вакытта гына аңлашу туа. Дөрес, беренче сөйләшүдән үк барысы да үз урынына баса дигән сүз түгел әле бу.

Ялгыз әни тормышын улы белән генә шөгыльләнеп уткәрә икән, дөрес хәл түгел инде. Ә бу хәзерге җәмгыятьтә бик киң таралган. Әни – шәхес, аның шәхси тормышы булу шарт. Моның өчен ул үз-үзен бәяли белергә тиеш. Улын ялгыз үстерүче әни хатын-кыз булудан туктамасын иде. Ә балага кечкенә ир-ат итеп карап, аның белән сөйләшүләр алып барып, аның фикере белән исәпләшеп яшәү мөһим. Шуны онытмыйк: бәхетле ана гына бәхетле бала үстерә ала.

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Любовь МУМЛАДЗЕ, сексопатолог, табиб-андролог

Россиядә төп проблемаларның берсе: җәмгыятьтә хатын-кыз гаиләләренең күплеге. Феминистик тәрбия киләчәктә ир-ат тормышында чагылмый калмый. Тарихтан беләсез: Александр Македонский әнисе итәгенә ябышып үскән, чирләшкә бала булган. 5 яше тулгач, әтисе Филипп патша аны, әнисеннән аерып, солдатлар арасына илтеп куйган. Андый тәрбия бирелмәсә, исеме гасырлар тарихына язылган шәхес була алмас иде ул.

Малайлар 3-4 яшьтә үзенең ир-ат затыннан икәнен аңлы рәвештә кабул итә башлый. Олыларга бер-бер артлы бирелгән сораулар да әнә шуны раслый. Сорауларын җавапсыз калдырмау, җенес әгъзасы төзелешен, аны читләргә күрсәтергә ярамаганлыгын аңлату мөһим. Пубертат чорына (җенси өлгереш) кызларны гына түгел, малайларны да әзерләргә кирәк. Эрекциясен күреп, бала куркып калмасын. Аның ир-атлар өчен сәламәтлек билгесе булганлыгын аңлату мөһим. Монда тагын бер четерекле теманы читләтеп үтәсем килми: үсмерләрнең үз-үзләрен канәгатьләндерүе. Шуны аңлагыз: бу шөгыль кешелек өчен куркыныч түгел! Бу – бары тик табигать. Әгәр дә күрсәгез, сизсәгез, әрләмәгез! Укый торган яшьтә икән, физиология хакында китап бирегез, кечерәк икән, аңлатыгыз. Үзеңә рәхәтлек бирү теләге булу яхшы, тик аңа кирәгеннән артык игътибар ясау кирәк түгел. Җенси өлгереш чорында кызлар да, малайлар да неандерталец кебек кыргыйлар. Нигәдер юынырга яратмыйлар. Аларны ваннага куып булса да кертеп, юынып йөрергә өйрәтергә кирәк. Җенси гигиена кагыйдәләрен үтәү малайлар өчен дә мөһим. Интим тормыш турында үсмерләр каяндыр читтән, интернеттан түгел, әти-әнисеннән ишетсә яхшырак. Бу хакта сөйләшкәндә аңлату зарур: тирән мөнәсәбәтләр бары тик яраткан кеше белән генә булырга тиеш. Әле ул да җаваплы булса гына. Бигрәк тә коммерцияле сексның начар икәнен төшендерергә кирәк. Ул ир-атның бөтен энергиясен ала, андый мөнәсәбәтләр аны импотентлыкка китерә.

Ир-ат башлангычын бетермәс өчен, малайларга кайда да булса лидер булу зарур. Ә иң мөһиме: ана улының ир-ат минен сындырмасын. Түбәнсетү, фикерен ишетмәү шуңа китерә. Ана үзенең хатын-кыз икәнен онытмасын иде. Нәрсә әйтсәләр дә, ир-ат акылы өстенрәк. Әни моны улында күреп хөрмәт итәргә тиеш. Булачак ирдә Эдип комплексы үстерергә ярамый. Җенси тормышта ул зур проблемалар тудырачак. Андый комплекс булса, егетнең хатын-кызларга карата интим хисләре тумаячак. Ул аларда әни образын күрәчәк. Кагыйдә буларак, мондый егетләр бик тыйнак һәм оялчан булалар, үзләренең физиологиясе белән нишләргә кирәклеген дә аңламыйлар. Кызлар белән аралашырга куркалар, өйдән чыкмыйлар. Үсмер өчен бик куркыныч билге бу. Мондый хәлгә тарымас өчен, әйткәнемчә, бала аралашып үсәргә тиеш, шул исәптән, кызлар белән дә.

14-15 яшьлек үсмерләргә интим мөнәсәбәтләргә кагылышлы тема үтә дә кызыклы. Шуңа даими рәвештә бу хакта ачыктан-ачык сөйләшү мөһим. Әгәр әни ниндидер сәбәпләр аркасында бала белән бу хакта сөйләшергә кыймый икән (замана әниләрендә андый барьерлар калмагандыр дип уйлыйм), урологка, сексопатологка алып барырга кирәк. Компетентлы табиблар, һичшиксез, ярдәмгә киләчәк.

ХЫЯНӘТ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым» мәчете
имам-хатыйбы

Хыянәтнең сәбәбен һәрвакытта да азгынлык дип карау дөресме?

– Ислам динендә хыянәт дигән сүзнең мәгънәсе, әлбәттә, киңрәк. Ул бөтен өлкәгә дә кагыла: дуслыкка, мәхәббәткә, иргә, хатынга, әти-әнигә, эшкә, Аллаһы Тәгаләгә... Инде ир белән хатын мөнәсәбәтенә килсәк, ислам дине хыянәтне, гомумән, гафу итми. Азгынлыкмы ул, түгелме, гашыйк булумы, юкмы – сәбәбе мөһим түгел. Ислам дине шәригатендә мондый адымга барган кешегә җәза каралган – таш белән бәреп үтерү. Ир кешене дә, хатын-кызны да. Аерма шунда: ир кешегә баскан килеш таш белән бәрәләр, хатын-кызга – чүгәләп утырган килеш. Шәригатьтә таш белән бәреп үтерү – иң каты җәза. Аннан да катырак җәза юк. Башны кисү, юлбасарларны баганага бәйләп, сөнге белән кадап үтерү бар, ләкин, миңа калса, алар да таш белән бәреп үтерүгә караганда йомшаграк җәза.

Җәза – җинаятькә, аның катылыгына карап билгеләнә. Димәк, шәригать ирнең хатынына (хатынның иренә) хыянәтен иң каты җинаять ди. (Дин җинаять дип якынлык кылуны саный, кулга-кул тотышу, үбешү моңа керми.) Ләкин бу мөнәсәбәтне дәлилләүче дүрт шаһит – дүрт ир-ат булырга тиеш. (Яки хатын-кыз (ир-ат): «Хыянәт иттем», – дип үзе әйтергә; яки ике якның берсе, икенчесенең хыянәтен сизсә: «Мин тәгаен беләм», – дип, судта вәгъдә бирергә тиеш.) Мондый шаһитлар, әлбәттә, табылмый, шуңа күрә бу җәза сирәк очракта гына тормышка ашырыла. Пәйгамбәребез вакытында бер тапкыр шундый хәл булган. Бер хатын-кыз үзе килеп: «Мин иремә хыянәт иттем һәм балага уздым», – ди. Пәйгамбәребез аны җәзага тартуны башта бала тапканга, аннан баласын имезгәнчегә кадәр калдыра. Соңрак бу хатын-кыз кабат килә: «Инде баланы имидән аерырга вакыт», – ди. Ул Аллаһы Тәгаләдән курка – гөнаһысы өчен җәзаны бу дөньяда алып калырга тели. Кем бу дөньяда җәза ала, ул аны ахирәттә күрмәячәк. Мин моны нәрсәгә сөйлим. Кемдер хатынына (иренә) хыянәт итә һәм «беркем белмәде» дип уйлап йөри, күңелен шуның белән тынычландыра икән, ашыкмасын: Аллаһы Тәгалә каршында моның җәзасын барыбер алачак. Һәм ул, әлбәттә, таш белән бәрелеп үтерелүгә караганда катырак булачак.

Ир (хатын) тәүбә итсә, бу вакытта Аллаһы Тәгалә хыянәтне гафу итә.

Хыянәттән саклану өчен ниләр эшләргә кирәк?

– Күп очракта хыянәткә бары нәфес сәбәп булып тора. (Ә азгынлык – нәфеснең бер чагылышы ул.) Кемдер «гашыйклыкны кая куясыз» дияр... Тик гашыйк булу хыянәт итү дигән сүз түгел бит әле: кешегә кагылмыйча, аны күрмичә гашыйк булырга, читтән генә яратып йөрергә дә мөмкин.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә: «Зинага якын килмәгез», – ди. Ике кеше күрешүгә шунда ук түшәккә ятмый. Башта алар әле сөйләшәләр, аралашалар. Шуңа күрә шәригать буенча ир-ат белән хатын-кыз арасында сәбәпсез сөйләшү булырга тиеш түгел: бу шунда ук хыянәтне чикли. Ир кешегә чит хатын-кызга комплимент ясарга ярамый: ислам дине буенча гөнаһ санала. Чит-ят ир белән чит-ят хатын-кыз икәү генә бер бүлмәдә кала алмый. (Әгәр ул җәмәгать урыны булмаса). Пәйгамбәребез: «Ир белән хатын икәү генә калса, өченчесе шайтан була», – ди. Ислам динендә ике гаилә бер-берсенә кунакка йөрешкән очракта да, хатын-кызлар белән ирләр аерым бүлмәләрдә утыра: дустыңның хатыны сиңа бит беркем түгел. Хыянәткә юллар шулай каплана. Пәйгамбәребез: «Хәтта егет белән кыз арасына да керергә ярамый. Бу – башка кеше хакына керү була. Ә инде никахлы ир (хатын) янына бару – тагын да зуррак гөнаһ», – ди. Пәйгамбәребез иң яман гөнаһ дип күрше хатынына (иренә) кызыгуны саный. Бу очракта тагын да зуррак гөнаһ кылына: күршеләр дошманлаша. Ирнең бертуганы белән хыянәт итү аннан да хәтәррәк – ике туган арасы бозылырга мөмкин ди пәйгамбәребез.

Бер-берсенә якын килсә, кеше инде үз-үзен тыеп кала алмый. Аны шунда ук шайтан котыртырга керешә... Шуңа күрә, ничек кенә матур итеп күрсәтсәң дә (ярату, тартылу, беренче мәхәббәт), кеше барыбер азгынлыкка бирелгән булып санала. Бу гамәлне шуңа да аклап булмый. Моны хатын-кыз кылса, рухи яктан тагын да яманрак – гаиләнең нигезенә балта чабыла. Статистика мәгълүматлары буенча, Европада 50 проценттан артык ир чит кеше баласын үстерә. Белмичә, әлбәттә. Шуңа күрә хатын-кызны иң бизи торган як – иренә тугры булу.

Хатыннар хыянәтне күп вакыт гафу итә, ә ирләр – юк...

– Хатын-кыз – ирнең тылы, аның ышанычлы аркасы. Алдан һөҗүм итеп, арттан да хыянәт итсәләр, иргә тагын да авыррак. Шуңа да ир-ат хыянәт белән килешми.

Хатын-кыз башка иргә гашыйк булган ди. Мондый очракта нишләргә? Бу хисләрне онытырга тырышырга кирәк. Гашыйк булу гаиләне җимерү өчен сәбәп түгел. Кайчак хисләргә юл куймасаң, бер айдан, ярты елдан барысы да онытыла. «Нәрсәгә хыялланып йөргәнмен?» – дип, үзең үк гаҗәпләнәсең... Чынлап торып яратканда да хыянәт кылырга ярый дигән сүз түгел. Инде ире белән тора алмаса, алар бер-берсен күрә алмасалар, бу вакытта инде аерылышалар. Ләкин аерылырга җитди сәбәп кирәк. Аерылышканнан соң гына ул яраткан кешесе белән бергә була. Ир кешенең исә башка варианты бар – ул икенче хатын ала ала.

«МИНЕМ ХОББИ – ЯЗМЫШЛАР»

Журналист Фирая БӘДРЕТДИНОВАның тормыш кагыйдәләре



БАЛА ВАКЫТ, АНЫҢ ХАСИЯТЕ-ӘҺӘМИЯТЕ ТУРЫНДАГЫ ФӘЛСӘФӘНЕ «ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК» ДИП ӨЧ СҮЗГӘ СЫЙДЫРГАН ӘДИПКӘ РӘХМӘТ. Гомернең чагыштырмача кыска гына шушы кисентесеннән сузылган бер җеп һичкайчан өзелми, кайчак йә уйларыбызда, йә төшләребездә, шул җеп буйлап без балачакка кайтып киләбез... Күзгә яңгырлы кич. Апам, мин, сеңлем киң агач караватка аркылы ятып, укытучылар көне уңаеннан Казанга спектакль карарга киткән әниләрне көтәбез. Фәйрүзә апа һавага сүзләр яза. Резеда белән мин укырга азапланабыз... Хәзер дә киң итеп җәелгән диванга балачактагыча өчәүләп аркылы ятып, янәшәлегебезгә куанып, төрлесен сөйләшәбез. Бик рәхәт сәгатьләр бу.

Авылларым минем дүртәү. Туган авылым – Көекбаш. Әнинең туган авылы Таузарда да яшәп алдык. Балачагым дигәндә, Карадуганны күз алдымда тотам. Аннары без Арбашка күчтек. Шулай итеп, дүрт авыллы булдым. Инде тормыш иткәндә мин шушы дүрт авылның, дүрт кеше шикелле, дүрт төрле холыклы булуын аңладым. **ҺӘР АВЫЛНЫҢ ҮЗ ХОЛКЫ БУЛА ИКӘН АНЫҢ.**

Әти безгә беркайчан да исем белән эндәшмәде. Ул безгә «кызым» дия иде. Өчебезгә дә. Ләкин без әтинең «кызым»ыннан кайсыбызга эндәшкәнен аңлый идек. Ул безгә эш кушып эндәшәме, каядыр чакырып эндәшәме, мактап эндәшәме... Чехов бер сүзне 35 төрле мәгънә салып әйтә алган дип язалар. Безнең әтинең сүз төсмерләре күбрәк тә булгандыр әле. **ШУЛХӘТЛЕ САГЫНДЫРА ИНДЕ АНЫҢ УЛ «КЫЗЫМ»НАРЫ. УЛ БЕЗНЕ БИК ЯРАТЫП ҮСТЕРДЕ.**

Әни бер кеше турында да начар сүз әйтмәде. Беркайчан да кеше сөйләмәде. Китапка кермәгән сүзне кулланмый иде. Беркайчан да. Мин хәзерге әдәбиятны күздә тотмыйм, әлбәттә... **ӘНИДӘ БИК КҮП КЕШЕНЕҢ СЕРЕ САКЛАНА ИДЕ.** Укытучы кызлар әнигә серләрен сөйлиләр, җаннарына дәва табалар...

БЕЗ ҺӘММӘБЕЗ АНА КАРЫНЫНДА ЯРАЛЫП, АНАНЫҢ ҮЗӘГЕННӘН ӨЗЕЛЕП ТӨШКӘН ЗАТЛАР. Якты дөньяга килүебез белән үк әниләребезгә бурычлы.

Мин бер атна Фәридә булып яшәгәнмен. Әти һич уйламаганда, әнине шаккаттырып, мине Фирая дип яздырып кайткан. Кызыма Фәридә исеме куштым. Энҗе бөртеге, бердәнбер дигән мәгънәне аңлата ул. Фәридә 3 яшендә безгә: «Мин мөстәкыйль кыз», – дип белдергән иде. Шуннан бирле мөстәкыйльлегенә ышандырып килә. Моңа кадәр борчулар китергәне, йөзне кызартканы булмады. Рәхмәт аңа. **ҺӘР ӘНИ ШИКЕЛЛЕ ИНДЕ МИН: БАЛАМ БӘХЕТЛЕ ГЕНӘ БУЛА КҮРСЕН!**

БАШЛАНГЫЧТА УКЫГАНДА МИН ОЧУЧЫ БУЛАМ ДИДЕМ. Очучы буласы килүдән бигрәк, хыялый җанымны күрсәтә торган әйбер булгандыр ул. 9-10 нчы сыйныфта укыганда конкурска язылган сочинениеләрем республикада I урынны алды. Балтачтагы укытучым Линура Габделхакова: «Син журналист булырга тиеш!» – диде. Журналистикага бару турында уйлап та баккан кеше түгел идем.

КЕШЕ КҮЗ АЛДЫНДА ЙӨРҮ – ИҢ АВЫРЫ МИНЕМ ӨЧЕН. Эшен эшлим, ә күренеп йөрү минеке түгел инде!

Һәр журналистның, русча әйтмешли, үз «конёгы» була. Кемдер аерым темага яза, кемдер оста репортёр... **МИНЕ АЕРЫП ТОРГАН, НИНДИДЕР МАКТАУ ИШЕТТЕРГӘН ӘЙБЕР – ЯЗМАЛАРЫМНЫҢ ТЕЛЕ ДИП УЙЛЫЙМ.**

Туганыбыз Азат абый Зыятдиновның мондый сүзе бар иде: «Олы казанда кайнаган чи калмас». Әтисе бу мәкальне гел әйтә торган булган. **МӘСКӘҮДӘ УКЫП КАЙТУ МИНЕМ ӨЧЕН ДӘ ОЛЫ КАЗАНДА КАЙНАП АЛУ БЕЛӘН БЕР БУЛДЫ.** Ул күңел офыкларын ачып, киңәйтеп җибәрде! ВКШда (югары комсомол мәктәбе) уку чорында дөньяның 70 тән артык иленнән килеп укучы студентлар белән аралаштык. Танылган журналистлар килеп дәрес бирде. Шундыйларның берсе – атаклы Владимир Познер. Ул минем өчен гади журналист кына түгел.

Укырга «Яшь ленинчы»дан киткән кеше буларак, стажировканы «Пионерская правда»да үттем. Остазым танылган балалар журналисты Елена Львовна Павлова күп нәрсәгә өйрәтте. Бу редакциядә авторның рөхсәтеннән башка аның бер генә сүзен дә төзәтмиләр иде! Бу хәл мине гаҗәпләндерде һәм сокландырды. **МАТУРЛЫЙМ ДИП, ЯЗМАНЫ БЕТКӘНЧЕ ТӨЗӘТӘСЕ ЮК.** Редакцияләгәндә шушы кагыйдәне сакларга тырышам. Тәрҗемә итәсе текстның холкын, рухын ачыклыйм башта. Ул бик җитди әйбер булырга мөмкин, әзрәк уенчак әйбер булырга, репортаж тибында... һәм башка, һәм башкалар... Күп сүзле, аз сүзле, тыгыз... Менә шуны бозмаска кирәк.

КАЗАНДА – МӘСКӘҮНЕ, МӘСКӘҮДӘ КАЗАННЫ САГЫНАСЫҢ ИКӘН УЛ. Казанда – туганнар, дуслар, театр, редакция... Мәскәүдә укыганда Камал театрына барыр өчен генә дә кайта идем. Бервакыт ничектер Зөлфәт абый белән Фирая апалардан киткәнем исемдә. Бөтен өй эче белән вокзалга озатырга төштеләр... Менә шулай бер гаилә булып яшәдек без «Яшь ленинчы»да... Мәскәүдәге бүлмәдәш кызларга мондагыларны сөйләгәнмендер инде. «Синең анда бөтенесе дә шундый әйбәт!» – дип көләләр иде. Ул кешеләрне аннан торып ничек сагынган булсам, монда да нәкъ шулай яратам.

«ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ»ГА КИЛЕП ЭЛӘГҮЕМНЕ ҮЗЕМНЕҢ БИК ЗУР БӘХЕТЕМ ДИП САНЫЙМ. Студент чакта ук эшли башладым. Практика узганнан соң инде мине әкренәкрен эшкә кертеп җибәрделәр. Редакторым Роза апа Туфитуллова заочнога күчәргә тәкъдим итеп, деканаттан рөхсәт булмагач, журналистика бүлеге мөдире Флорид Әгъзамов: «Син монда күренмәгәндә, без күз йомарбыз, эшеңдә бик күренеп җитә алмасаң, Роза апаң күз йомар», – диде. Без, яңа килеп кушылганнар, ул тату «Яшь ленинчы» гаиләсенең балалары шикелле булдык.

Фото: Анна Арахамия

«Сөембикә» редакциясенә килергә журналист буларак әзер булганмындыр инде. Ул чактагы матбугат министры Зилә Рәхимьяновна баш мөхәррир эшенә тәкъдим иткәндә, русчалап: «Это же золотой шар! Как бы не уронить!» – дип әйткәнемне хәтерлим. **ҺӘМ УЛ ӘЛЕ ДӘ МИНӘ ШУШЫНДЫЙ АЛТЫН ШАР.**

ДӨНЬЯ ТҮГӘРӘК ШУЛ! Уйлаган уйлар да, кылган гамәлләр дә Җиребездән беркая да китми. Әйләнә дә үзеңә кайта...

«БӘХЕТНЕҢ БЕР ИШЕГЕ ЯБЫЛГАНДА ИКЕНЧЕСЕ АЧЫЛА»... Америка язучысы Хелен Келлер шулай дигән. Укыйк әле: «Бәхетнең бер ишеге ябылганда икенчесе ачыла; ә без, ябык ишеккә текәлеп торып, аны күрми генә калабыз». Колак салыйк бу сүзләргә: сукыр, чукрак һәм дә телсез бу ханым ни әйткәнен белеп әйтәдер. Ул бит дөньяга күңел күзе белән карап яшәүчеләрдән.

Без, кешеләр, бала вакытта да, үсеп җиткәч, олыгайгач та усаллыктан, тупаслыктан, авыр сүздән куркабыз. **БЕЗГӘ ГЕЛ ҖЫЛЫ, МАТУР, ТҮГӘРӘК СҮЗЛӘР ТАНСЫК.** Янәшәбездәгеләр бездән дә нәкъ менә шуны көтә.

Татар ханымнарын, туташларын чибәр диләр, акыллы, булдыклы, тәпле, сабыр, диләр. **БЕЗНЕҢ БЕР ГЕНӘ ЗУР КИМЧЕЛЕГЕБЕЗ БАР: МАТУР СҮЗНЕ МАТУР ИТЕП ТЫҢЛЫЙ БЕЛМИБЕЗ БЕЗ.** «Сез бигрәк яшь күренәсез!» дигәнгә, «Һи, кая инде ул яшь булу, менә...» дип, иң элек авыр эштән тупасланган куллар алга сузыла. «Күлмәгегез бигрәк килешле» диючесенә дә «рәхмәт» әзер: «Әйе, базарда да кайвакыт кеше киярлек әйбер табып була ул!»

БАЛИГЪ БУЛГАЧ, КЫЗ БАЛАНЫ, ИР БАЛАНЫ ГАИЛӘЛЕ ИТҮ – ӘТИ-ӘНИНЕҢ БУРЫЧЫ. Рәшидә абыстайның шул сүзләрен күңелемә салып куйдым. Хөрмәт иясе бер ханым кызын кияүгә биргәннән соң, яңалыклары белән котлап: «Сез үзегезнең бурычыгызны үтәдегез», – дидем. «Ул да үзенең бурычын үтәде», – дигән җавап яңгырады. Сискәндереп җибәрде ул. Чынлап та, без үзебезне үстергән әти-әниләрне, вакытында гаилә корып сөендереп, алардан оныкларын да сөйдерергә тиеш икәнбез. Бу безнең бурычыбыз икән.

Нәрсә ул мәхәббәт? Моң нәрсә? Матурлык? Без аларны бер сүз, бер җөмлә белән генә аңлата алмыйбыз. Мәскәүдә укыганда бер укытучыбыз лекциядә: «Матурлык сүзенең 39 төрле аңлатмасын таптым, тик берсе дә канәгатьләндерми», – дигән иде. Бәхет сүзе дә менә шундый аңлатып бетереп булмый торган төшенчә. Минем беркайчан да үземне бәхетсез итеп тойганым булмады. Хәтта иң авыр вакытта да... **БӨТЕН КЕШЕ ДӘ БУ ДӨНЬЯГА СЫНАЛЫР ӨЧЕН КИЛӘ.** Яши-яши шуны аңладым: һәркемнең үз сынавы. Кызыма теләк теләгәндә дә, сынауларның авырын бирмә, җиңелен бир, дип сорыйм. Менә шул сынауларны үтә бару – бәхет түгел микән?

МИНЕМ ЯЗМЫШЫМНЫ ҮЗГӘРТӘСЕМ КИЛМИ. Флорид Әхмәтович берчак мине аспирантурага керергә һәм журналистика факультетында укытырга дип чакырды. Шушы эшкә ризалатырга өметләнеп, берсен тартуга – икенчесен, өченчесен кабыза-кабыза, сигез сигарет тартып бетерде ул. Ә мин ризалашмадым. Тормыш барыбер һәр нәрсәне үз урынына утырта икән: мин бүген фәнни институтта, ә эшем шул ук язу белән бәйле.

Студент чакта Ташкентка фәнни конференциягә баргач, дус кызларга 12 см үкчәле босоножкалар җыеп кайтканым хәтердә. Мәскәүдә укыганда да миңа шундый күп заказлар бирәләр, аларны рәхәтләнеп үти идем. **БАШКАЛАРНЫ СӨЕНДЕРҮ ОШЫЙ МИҢА.**

ЧЕМОДАН ТУТЫРЫРГА ОСТА МИН. Бөтен кеше чемоданын миннән тутырта. Юлларда күп йөрдем, мөгаен, шуңадыр. Дөнья күрү белән бәйле профессия сайлыйсым килә дигәч, әни: «Сиңа, кызым, геолог булырга кирәк алайса», – диде. Геолог булмасам да, бик күп йөрелде. Авыр һөнәр – журналистиканы сайлавым өчен миңа бер бонус дип саныйм моны. Миндә һаман яңа җирләр, яңа кешеләр, яңа язмышлар, яңа дөнья ачасы килү теләге.

Авыл әдәбе, шәһәр әдәбе дигән әйбер бар. Икесе ике нәрсә. Без, авылдан килгән мәлдә шәһәр әдәбен әле аңлап бетермибез. Эчтән бик мәгънәле, мәнле булсак та, тыштан шәһәр кешесенә бераз көлкерәк тә күренергә мөмкинбез. Ә шәһәр кешесенә безнең ныклык җитеп бетми. **ДУС КЫЗЫМ АЛЬБИНА МИНЕ ШӘҺӘР ӘДӘБЕНӘ ӨЙРӘТКӘН КЕШЕ.** Ә мин аңа үземчә булыштым.

ДУСЛАРЫМ КҮП ТҮГЕЛ, САНАУЛЫ ГЫНА. Чөнки җаныма дус дип санаган кешенең үзен генә алмыйм. Мин аны бөтен дөньясы, туган-тумачасы белән кертеп утыртам.

Чәй эчеп утырганда да китаптан аерыла алмыйм. **ЯШЬЛӘРНЕҢ УКУДАН БИЗҮЛӘРЕНӘ БОРЧЫЛАМ.** Шулай дип ялгышабызмы әллә? «Без бит китапны китаптан укымыйбыз», – ди кызым.

ИҢ АВЫР ВАКЫТЛАРЫМДА ШИГЫРЬ УКЫП ДӘВАЛАНДЫМ. Без белми-күрми калган әбиебезнең кече сеңлесе, биш бала табып, шулардан дүртесен җир куенына куйган (соңгысын 16 яшендә) Балапайның безгә ни өчен «кызым, шигырь китаплары алып кайтыгыз миңа» дигәнен дә шунда аңладым.

Бәхет ишеге булдымы икән ул, белмим, алдымдагы ишекнең ямьсез шыгырдап ябылуын үземә дә күрергә-кичерергә туры килде. Әллә Хелен ханым кисәтеп куйганга, **МИН АЛДЫМДА ЯҢА ИШЕК АЧЫЛАСЫНА ӨМЕТЛӘНДЕМ, ЫШАНДЫМ, ҺӘМ НӘКЪ УЛ ӘЙТКӘНЧӘ БУЛДЫ!**

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

Мода дип әйтүгә, подиум буенча атлаган талчыбык модельләр, төрле тукымалардан тегелгән костюм-күлмәкләр, шуларны кияргә өндәгән стилистлар күз алдына килә. Ә менә шуларның барысын да тудырган дизайнер-технологлар читтә кала. Югыйсә нәкъ менә шушы һөнәр ияләре мода индустриясе нигезендә тора бит. Кайсы чорда яшәүгә карамастан, модага һәрвакыт ихтыяҗ зур. Чөнки барыбызның да (бигрәк тә без – хатын-кызларның!) матур итеп киенеп йөрисе килә. WorldSkills эшче һөнәрләр чемпионатында да мода технологиясе компетенциясе бар. Гади итеп әйтсәк, ул – булачак дизайнерлар мәйданы. Араларыннан киләчәктә Коко Шанель, Карл Лагерфельд, Ив Сен-Лоран дәвамчылары чыгарга мөмкин. Чемпионатта Татарстан данын яклаган Һава ГАГИЕВА да, бәлки, мода индустриясендә якты йолдыз булып калкыр, әлегә исә аның хыялы башка...



ТЕГҮЧЕ – ОСТАЛАР ҺӨНӘРЕ

Һава Казанга таулар иле Ингушетия Республикасыннан килә. Унберенче сыйныфны тәмамлагач, балачак хыялын чынга ашырырга була. Кечкенәдән тегәргә ярата ул. Курчакларына нинди генә матур күлмәкләр тегеп кидертми. Авылда җиде балалы ишле гаиләдә яшәп, тегү белән шөгыльләнү гаҗәп тә түгел. Апасы да тегә, әнисе дә кул эшләренә оста. Бу осталык Һавага да күчә, күрәсең. Гадәттә, урта мәктәпне тәмамлаганнар югары уку йортына керергә тырыша. Һава исә технология һәм дизайн колледжын сайлый. «Урта һөнәри белем бирү йортларында вузларга караганда белемне тирәнрәк бирәләр», – дип аңлата бу адымын. Укырга кергәч, әлеге фикере ныгый гына. Кызганыч, туган ягында дизайнер-технолог һөнәрен тирәнтен өйрәтмиләр. Мондый төр сәнәгать тә юк дәрәҗәсендә диярлек. Читтә укып карарга уйлый. Мәскәү, Казан уку йортларына документларын җибәрә. Бәхеткәме, бәхетсезлеккә каршымы, документлары Мәскәүгә барып җитми, почтада тоткарлана. Казанның дизайн һәм технология колледжы кызны укырга кабул итә. Моңа шатлана гына Һава. Татарстан башкаласындагы медицина университетында бертуган апасы Жарейда белем ала бит. Чит-ят җирдә барып сыенып якын кешең булу бик мөһим ул (алар артыннан сеңелләре Ләйлә дә Казанга – фармацевтика колледжына укырга килә). Шулай да Казанга авыр ияләшә кыз. Җылы яктан килгән Һаваны салкыннары белән куркыта ул. Шунысы шатландыра: дини кызга татар мохитендә күпкә уңайлырак була.

Колледжда укый башлау белән үк аларга WorldSkills хәрәкәте хакында сөйлиләр. II курста укыганда уку йорты буенча үткәрелгән бәйгедә икенче урынны ала. Аны егет кеше – Рәмзил Камалиев кенә уздыра. Ул вакытта алар бер атна эчендә күлмәк тегәләр. «Шулкадәр дулкынланганмын күрәсең, күлмәк җиңнәрен бутап тегеп куйган идем», – дип искә ала ул. Хәзер инде тәҗрибәсе җитәрлек, бәйгедәге биремнәр дә җиңелрәк кебек тоела. Аны Татарстан җыелма командасына алалар. Әлеге команда белән үзенең туган җире Ингушетиядә уздырылган WorldSkills Russia төбәк ярышларында катнаша. Үз өеңдә диварлар да булаша, диләр бит. Һава да нәкъ менә Ингушетиягә барып көч сынашуга бик тә шатлана. Үзе өчен җан атарлар дип өметләнә. Өмете аклана, тик аның башка республика өчен ярышуына кырын караучылар да табыла.

Һава хәзер Казанда май аенда узачак эшче һөнәрләр буенча Бөтенроссия чемпионатына әзерләнә. Анда аларга, техник биремнәрдән тыш, алты сәгать эчендә хатын-кызлар блузкасы тегәргә кирәк булачак. Шуның өчен хәзер алар унар сәгать эш өстәле янынннан китмиләр. Җөй тегү берни тормый, өлгеләрне сызып кисәргә кирәк. Һава өчен иң авыры шул. Колледжда производствода эшләргә өйрәтәләр, ә бәйгедә иҗади уйлау мөһим. Шуңа күрә һәр экспертның дәресен йотылып тыңлый. Көн саен үзенә яңалык ача ул. WorldSkills хәрәкәтендә катнашу аңа зур тәҗрибә бирә. Дөрес, кайбер чакта ашарга түгел, намаз укып алырга да вакыты җитми. Чемпионатта, әлбәттә инде, беренче урынны аласы килә. Сынатырга ярамый. Әнисе догалары белән көч биреп тора үзенә. Һава белә: ул аларның – зур өмете. Кайтып, үзенең ательесын ачып, гүзәл затлар өчен күлмәкләр тегү хыялы белән яши. «Күлмәк – хатын-кызның иң матур киеме. Ул аны тагын да зифаландыра, сылулата», – ди булачак дизайнер. Тегәргә өйрәтү мәктәбе дә ачасы килә. Белгәнеңне кешегә өйрәтү – зур савап, ди ул. Югары белем алу турында да хыяллана: Казан вузларының берсендә читтән торып укырга тели.

«Язмышыңа язылган булып, Казанда калсаң», – дим.

«Юк, – дип кире кага Һава. – Тауларны бик сагынам шул...»

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА



«АЗНАКАЙ КУРЧАГЫ»

– Йөрәгем җитеп, ничек тотынганымны хәзер үзем дә белмим... Миңа бу эш кызык иде – башкасы турында уйламадым...

60 яшьтәме? 60 яшьтә күпләр «барысы да артта калды инде», дип, өй тирәсеннән ерак китми: сериаллар карый, көннәре оныкларны каршылап-озатып уза, хыялланудан туктый... Ә ул... ул әле яши генә башлый. Үз эшен ача! «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесенең быелгы лауреатларыннан берсенә – «Өченче буын героинясы» номинациясендә җиңү яулаган Галина Альвисовна ГЕРКка ул сәхнәдә басып торганда күпләр игътибар иткәндер. Аяк битенә җиткән озын күлмәк, затлы калфак һәм... менә шундый ят фамилия. Чын татар районына – Азнакайга кайдан килеп адашкан икән фрау Галина?



Гөлнур САФИУЛЛИНА

ЗАМАН һӘМ БЕЗ



Яши-яши, йөз-кыяфәтем белән дә татарга охшый барам бугай.

Ул җитәкләгән «Азнакай сувенирлы» остаханәсе турында сөйләүгә күчкәнче, башта минем шушы тарихка тукталасым килә. Китап язарлык тарихка...

Галина Альвисовнаның әнисе Мөнҗия – Иректе авылы кызы. Әнисе нибары 40 яшендә мәңгелеккә күзен йомганда аңа яңа 17 се тулган була. Илдә Бөек Ватан сугышы бара, аларның да әтиләре фронтта... Үзе дә балалыктан әле чыгып кына килүче кыз кулында җиде (!) бала кала. Иң кечкенә энеләренә җиде ай. Сигезенчегә – туксанны узган әбиләре... Очраган саен тирә-күршеләр кызга: «Төпчегегез үлсә дә сиңа җиңелрәк булыр иде ичмасам», – дип кабатлый. Яхшылык теләп әйтәләр дә бит, тик аның энесен жәлләп шунда ук яшьләре тама башлый... Туганнарының барысын да саклап кала ул. Хәтта ике баш сыерны да! Әтиләре авылга 1948 елда гына кайтып төшә. Аларны алырга гына кайтуы икән. «Хәрби заводта эшлим, син дә минем янга урнашырсың, бергә яшәргә җиңелрәк булыр», – ди. Кузгалалар... Иректедәге 30 сутый бәрәңге бакчасыз, сыерсыз ишле гаилә белән шәһәрдә көн итүләре ансат булмавын бик тиз аңлыйлар да... Алдагы җәйгә ялга кайткач, әтисе Мөнҗияне Ирекледә калдыра: «Авылда гына төпләник, кызым, син китеп йөрмә, начальнигыңа мин үзем әйтермен», – ди. Тик хәрби заводта тәртипләр кырыс була шул: «эшкә чыкмаган» өчен дип, Мөнҗияне килеп кулга алалар һәм ике елга төрмәгә утырталар. Озакламый ул амнистиягә эләгә һәм Монголиядән Азнакайга кадәр җәяү кайта. Ә йортта инде үги әни хуҗа, буй җиткән кыз анда, әлбәттә, артык... Әтисе белән яңа әнисе, үзенә әйтеп тә тормыйча, аны торф чыгарырга китүче кешеләр исемлегенә теркиләр... Берничә ел элегрәк исә Саратов өлкәсендә яшәгән Идел буе немецларын бер көн эчендә, товар вагоннарына төяп, Себергә озаталар. «Без бит монда, шушы җирдә туып-үстек, беркемгә начарлык эшләгәнебез юк», – дип өзгәләнүләрен ишетмиләр. Төзек йортлары, чәчәккә, җиләк-җимеш бакчаларына күмелеп утырган урамнары белән Герклар яшәгән авыл да ул көнне бушап кала. Кайчандыр Россия патшасы үзе чакырып китерткән алман һөнәрчеләре авылы. Август ае була. Кырларда игеннәр шаулап утыра, савылмаган сыерлар мөгри... Тормышның менә шундый катлаулы сынауларын кичкәннән соң, чит-ят җирдә татар кызы белән немец егете очраша. Башкалар кичләрен танцыга йөгергәндә, чигү чигеп гел өйдә калган чибәр, озын толымлы Мөнҗиягә Альвисның күзе төшә. Кавышалар...

Кайчандыр икесен бер сукмакка чыгарган язмыш инде аларны күптән аерган. Хәтта каберләре дә икесе ике җирдә, ике илдә. Мөнҗия апаныкы – монда. Әтиләренеке – тарихи Ватанында. Туксанынчы елларда Германия аларга да әби-бабалары туфрагында – Баден-Вюртембергта җир бирә. Галина Альвисовнаның өч сеңлесе, бер энесе шунда яшәп ята хәзер. Әтиләренең, әлбәттә, олы кызын да үз янына бик аласы килгән. «Әти исән чагында Германиягә кунакка еш барып йөрдем. Хәзер дә гел барып торам. Мин анда үземне Андерсен әкиятләренә эләккән кебек хис итәм...



Документларыбыз инде әзер иде. Тик улым: «Әллә китмибезме соң? Монда ияләшкән җир бит», – диде. Аның сүзеннән узмадым, шулай итеп калдык», – ди ул. Сүзләрендә үкенү ишетелми.

Кан тартуы барысын да җиңә. Һөнәрчелек турында әйтүем әле.

– Кулыма бер газета килеп эләкте. Президентның Указы басылган иде анда. Казанның меңьеллыгы алдыннан сувенирлар әзерләү хакында. Күңелемә кереп утырды гына бит – һич тынгылык бирми! Кызыма әйтәм: «Әйдә, без дә тотынып карыйбыз!» – дим. Икебез бер коллективта эшләдек, ул кулланма-гамәли сәнгать буенча дәресләр алып бара иде. Курчаклар ясап карарга булдык...

Галина Альвисовнаның Азнакай балалар музыка мәктәбендә сәнгать бүлеге мөдире булып эшләгән чагы бу. (Омск өлкәсендә дөньяга килгән кызның әнисенең туган ягында төпләнеп калуы да язмыш, әлбәттә.) Татар милли чигешле күлмәк «кигән» курчаклар яныннан күргәзмәләрдә кеше китми. Барысының да тотып карыйсы, үзенеке итәсе – сатып аласы килә. Бер курчак янына икенчесе өстәлә, өченчесе, дүртенчесе...

– Мин курчаклар белән тәмам саташтым! Көндез дә ясыйм, төннәрен дә... Әмма хыялларым артыннан барыбер өлгерә алмыйм!

Әнә шул «өлгерә алмау» иң зур проблемага әйләнгән бер вакытта Азнакай районы башлыгы итеп Марсель Зөфәр улы Шәйдуллинны билгелиләр. Галина Геркка үз эшен башлап карарга ул тәкъдим итә. Ярдәм кулы да суза.

«Азнакай сувенирлы» халык һөнәрчеләре йорты 2012 елның 1 мартында ачыла. Һөнәрче ханымга, таш-

Фотолар: Анна Арахамия

Китәргә күпме талпындым, китә алмадым – мин инде төп Азнакайныкы.







ламалы шартларда, 130 квадрат метрлы мәйданны арендага бирәләр, ә ул районда яшәүче мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны үзенә эшкә ала.

Беренче ялгышлар. Бүген артка борылып караганда, иң элек шулар искә төшә.

– Бернинди тәҗрибәм юк иде бит... Эшләү теләгем генә көчле! Ике бүлмә тулып утыра иде баштагы мәлләрдә. Ул кадәр кеше алырга кирәкмәгәнен соңрак аңладым... Арада бөтенләй эшли алмаучылар да бар булып чыкты. Никадәр материалны боздылар! Берәү йөрәгенә инде өч тапкыр операция ясаткан – хәтере бөтенләй юк. Икенчесендә – шизофрения, институтта укыганда ялгышкан, кызлар: «Без аңардан куркабыз, ул бик агрессив», – диделәр. Эштән киткәч тә, юлыма чыгып, шактый янап йөрде үземә. Өченчесенең – умыртка баганасы авырта, озак утырып тора алмый, ә безнең эштә ансыз булмый... Мәшгульлек үзәгә аша килгән берәүгә: «Үзең дә күреп торасың – булдыра алмыйсың. Җибәрмичә чарам юк», – дигәч, «Ике елдан пенсиягә чыгам, хәзер кая барыйм, зинһар, калдыр», – диде. Калдырдым... Безне бит мәктәптә укыганда ук һәрвакыт кешеләргә карата әйбәт булырга кирәк дип өйрәттеләр: хәленә керергә, юл бирергә, терсәк белән сугышмаска... Мин дә әйбәт булырга тырыштым. Ә бер ай узуга, икенчесе шундый тиз килеп җитә! Салымнар түләргә кирәк, аренда хакы... Хезмәт хакын түләү буенча тоткарлыклар килеп чыккач, шушы кешеләр өстемнән шикаять яздылар... Ул чакта ничекләр түздем икән, хәзер дә аңламыйм...

«Мин үземне һәрвакыт йомшакка саный идем», – ди ул. (Күпләребез үз-үзен шулай белеп бетерми бугай!) Сыгылыплар төшәрлек сынау килгәндә исә көч каяндыр табыла аңарда. Аякта басып калырга. Егылмаска. Алга таба атлап китәргә.

Һөнәрчеләр йорты март башында ишекләрен ача, ә сентябрь аенда ул улын югалта. Иреннән бик иртә аерылып, кызы белән улын ялгызы гына аякка бастырган әни кешегә хәсрәтнең иң ачысы килә... 5 яшьлек чагында имгәнеп, авыру булып калган улы белән аралары бигрәкләр дә якын була шул...

– Бер атнаның шимбәсендә – туган көне булды, икенче атнаның азагында җирләдек... Ничек кичердем икән мин ул көннәрне, белмим. Йокыдан калдым, ашаудан... Көнетөне эшләдем дә эшләдем. Шул коткарды бугай... Инде менә, Аллага шөкер, сәхнәгә чыгып шигырьләр сөйли алам.

Әйе, барысы да акрынлап җайга салына.

Иң беренче ялгышлар төзәтелә. Мондый остаханәдә кул эшен яратканнар, моңа азмы-күпме сәләте булганнар гына эшли ала – ул хәзер һәркемгә шушы таләпне куя.

2002 елны Галина Герк Татарстан Республикасының «Халык һөнәрчеләре» берлегенә керә, ул – «Һөнәрчеләр палатасы» әгъзасы. Фикердәшләре белән очрашу-аралашу, күргәзмәләрдә фикер алышу, иҗатыңны башкалар белән чагыштырулар – барысы да алга таба эшләргә зур этәргеч бирә. «Татарстан Республикасы халык сәнгате һөнәре остасы» дигән мактаулы исемгә лаек булу исә яңа офыклар ача: Оста исемен йөртүчеләргә җәен «Казан Кремле»ндә үз эшләнмәләрен туристларга тәкъдим итү мөмкинлеге бирелә.

Курчаклар бик тиз ясалмый. Бигрәк тә – зурлары.

– Иң элек курчакның башын, кулларын, аякларын, гәүдәсен – һәммәсен аерым-аерым формада коябыз. Фарфордан эшләнгән курчаклар ялгыш төшеп китсә дә ватыла. Ә безнекеләр нык – скульптуралар ясый торган махсус балчык кулланабыз. Үзебезнең Илбәк авылы янында ак балчык бар, диләр – шуны алып кайтып ясап карыйсым килә әле... Курчакларның башларын, кулларын Рамил коя менә хәзер

бездә. Күптән түгел эшли әле ул, әмма инде ияләште. Улының эшле булуына әнисе дә бик канәгать. Нәрсәгәдер кәефем төшкәнне, азрак ачуланганымны сизсә, Рамил аркамнан килеп кочып ала. Улым да шулай итә иде... Церебраль паралич белән авырый ул, өянәге дә бар... Койганнан соң башларны, кулларны әле эшкәртергә кирәк. Рамил инде бу эшкә дә өйрәнде. Әмма аңардан соң кабат барысын да үзем бер кат күздән кичерәм. Менә, күрәсезме, кайберсенең борыны бигүк килеп чыкмаган – ямап, төзәтеп куярга кирәк. Кайсысының күзе...

Кәеф бар чакта гына утыра алмыйсың – эш бит. Әмма курчакларны кулга алуга күңелдә болытлар тарала. Хәсрәт тә онытыла төшә...

Курчакларга киемне үзем уйлыйм: тукымаларны эзләп табам, төсен, фасонын сайлыйм, алкаларын туры китерәм... Күлмәк-камзулларны кызлар тегә, ә мин курчакларның йөзен, кул чукларын ясыйм. (Вак, четерекле, катлаулы эш – көнгә уннан да артык башны берничек буяп булмый!) Иң кызыгы шул: йөз чалымы һәр курчакның үзенчә килеп чыга! Күз карашлары, елмаюлары... Кешеләр шуны күрә: «Карале, болар төрле икән бит!» – дип, үзләренә ошаганны сайлап ала. Минем үземә безнең курчакларның кечерәкләре шаянрак кебек тоела.

Ә иң рәхәте, әлбәттә, курчакларны киендерү... Заказ бирүче: «Бигрәк матур булган!» – дисә, бөтенләй канатланасың! Казанда таныш бер рәссам яныма килеп: «Сезнең курчаклар ягымлы, җылы!» – дигән иде: аның сүзләре искә төшкән саен сөенәм...

Заказ дигәннән, «Азнакай курчагы»н, әлбәттә, республикада инде күптән таныйлар. (Курчак ясаучылар исә Татарстанда хәзер аз түгел: «Халык һөнәрчеләре» берлегендә алар инде хәтта аерым гильдия оештырды, анда уннан артык иҗат әһеле керә.) Галина Альвисовна өчен аның курчакларын эзләп башка шәһәрләрдән – Уфадан, Чаллыдан, Түбән Камадан, Лениногорскидан үк килүләре дә горурлык. Аның затлы «Сөембикә»сен, гади ситсы күлмәкле «Авыл кызы»н, бәрхет камзуллы «Шәһәр кызы»н Франция, Төркия, Америкага алып китүләре, Татарстан Президенты Аппаратыннан күпләп соратып алулары, күргәзмәләргә чакырып торулары...

Алъяпкыч, калфак, изү, төрле зурлыктагы сумкалар, курчак-магнитлар... «Азнакай сувенирлары» остаханәсе әзерләгән товарлар исемлеге ел саен арта тора. Калфак янына алка сораучы да күп, димәк, озакламый милли бизәкле алкалар да өстәләчәк.


Беренче мәлләрдә курчак күлмәкләрендәге һәр чигүне кулдан чиккәннәр. Хәзер Галина Альвисовна машина белән чигә. Бу нечкә эшне ышанып тапшырырлык кеше таба алмаган әле – эзли. Тапса, вакыты шактый бушар, яңа идеяләргә урын калыр иде дә бит... Тик осталар адым саен очрап тормый шул.

Аның кул астында бүген 6-7 кеше эшли, җәйгә, ким дигәндә, 10 кеше кирәк. Бүген янында булган кызлар – иң ышанычлылары, иң булдыклылары. Светлана – сумкалар тегә. Ул – өч бала әнисе, игезәк балаларының берсе – авыру. Светлана аны ялгызын бер сәгатькә дә калдырып йөри алмый. Остаханә белән янәшә яшәве аңа бик уңайлы: әзер эшләрне йә йөгереп кенә үзе кереп алып чыга, йә кертеп үк бирәләр. «Аңа азрак ярдәм итә алгач, миңа да рәхәт», – дип сөенә Галина Альвисовна.

Зөлфия исә аның уң кулы. Ул «Азнакай сувенирлары»на мәшгульлек үзәге аша килгән. Чукрак-телсез кызны моңа кадәр эшләгән хезмәт урынында бик кыерсытканнар. Ә остаханәдә аның өчен икенче тормыш башланган... «Эшкә бик озак өйрәнде, бик күп әйберне бозды. Әмма өйрәнде! – дип яратып елмая директор. – Ул монда үз урынында. Бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз». Иң чиста, иң пөхтә эш урыны – Зөлфиянеке. Ул инде күптән бар эшне дә үзе белеп башкара.

...Галина Альвисовнаның күңелендә йөргән хыялларын, ниятләгән кайбер эшләрен махсус сөйләмим. Күз тидерүдән куркам.

Казанда, туристлар күпләп йөри торган урыннарда «Азнакай курчаклар»ын очратканда шушы язманы искә төшерерсез. Коңгырт күзләре белән әтисенә охшаган, үзе әйтмешли: «кайчак фрау Галина булып фикер йөртә, әмма татарча сөйли, татарча уйлый» һәм татарга эшли торган сөйкемле ханымны.


ДОМ НАРОДНЫХ ПРОМЫСЛОВ
АЗНАКАЕВСКИЕ СУВЕНИРЫ
куклы и другая сувенирная продукция
г. Азнакаево ул. Гагарина, 35
8 (927) 482-21-75
ИП Герк Галина Альвисовна
РЕКЛАМА

– ТАТАР ФЕМИНИЗМЫ... – МИЛЛӘТ АНАЛАРЫ?



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

«Президент хатын-кыз булса, рәхәт булыр иде. Миңа калса, парламентның яртысы хатын-кызлардан торырга тиеш. Әмма беркайчан да болай булмаячак, кадерлем!»

Мэрилл Стрипп, Голливуд актрисасы.



Бүген без сайлау хокукына ия, югары белем алабыз, бала табуны контрольдә тотабыз, эшлибез, милек хуҗасы була алабыз, сәясәт һәм спорт белән шөгыльләнәбез, җитәкче вазыйфада утырабыз – болар барысы да феминизм хәрәкәте нәтиҗәсе. Кадерле хатын-кызларыбыз, әгәр сезнең «феминизм» төшенчәсенә тискәре мөнәсәбәтегез бар икән, беренче җөмләне ашыкмый гына яңадан укыгыз. Кадерле ир-атларыбыз, әгәр сезнең арада феминизмны «ир-атларга каршы көрәш» дип аңлаучылар бар икән, патриархаль җәмгыять белән матриархаль җәмгыять турында мәгълүмат сорап, Гуглга мөрәҗәгать итә аласыз.

Бер яклап караганда, XXI гасырда феминизмның кирәге дә калмады кебек инде. Һәрхәлдә, безнең илдә. Россия Федерациясе Конституциясенең 19 нчы, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 нче маддәсенең өченче пунктында «Ир-ат һәм хатын-кыз тигез хокукларга һәм ирекләргә, аларны гамәлгә ашыру өчен тигез мөмкинлекләргә ия», дип язылган.

Икенче яклап караганда, феминизм буенча ачыклык кермәгән сораулар күп кала икән әле. Бу мәкаләдә шул сорауларның кайберләренә җавап бирербез.

Инде бар да тәртиптә кебек, хатын-кызларга тагын ни җитми?

1 Татар феминизмы бармыни соң ул?

Әлеге мәкаләләр циклын башлаганда ук туган иде бу сорау. Беренче дулкын, икенче дулкын, өченче дулкын булып күтәрелгән феминизмда безнең татар кызлары да катнашканмы? Әллә «татар кызларына алай килешми» дип читтә калганмы? Юк, әлбәттә.

Алдынгы карашлы татар хатын-кызлары XIX гасыр ахырында–XX йөз башында мәктәпләр, гимназияләр ачкан, хәйриячелек белән шөгыльләнгәннәр (Фатиха Аитова, Мәрьям Акчурина-Солтанова һәм башкалар), газеталар чыгарганнар (Зөһрә Акчурина), сайлау хокукы алганнар (Мөхлисә Бубый дөньяда беренче булып казыя итеп сайлана) һәм югары белем алганнар (Сара Шакулова чит илгә барып укып кайта). Татар хатын-кызларының ул вакытта ук инде күчемсез милеккә хокуклары булган. Күрүебезчә, кайбер җәһәттән алга киткән илләр арасында да беренче булган алар.

Әгәр феминизмны яхшы мәгънәдә «хатын-кызларның үз хокуклары өчен көрәше» дип аңлыйбыз икән, татар хатын-кызларына бу хокуклар өчен көрәшергә кирәкмәгән дә диярлек. Бу хәрәкәтне татарның җәдиди карашлы зыялылары үзләре җанландырып җибәргән. Бу татар феминизмының, ягъни «хатын-кыз мәсьәләсе»нең үзенчәлекле бер ягы. Миңа калса, без горурланырлык ягы. Шәхсән үзем татар феминизмы, зыялы ир-егетләр белән бер сафта партнерлык дәрәҗәсендә барлыкка килгәнгә, Көнбатыштагы кебек радикаль һәм богема төсмерен алмый калгандыр дигән фикердә.

2 «Татар феминисткасы» милләт анасы буламы ул?

Бу сорауны миңа гыйнварда ук биргәннәр иде. Төрки халыкларның тарихи шартларда формалашкан социо-мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, безнең халыктагы «ир – баш, хатын – муен» дигән гаилә моделе буенча мин, милләт анасы дигәндә, үз милләтенә тугры калган балалар үстерүче әниләрне күз алдына китерәм.

Шул ук вакытта 1990 нчы елларда халкыбыз үз дәүләтчелеген булдыру максаты белән милли республика төзүгә таба адымнар ясаганда, ир-атлар белән бергә күренекле хатын-кызлар да алгы сафка чыкты. Вафирә апа Гыйззәтуллина, Фәүзия апа Бәйрәмова, Гөлзадә апа Сафиуллиналар зур һәм җаваплы эштә ир-егетләргә терәк була алуларын исбатлады.

Милләт анасы дигәннән, язучы, җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмованың татар хатын-кызларының нинди булырга тиешлеге турындагы бер әңгәмәсендә әйткән фикере «милләт анасы» билгеләмәсенә күбрәк туры килә: «Хатын-кызда беренче урынга әхлакны, миллилекне куям. Безнең татар хатыны гыйлемле дә булган, телне дә, тарихны да белгән, киенә дә белгән. Бөтен яктан үрнәк булганнар». Мондый бурычларга җавап биргән хатын-кыз «феминист» булудан бигрәк, беренче чиратта «милләт анасы» була, әлбәттә.

3 Бүген татар кызлары феминизм хәрәкәтендә катнашамы?

Күпмедер дәрәҗәдә феминистик карашларны яклаучылар булса да, ачыктан-ачык феминизм хәрәкәте оештырып, актив чараларда катнашучы татар кызлары турында ишеткән юк.

Шул ук вакытта Татарстанда, татарлар яшәгән төбәкләрдә хатын-кызларның күпсанлы иҗтимагый оешмалары эшләп килә. Алар хатын-кызларны милли рухта тәрбияләү эшен башкарып, нәкъ менә «милләт аналарын» тәрбияләү эшен алып баралар. Ике елга бер тапкыр Бөтендөнья татар конгрессы татар хатын-кызларының җыенын үткәреп, алар үзләренә алга таба эшләү өчен резолюцияләр, эш планнары кабул итә. Еш кына татар хатын-кызлары, аларның бүгенге җәмгыятьтә нинди булырга тиешлеге хакында түгәрәк өстәлләр оештырыла. Бу җәһәттән әлеге оешмалар мультикультурализм һәм глобальләшү шартларында үзбилгеләнүгә йөз тота, хатын-кызлар хокуклары турында сүз кузгатмый, дөньякүләм феминизм хәрәкәтенә тәгаен өлешен кертми.

4 Бүген феминисткалар нәрсә даулый?

Бу сорауга җавап бирү өчен БашФем, ягъни Башкортстан феминисткалары хәрәкәте активисты Таңчулпан Буракаевага мөрәҗәгать иттек. Ул безгә түбәндәгеләрне сөйләде:

– Безнең хәрәкәттә феминизмның төрле юнәлешләренә караган феминисткалар бар, чөнки төркемебезнең максаты – аерым-аерым эшчәнлек алып барган фикердәшләребезне берләштерү. Радикаль, либераль, интерсекциональ, анархо-феминизмның төрле юнәлешләренә караган кешеләр җыелган, кайчак фикер уртаклыгы таба алмаган, бәхәскә кергән очраклар да була, әмма максатларның бер икәнен аңлап, барыбер бергә эшләүне, берләшүне дәвам итәбез. Киләчәккә планнар зур. Россиядә рәсми рәвештә ике җенеснең хокуклары да бер иш күренсә дә, чынбарлыкта хатын-кызларның проблемалары бихисап. Мәсәлән, күптән түгел гаиләдә кул күтәрүнең беренче очрагы өчен җәза җинаять кодексыннан административ кодекска күчерелде, ягъни хәзер ир беренче тапкыр кул күтәреп, хатыны аны судка бирсә, алар бергәләшеп гаилә бюджетыннан дәүләткә штраф түләячәк. Күп очракта җәберләнгән хатын-кыз кая мөрәҗәгать итәргә белми, төн уртасында гауга чыкканда, качып китәргә урыны булмый.

Ир-атларны инфантильлектән коткару кампаниясен башларга кирәк.

Ркаил Зәйдулла

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА, язучы:

– Хатын-кыз өчен гаилә беренче чиратта торырга тиеш. Мин бу фикерне һәрвакытта да әйтә килдем. Хатын-кызның иң зур бәхете гаиләле булуда, балалар, алга таба оныклар үстерүдә. Бары тик шул гына хатын-кызның бәхетен түгәрәкләп куя. Безнең арада да үзен иҗатка гына багышлыйм дип, иреннән аерылган хатын-кызлар булды, әмма алар ямьсез картайды.

Мин әдәбиятка килгәндә, безнең ир-ат язучылар арасында «хатын-кыз язучы гына» итеп караучылар булды. Рус язучылары Анна Ахматованы да, Белла Ахмадуллинаны да зурлап «поэт» дип йөртте. Ни өчендер татар язучылары әдәбиятны җенескә бүлеп карый. Югыйсә әдәбиятта җенесләр юк. Әдәбият ул җенескә түгел, ә талантка бәйле. Алайга китсә, бүген әдәбиятны хатын-кызлар җигелеп тарта...

Шулай ук безнең мәдәнияттә сексуаль җинаятьләргә карата мөнәсәбәт бик сәер. Кызны көчләсәләр, игътибар фокусы ни өчендер җинаятьчегә түгел, ә кызның шәхесенә юнәлтелә: ул үзен ничек тоткан, нинди кием кигән һәм башкасы. Бу борынгыдан килә: элгәре көчләнгән кыз кияүгә чыга алмаган, бозык саналган. Ә бит аның бер гаебе дә юк, җинаятьне бит ул эшләмәгән!

Эш урынында дискриминация очраклары да җитәрлек:

- «пыяла түбә», ягъни хатын-кыз карьера баскычы буйлап аерым бер югарылыкка җитә ала, алга таба аның мөмкинлекләре кимегәннән-кими. Районнардагы хакимият башлыкларын гына алыгыз: кайсында хатын-кыз соң?
- гомумән алганда, хатын-кызларның эш хакы ирләрнекенә караганда, 30 процентка азрак;
- әйбәт эш урыннарына хатын-кызларны алмаска тырышалар, чөнки аның декрет ялына чыгуыннан, аннан соң бала белән дәваханәләрдә ятуыннан куркалар. Алдынгы илләрдә бала карау, хатын-кызларның гына эше түгел, ирләргә дә кагыла. Бездә исә бала тәрбияләү хатын-кыз җилкәсенә генә төшкән авырлык булып кала. Ирләр ярдәм иткән очракта да, финанс ярдәме белән генә чикләнә диярлек;
- финанс ярдәме турында сүз чыкканда, алимент түләмәүчеләр турында да әйтми мөмкин түгел.

Болар Россия һәм төбәкләрдәге хатын-кыз проблемаларының бер өлеше генә. Феминисткалар елдан-ел агарту эше белән шөгыльләнә, халыкның феминизмга булган мөнәсәбәтен үзгәртергә тырыша.

5 Ә мин үзем феминисткамы?

Феминизм тирәсендәге бик күп яңа термин-төшенчәләрне «киеп» караганда, антифеминист түгелмен. Идеаллаштырылган феминизмга якынрак, дип саныйм. «Сестринство» дип атала ул. Ягъни мин – үзебезнең кавемгә теләктәш. Моннан аңлашылуынча, сексист түгел. Сексистларның хатын-кызлар табигать тарафыннан ук ир-атлардан түбән итеп яратылган, дигән карашын якламыйм. Бер генә мисал китерәм: дөньяда иң югары IQ теркәлгән ике очрак бар, шуларның икесе дә – хатын-кыз.

Безне кечкенәдән «кызлар – матур, малайлар – акыллы» дип үстерделәр. Балаларымны «кызлар матур да, акыллы да була» дип үстерәм.

Матурлык дигәндә, конвенциональ матурлык яклы түгел. Минемчә, һәркем үзенчә матур. Шуңа да бүгенге җәмгыятьнең ихтыяҗларына җавап бирергә тырышып, тышкы кыяфәтемне үзгәртмим. Ничек бар, шулай мөнә...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, шагыйрь:

«Татар феминизмы» дигән төшенчәне ишеткән юк. Феминизм – безгә русларга ияреп, Көнбатыштан кергән агым ул. Татар язучылары татар хатыннары турында бик күп әсәрләр язган. Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән әсәре, мәсәлән. Минем карашка, анда кайнана образы беренче планга чыга. «Оҗмах әниләр аяк астында» дигән хәдис тә бар.

Татар хатыннарын изелеп яшәгән дип уйламыйм. Ә менә «тигезлек» дигәннәре җәмгыять корылышының тез астына сукты дип уйлыйм. Тигез булабыз дигән хатын-кызларга урман кисәргә, күмер чабарга туры килде хәтта. Миңа калса, хәзер инде ир-атлар тигезлеге турында сөйли башларга вакыт.

Гомумән, бу мәсьәләдә карашым бер генә төрле минем: ир-атларның үз урыны, хатын-кызларның үз урыны. Хатын-кызларның бурычы – бала табу.

Ни өчен шулай килеп чыккандыр, татар тормышында хатын-кыз ирегә тискәре роль уйнады. Ә бит милләтнең киләчәге хатын-кызлар кулында. Мәсәлән, рус хатын-кызлары динен, милләтен аңлыймы-юкмы, әмма аның өчен чәчрәп чыга. Ә татар хатын-кызлары бик тиз үз позицияләрен бирә: азмы чит милләткә ул-кызлар үстереп биргән татар хатыннары?

Гадәттә, милләткә куркыныч янаганда, хатын-кызлар алга чыга. Мәсәлән, Фәүзия Бәйрәмовалар нәкъ шундый вакытта күтәрелде дә. Алар дөньяны аңлый белә. Андый хатын-кызлар булу – милләт тегермәненә су коя.

ЧИРМЕ, ХОЛЫКМЫ?

Өйләнешкәнче, ирем саран кеше кебек түгел иде. Кысмырлыгын, балабыз туып, өйдә утыра башлагач тойдым. Бала тиз үсә, кием-салымын да гел алып кына торасы, уенчыклары да кирәк, башкасы да. Декрет акчасын гына җиткерерлек түгел. Ә нәрсәдер алу өчен иремнән акча сорау бер бәлагә әверелде. Акча дигән сүз чыгуга, кашы җимерелә. «Ай-яй, туздырырга яратасың да инде», – дип битәрли. Кирәкмәгәнгә туздырмыйм да бит югыйсә. Иң-иң мөһим әйберләрне генә сатып алам, ләкин ирем барыбер ачулана. Аның шушы саранлыгы белән ничек көрәшәсе?

Раил САДРИЕВ, Татарстанның халык артисты, Буа дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе-директоры:

Саранлыкны берничек тә дәвалап булмый. Ул – чир кебек. Төгәлрәге, чир түгел, ә генетик код. Кеше туганда ук саран булып туа. Ләкин бу ситуациягә төрлечә карарга була. Ир кеше гаиләне берүзе туендырса, акчаны санамый да булмый. Кысмыр кеше үзен беркайчан да саран дими. Рәшит Шамкай әйтмешли: «Мин саран түгел, сакчыл», – диячәк. Акчамны бүген туздырып бетерсәм, иртәгә ничек яшәрмен, дип уйлый ул, кара көнгә дип җыя. Ләкин шул рәвешле үзенең һәр көненнән «кара көн» ясый. Бу – бәрәкәтсез акча. Үзем өчен бер ачыш ясаганым булды: гомер буе акча җыючы кеше бер көнне акчасын туздырырга керешә икән, ул озак яши алмый. Иркен яшәргә яраткан мут кеше дә шулай: акча җыя башласа, озак яшәми.

Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА, Татарстанның атказанган артисты:

Бу – күп кенә гаиләләрдә очрый торган хәл. Хатын-кыз бала табып, өйдә утырганда керем кими, тормыш күбрәк ир-ат җилкәсенә генә кала. Моңарчы саран булмаган кеше дә мондый чакта сакчылга әйләнә. «Икенче юлы акчаны белебрәк тотсын, ул сораган саен чыгарып салмыйм әле», – дип тә уйларга мөмкин. Әгәр дә ир кешедә электән үк патологик саранлык булмаса, моңа узгынчы хәл дип кенә карарга, сабыр итәргә кирәк. Әлбәттә, яңарак кына бала тапкан хатын-кызның күңеле бик нечкә була. Аның үзен сөйдереп торасы, иркәләнәсе килә. Матур әйберләргә дә күз төшә. Ләкин моңа вакытлыча итеп карарга кирәк. Ирләрнең күбесе бер әйтү белән «егылып» төшми. Ул шулай дип әйтте дип кенә кырт өзәргә ярамый. Ир кеше, сукрана-сукрана булса да, барыбер син дигәнне үти инде ул.

Белгеч фикере



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

Ир-атның безнең өчен нәрсәдер эшләвен телибез икән, үзебезне хатын-кызларча тотарга өйрәнергә кирәк. Кияүдәге ханымны руслар «замужем», диләр. Димәк, ул – ире артында торучы. Артында булмаса, һичьюгында рәттән баручы, ләкин алдан йөгерүче түгел.

Хатын-кыз ир-ат белән идарә итә, аңа боера башлый икән, бу – сугыш мәйданына аяк басу. Ирләрнең колы булырга кирәк димим. Тормышта хатын-кызга дипломат булырга, иренең абруен төшермичә, балаларына да әтиләренең кирәклеген төшендереп торырга туры килә. Хатыны ихтирамын тойган ир-ат (холкында патологик җитешсезлекләр булмаганда) үзе дә аны югары бәяли. Нәтиҗәдә, теләгәнебезгә ирешәбез. Әгәр дә моңа ирешә алмыйсыз икән, нәрсәне дөрес эшләмим дип үзегездән сорагыз. Үзара мөнәсәбәтләр – көзгедәге чагылышыбыз ул.

Ир-атта кысрыклап чыгару механизмы дигән нәрсә бар. Үзенә ошамаган нәрсәләрне ул аңыннан кысрыклап чыгара. Әйтик, балаларга игътибар бирмисең, дип гаеплисез икән, ул моны кабул итми. Әгәр дә, улыбыз син игътибар күрсәткәч, шундый шатлана, син алган теге уенчыгына сөенеп бетә алмады, дисәгез, менә монысы хәтерендә кала, һәм ул шул юнәлештә алга таба бара. Кайда игътибар, шунда энергия. Энергия булган җирдә – нәтиҗә.

Бер танышым гел иренең өй башмакларын киеп йөри иде. Иренең моңа ачуы килә, хатынын битәрли. Ә анысы назлы гына итеп: «Ник, мин дә синеке бит инде», – ди. Балаларына кием аласы булса да: «Кем баласы дигәндә, синең балалар, диячәкләр. Әнә Нәфисә (исемнәр үзгәртелде, – авт.) килә димиләр бит, Дамирның кызы килә, диләр», – дип, бик үтемле итеп әйтә белә ул.

Үз ихтыяҗларың турында дөрес итеп әйтә белү дә мөһим. Кемдер мәгълүматны колак аша кабул итә – аудиаль була, кемдер визуаль – күз алдына картина килсә генә мәгълүматны сеңдерә ала, кемдәдер кинестетик кабул итү төре – аның өчен тоем мөһим, ә кемдер мәгълүматны компьютер кебек кабул итә – тиз, аңлаешлы, артык сүзләрсез. Ирегезнең нинди төргә караганын ачыклап, гозерегезне дөрес итеп җиткерү дә мөһим дип әйтәсем килә.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.



МӘСКӘҮ ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘ



Ул – Мәскәүнең үзәгендә, Таганская метро станциясеннән ерак та түгел, Большие каменщики урамындагы 2 нче йортта урнашкан. Зур холл. Диварлар рәссамнар картиналары белән бизәлгән. Тәрәзәләрдә – гөлләр. Монда рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр, баянга кушылып җырлыйлар, бәлеш, өчпочмаклардан авыз итәләр, якташлары белән гәпләшеп утыралар. Татар мохитенә хас җылылык, үзенә бер ямь сирпелә анда, китәсе дә килми. Исеме дә үзгә – «Татар штабы». Хәрбиләрчә, штаб дип йөртүләре дә тикмәгә генә түгел. Татар халкының телен, традицияләрен, мәдәниятен саклап калу һәм үстерү юнәлешендә зур максатлар куеп, армый-талмый эшләүче фидакарьләрне туплаган оешма ул. Аның чишмә башы 90 нчы елларга барып тоташа. Бүгенге героебыз Гөлнара ЯРУЛЛИНА – әнә шул оешмага яшьләрне тартып, яңа проектлар уйлап табучы, шуларны тормышка ашыруда янып йөрүче замана кызы. «Татар штабы»ның координаторы, татар яшьләрен бергә туплый, аларны илһамландыра һәм канатландыра белүче чын лидер. Яшьләр үз милләте, тарихы белән горурлансын, бер-берсенә таяныч булсын өчен җан атып йөри. Әйдәгез, Гөлнара белән якыннанрак танышыйк.

Эльмира ЗАКИРОВА

Татарлар белән аралашып, аларны үзенә ияртеп кем йөри дисәләр, Гөлнара булыр ул!

Казан кызы Мәскәүне яулый

Шаян телле, чая, тиен кебек җитез, күбәләк кебек җиңел, тәвәккәл һәм тиктормас. Спорт ярата: йөгерү марафоннары, тау чаңгылары, теннис... Ул барысын да колачлый. Гөлнараның кермәгән тишеге, белмәгән кешесе юктыр бу зур мегаполиста! Метрода Пролетарскаядан Таганскаяга кадәр генә барасы, бер атлый, ике сикерә – инде Штабта ул. Туктаусыз хәрәкәттә: йөгерә, чаба, тегесен таба, монысын хәл итә... Татарстан Республикасының Россиядәге Вәкаләтле вәкиллегенә ашыга, Муса Җәлил исемендәге татар мәктәбенә барып чыга, студентлар белән Җәлилнең кызы Чулпан ханым фатирында була, гастрольләргә килгән Камал театры артистларын Штабта кунак итә... Туган тел язмышы турындагы сөйләшүләргә күренекле язучыларны, сәясәтчеләрне чакыра. «Уртак фикер» дискуссион клубында Римзил Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиев, Рәшит Әхмәтов, Рауль Мир-Хәйдәров, Шамил Идиатуллин белән очрашулар үтә. Штабның дәрәҗәсе бермә-бер артты хәзер. «Татар штабы»ның сулышы – социаль челтәрләрдә: инстаграмда да, ВКонтактеда да, фейсбукта да, штабның ютуб-каналы бар. Интернет-ресурсларны яңартуга шактый вакыт китә, әлбәттә. Каян яңа хәбәр алырга, нинди мәгълүмат бирергә дип баш ватмаган, эзләнмәгән чагы юк бу тынгысыз җанның.
Ә без социаль челтәрләрдән аларның бөтен яңалыгын белеп торабыз. Коломнада Җәлил укулары узган... Татар мәдәнияте музее ачылган... Ришат Төхфәтуллин концертына барганнар... Тукай һәйкәленә чәчәкләр салачаклар... ТАССР төзелүнең 100 еллыгына әзерлек чаралары күрә башлаганнар... Валерия Порохова ислам, фән, мәдәният темасына лекция укыган... «Дустыңны да Сабантуйга алып кил!» акциясенә кушылып, 700 ләп яңа кеше килгән... «Беренче намаз» проекты яшьләргә ошый... Эшләгән эшнең нәтиҗәсе дә күзгә күренерлек шул: штабның хәзер ике меңләп активисты бар.
Дус кызлары кайчак үпкә дә белдерә: «Син кайчан карасаң телефонда!» – диләр. Ә аңа башкаларга булышу бик ошый! Ел саен Мәскәү вузларына Татарстаннан йөзләгән егет-кыз укырга керә. Аларны мегаполиска җайлашырга өйрәтергә кирәк, үзләрен ялгыз итеп тоймасыннар. Медицина институты студентлары өчен «Гиппократ» клубы эшли, атаклы табиблар катнашында очрашулар үткәрелә. КВН командасы булдырылды, «Татар мафиясе» уены клубы эшли башлады. Эшмәкәрләр өчен – «Масштаб» клубы, тарихчылар клубы, Аксакаллар шурасы... «Аулак өй» клубы да бик популяр: йөзләп кеше җыела анда. Көрешәләр, танышалар, кавышалар. Бер елда әнә ун татар гаиләсе туды. Кайчак Гөлнараның үзенә дә яучы ролен башкарырга туры килә. Әйтүенә караганда, кемгә нинди кеше туры килгәнен тоемлау сәләте бар икән. «Анара белән Мигель менә дигән пар инде, үзләре генә белми», дип, ул аларны якыннанрак таныштыра. Кулы җиңел булып чыга: озак та үтми егет белән кыз өйләнешә.

«Безнең Гөлнара ул юрист та, киңәшче дә, экскурсовод та, «Ашыгыч ярдәм» дә, спортчы да, дипломат та... Барысын булдыра!» – диләр аның турында. Спорт дигәннән, Татарстан спорт командаларының фан-клубын да җитәкли әле. Ул бөтен җирдә! «Ак Барс», «Нефтехимик», «Рубин» «Динамо»... Берсенең дә уенын калдырмый җанатарлар.

17 ноябрьдә «Ак Барс» белән «ЦСКА» матчына бара яшьләр. Арена җитәкчеләре белән алдан килешеп, Мәскәүнең «Шүрәле» төркемен стадионда таймнар арасындагы тәнәфесләрдә татарча җырлатырга сөйләшә Гөлнара. Мондый хәлнең әле булганы да юк моңарчы! Берзаман трибунадан татарча: «Гөлнара, сине туган көнең белән котлыйбыз! Бу җырыбыз – сиңа!» – дигән сүзләр кайтаваз булып яңгырый. Кызның үз туган көнендә нинди эйфория кичергәнен аңлыйсыздыр! Биш мең кешене сыйдырган стадион гөрләп тора. «Сине генә көтәм, сине генә сагынам, сине генә кил ә күрәсем...» дип җырлый ансамбль, бөтенесе күтәреп ала! Менә нинди көч бит алар! Мәскәүне ярата Гөлнара! Арбат, Тверская урамнары, Измайлов паркы... «Россия» кунакханәсе урынында хәзер «Зарядье» паркы, искиткеч матур! Татар милли киемнәрен киеп, калфагын кыңгыр салып, Кызыл мәйданнан да узганы бар. Әйләнеп-әйләнеп карыйлар бу сылу кызга. Кайсы милләттән булуы белән кызыксыналар. «Мин – татар кызы!» – ди ул балкып.



Фото: Анна Арахамия

PRESSA

«Һәр татар кешесе анда үзен өйдәге кебек рәхәт бер халәттә тоя.»

Сусау

Кем соң бу Гөлнара, нишләп Мәскәүгә килергә уйлаган, татар дөньясына ничек тартылган? Үзенә дә шул сорауны бирдек.

– Мин – Казан кызы. Башта технология университетында программист булырга укыдым, аннары икътисад буенча икенче югары белем алдым. 3 нче курста ук банкта эшли башладым. Биш ел эшләп тә карьера үсеше күренмәгәч, башка җиргә күчеп карарга булдым. Зур консалтинг компаниясенә бухгалтер булып урнаштым. Ләкин һаман канәгать түгелмен. Шунда аңладым: миңа кешеләр белән аралашу җитми икән! Бу стеналар минем өчен тар икән! Казан ничектер кечкенә тоела башлады. Мәскәү шундый зур, матур, үзенә тартып тора! Минем һәрвакыт Мәскәүгә китәсем килә иде. Җае да чыкты. Дус кызым Алсу туган көненә чакырды. Ул бер ел элек шунда киткән иде. Сәяхәтем башыннан ук мажараларга төренгән булып чыкты. Башта поездга соңга калдым. Ничек итсәм иттем – танышларым аша табып... КамАЗ машинасында утырып киттем башкалага! Әти белән әни бу хакта әле дә белми бугай. Туган көн сәбәп кенә иде инде. Мәскәү гел кызыктырып, ымсындырып торды бит. Бу килүдә бер-ике атна яшәп карадым да өйдәгеләргә: «Мин монда калам!» – дип шалтыраттым. Әниләргә шок була язды! Бер дә җибәрәселәре килмәде инде. «Ничек инде каласың? Нәрсә эшлисең? Кайда яшисең?» – дип тәмам пошаманга төштеләр. Әти ягыннан туганнарны эзләп табарга, шуларга барырга куштылар. Мәскәүдә эш табу җиңел түгел. Син анда беркемгә кирәкмисең. Үз-үзеңне табарга кирәк. Минем инде тәҗрибәм бар: банкта эшли башладым. Шунда яшәгәндә аңладым: миңа үз татарларым бик якын икән. Туган якта түгел, мең чакрым читтә үз телемә, үз моңыма сусау тойдым мин. Үзебезнең татарларны эзләп табасым, алар белән рәхәтләнеп сөйләшәсем килде. Мәскәүдә татарлар күп дип ишеткән бар иде инде. Ләкин күбесе Нижгарныкылар – Сергач мишәрләре анда. Үзебез өчен генә татарларның санын алып караган идек, нижгарлар күбрәк килеп чыкты. Түбән Новгород Мәскәүгә якынрак бит, бәлки, шуңадыр... Аларның сөйләшүләре дә башкачарак, безнекеннән аерыла. Метрода йә транспортта барганда кайчак Казанча сөйләшүләр колакка керә. Сөенүләрем! Ул инде җыр кебек яңгырый! Тамагыма төер тыгыла. Сез кайдан, дип, тизрәк яннарына ашыгам. Чаллыдан, диләр. Белсәгез иде ничек рәхәт булып киткәнен. Эчемнән генә татарча җырлар да көйләп йөрим әле. Бәләкәйдән җырлы өйдә үстем бит. Әнием Иркия тумышы белән Сарман ягыннан, Кужак авылыннан. Әтием Ринат – Әлки районы Яңа Чаллыдан. Без һәрвакыт кунаклар җыя, мәҗлесләрдә татарча җырлап утыра идек. Әни үзе баянда уйный, үзе җырлый, үзе тамада булып туган көн, юбилейларны алып бара. Җитмәсә, тәмле бәлешләр дә пешерә әле. Әти дә әнигә кушылып җырлый. Миңа да шул сыйфатлар күчкән, ахрысы. Энем Линарга да... Ул шәп баянчы.





Яшьләр аеруча яратып йөри Штабка! Горурланырлык эшләре дә, яңа проектлары да байтак. Һәм алар барысы да бер максатка – татар милләтен яшәтү, саклап калу, үстерү максатына юнәлтелгән. Татар дөньясы кайнап тора монда.

Ләкин... Казанда чакта татар телендә генә сөйләшеп, татар дөньясында кайнап яшәдем дип әйтә алмыйм. Авылга кайтсам, минем сөйләшүдән көләләр. Ә студент елларында татарча сөйләшүчеләргә авылныкы дип мыскыллап карау бар иде. Шуңа принципиаль рәвештә татарча сөйләшмәдем. Мәскәүгә күчеп ике-өч ел яшәгәч кенә татар теле кирәген аңладым. Миңа татарлар белән аралашу җитмәгән икән бит! Бөтенләй ачылып киттем. Ә ул болайрак булды.

Мин Штабка килдем

29 август иде. Матур кояшлы көн. Казаннан килгән татар егете Артур дус кызым белән мине бер мәҗлескә чакырды. Килегез, анда татаралар җыела, ди. Бергәләп «Заман» кафесына бардык. Һәм анда Рөстәм абый белән таныштык. Рөстәм Фәиз улы Ямалиев белән! Аның туган көне иде. Бер белмәгән кешенең туган көненә барып керү безнең өчен сәеррәк иде, әлбәттә. Ә Артур кыстапмы-кыстый: «Әйдәгез-әйдә, ул яңа кешеләр алып килгәнне ярата. Җитмәсә, сез әле Татарстаннан, үзебезнекеләр», – ди. Рөстәм абыйның «Татар штабы» җитәкчесе икәнен шунда аңладым. Ул бөтен татарларны шулай үз тирәсенә җыя икән Мәскәүдә. «Килегез, бергәләп сөйләшеп, җырлашып, чәйләр эчеп утырырбыз», – дип чакыра һәрвакыт. Ул көнне дә кунаклар күп иде. Бөтенесе котлый, ә без нәрсә әйтергә дә белми оялып утырабыз. Юк, ул туган көн тантанасы ясамады, бәйрәмен татар милли мәдәнияте кичәсенә әйләндерде. Заманында Табиев белән бергә Мәскәүдә шушы оешманы оештырып, яшьләрне үз артыннан ияртеп йөрүчеләрнең берсе ул. Гаҗәп акыллы, әйбәт энергетикалы, зирәк җитәкче. Чын милләтпәрвәр. «Нижнекамскнефтехим»да җаваплы вазыйфалар башкарган, атаклы Николай Лемаев белән бергә эшләгән. Милләт язмышы өчен борчылучы буларак, үзен Азат Зыятдинов шәкерте дип атый. Түбән Камада алар татар милләтенә хезмәт иткән кешеләр. Табиев чоры турында Рөстәм абый әле дә легендага тиң истәлекләр сөйли.

Фикрәт Әхмәтҗанович Табиевның ТАССР партия өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән елларын өлкән буын яхшы хәтерлидер. 20 ел буе республиканы җитәкләгән, аның икътисадый потенциалын күтәргән абруйлы җитәкче диләр аның турында. 90 нчы елларда Мәскәүгә күчеп килгәч, ул үз тирәсенә башкалада яшәүче татар элитасын – танылган шәхесләрне, эшмәкәрләрне, сәясәтчеләрне, табибларны җыеп, «ДЛ-16» («Эшлекле кешеләр-16») клубын эшләтеп җибәрә. Кеше минутына 16 тапкыр тын ала, исеме шуннан...

«Татарстан үз-үзен аямый эшли торган намуслы, тырыш кадрлары белән данлыклы, ди иде Фикрәт Әхмәтҗанович, һәм аларның биредә дә үзләрен табуларын тели иде, – дип искә төшерә Рөстәм Фәизович. – Якташлар кичәсе башлануга, Табиев торып баса. Ә яшьләрнең күбесе аны беренче тапкыр күрә. Ул аларны кыздыра башлый: «Кайда эшлисең? Нигә начальник түгел? Нәрсәгә ирештегез? Эшкә бер сәгатькә алданрак киләсеңме, син алданрак килергә тиеш, чөнки син Татарстаннан! Ник арагызда депутатлар юк? Ник олигархлар юк?» Татарстаннан чыкканнарның зуррак уңышларга ирешүләрен теләде ул. «Безгә Мәскәүне алырга кирәк! Мәскәү безнеке булырга тиеш!» дип канатландыра иде халыкны. Аның принциплары берничә иде: кадрлар, үзеңне аямый эшләү һәм бер-береңә ярдәм итү».

Мәскәүне алу – бизнес белән шөгыльләнү дигән сүз икән. «Эшмәкәрлекне үстерегез, баегыз. Ник сез Forbesта түгел? Нигә депутатлар, министрлар юк арагызда?» – дип гел әйтә килгән обком секретаре. Клуб шактый эшләр башкарган, күпләргә булышкан ул чакта. Хәзер дә Штаб кадрлар сәясәтен, милли мәсьәләләр идеясен тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

Менә шундый программа белән эшли Гөлнара һәм аның Штабтагы дуслары, фикердәшләре. Руслан, Марат, Эльвира, Фәридәләр... Алар – Гөлнараның ышанычлы терәге. Татар халкының үсеш стратегиясе буенча татар җәмәгатьчелеге белән «түгәрәк өстәл» оештырганнар. Милли мәгариф, милли мәдәният турында фикерләр аеруча күп яңгыраган. Тәкъдимнәрен Бөтендөнья татар Конгрессына юллаганнар.

Яңа планнар, проектлар байтак. Мәскәү янында татар бистәсе дә төзелер. Анда татар мәктәбе, клуб, балалар бакчасы да булыр. Мәскәүнең үзендә татар театры да ачылыр. Мондый фидакарьләр белән теләсә нинди хыялны тормышка ашырып була!

Ә Мәскәү, чынлап та, татарча сөйләшә!
















Marshall



СӨЕНДЕРЕП ЯШИК ӘЛЕ!

Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

– Раяз улым, ал әле тальяныңны, менә бу җырны җырлыйсым килә... Лəлə әби шук оныгын тыңлатуның иллә дә мәгәр үтемле бер җаен белә: утыртып куя да гармун уйната, үзе җырлый. «Таулар юлы», «Яшь гомер», «Олы юлның тузаны», «Син кайтмадың», «Кайтырсың шикелле тоела» кебек моңлы җырлар белән шуклыклар онытыла, кая ул, дөнья бөтен мәшәкатьләре-ние белән учта тәгәрәтеп йөртердәй генә булып кечерәеп кала. Балтач районы Нөнәгәр авылының Фасыйховлар яши торган өе чын сәхнәгә әйләнә. Шулай әйләнә-әйләнә Фасыйховларның биш балалы ишле гаиләсендә уртанчы уллары Раяз Нөнәгәр сәхнәсенә чыга, аннан соң район, шәһәрләр, чит илләрнекенә... Җыр сукмагының шактый күп чакрымнарын (җыр конкурсларына чыгып киткәндә, унар чакрымнарга җитә) җәяү үтәргә туры килә. Кайчак юлда очраган машиналарны туктатып, кайчак автобуста... Арча көллияте, Казан мәдәният университеты. Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор дәүләт ансамбле, «Барс-Медиа» ширкәте... Шыгрым тулы заллардагы концертлары. «Үзгәреш җиле». Алда Карнеги-холл көтә...

Нөнәгәрнең җырлы нигезе

– Өйгә без инде гармунда тәмам уйнарга өйрәнеп кайта идек, аңа кадәр иске мунчага төшеп уйныйбыз. Беркем ишетми, ялгышларыңны беркем төзәтми. Көйне өйрәнеп бетергәч, өйгә кайтып уйнап күрсәтәсең... – Әтисе Наил абый белән әнисе Илсөяр апа эшкә киткәндә язып калдырган «нәрәт» кәгазе буенча тиз генә эшләрен бетерә дә Раяз әнә шулай иске мунчага кереп, гармун тарта. Янәшәдә генә зур казанда кош-кортларга, мал-туарга дигән ботка пешә. Ул арада уртанчы абыйсы Ильяс та үзенә тигән эш чиратын тәмамлаган икән, алар бергәләп уйнарга яки клубка чыгып йөгерәләр. Әтиләре инженер белгечлеге алган булса да, һөнәре буенча озак эшләми, аны клубка мөдир итеп куялар. Раяз күбрәк сәхнә артында үсә: концерт куярга килгән артистлар белән аралашырга, сәхнә кануннарын өйрәнеп калырга өлгерә. Өйләрендә җыр-моңсыз яшәмәсәләр дә, Лəлə әбисе Нөнәгәрнең иң якты йолдызы булса да, әтисе кредитка баяннар ала-ала балаларын уйнарга өйрәтсә дә, Раязны бу гына канәгатьләндерми. Аның музыканы профессиональ дәрәҗәдә өйрәнәсе килә. Әнә бит, еллар узгач, беренче итеп ул әтисе иҗат иткән җырларны башкарды – «Кыр казлары», «Син эзләмә мине» җырлары хитка әйләнде. Әгәр музыкаль белеме булса, бәлки, әтисе тагын да күбрәк иҗат итәр, яңа көйләре онытылып, югалып калмас иде...

Наил абый да, Илсөяр апа да аңлый улларының бу омтылышын. Шуңа да улларының Арчага укырга китүенә каршы килмиләр. Туксанынчы еллар ахыры бу вакытлар, дөньялар әле тынычланып җитмәгән. Һәрхәлдә, тугызны гына бетергән үсмерне тулай торакка урнаштырырга кыймыйлар: Раяз бер ел әтисенең дусты Фәрит абыйларында яшәп тора.

> Сәхнәләрнең күп буласын белә Раяз. Анысына шөкер. Ә менә гаилә бер генә.

Бу бит Мәһдиев укыган Арча көллияте. Ә анда һаман да Мөхәммәт ага тасвирлаган шул рух яши әле. Раяз анда укыганда бер генә минутын да бушка үткәрми. Тәнәфес араларында да баян классына кереп, ноталарга карап, көй чыгара. Кәттәләнеп тә ала.

– «Безне «Арча егетләре» ансамбленә алдылар. Әллә кем булып киттек инде. Имеш, безгә сүз әйтүче юк, кайбер дәресләрдә белмәсәк тә, күз йомалар. Озакка бармады безнең бу «егетлек». Җитәкчебез Марсель абый Фәйзрахманов (хәзер мәрхүм инде) көннәрдән бер көнне безне җыеп алды да бик әйбәтләп кенә тормыш сабаклары бирде. Аннан соң инде ГТО да «нипачум» иде...

Раязның йолдыз чиренә әнә шулай итеп «прививка» ясала. «Аннан соң мин бит кинәт кенә сәхнәгә килеп чыкмадым, әкрен-әкрен килдем. Икенче көнне йолдыз булып уяндым, дип әйтә торган көнем юк», – ди Раяз.

Балаларның сөенечләре, көенечләре вакытында янәшәсендә булу мөһим.

Бүген Раяз Фасыйхов авылга гаиләсе белән кайтып йөри. Әлбәттә, балачакта такыраеп беткәнче уйнаган тау битләрендә, елга буйларында бүген бил тиңентен кычыткан үсүе аны да сагайта, сагышландыра. Кызлар озатып йөрер яшькә җиткәч тә, җен-пәриләр яши дип шомландырган әрәмәлекләр тагын да куерган, чытырманлык баскан кебек. Җәйге айлы кичтә малайлар белән төрле куркыныч хәлләрне сөйләшеп утырганда, чытырт иткән ят тавыш ишетүгә артка борылып карарга да куркып, өйгә кадәр йөгерә торган чаклар да күптән узган инде. Качып кына йомырка салырга ияләшкән тавык артыннан лапас түбәсенә менеп, печән белән түбә арасында кысылып калган чаклар онытылып бара. «Улым, карының ачмадымы?», «Кая, кил әле, өшкереп җибәрим», дип бертуктаусыз кайгыртып торган Ләлә әбисе дә гүр иясе инде аның.

– Нөнәгәр – ныклы авыл әле ул. Без үскәндәге авыл булмаса да, анда үзләренә шөгыль табып, чын итеп яши торган ныклы гаиләләр күп. Шунысы сөендерә... – Җәй көннәрендә авылга кайтканда, Наил абый, Раяз, Рамазан балыкка йөрергә яраталар. Туры килгәндә, Нияз, Ильяс, Рәсим абыйлары да иярә. Хатын-кызлар – апалары, кайнана, киленнәр өйдә кала: балыкчылар кайтуга каз итеннән, аның эч-башыннан өресендә генә кайнап торган тәмле бәлеш пешерәчәкләр...

«Сөендерәсем килә...»

Раязның хыялы чынга аша. Ул бүген хатыны Люция, кызы Венера, улы Рамазан белән Казанда яши. Фатирда түгел, үз йортлары белән.

– Мин көлгә тәгәрәткән кабыклы бәрәңге яратам. Яратам, дию генә аз, сагынам мин аны. Андый вакытта ишегалдына чыгып, мангалда булса да утын ягып, бәрәңге пешереп ашыйм. Ә менә балаларга шуның тәмен аңлатып булмый. Аларга «фри» кирәк. Шуннан ни? Мин аларны көл бәрәңгесе яратмаган өчен ачулана алмыйм бит инде. Бу – аларның заманы. Каршы килеп булмый. – Раязның заманга карата да, балаларга карата да үз фикере, хәтта ки үз педагогикасы дияргә була.

– Бездә күп нәрсәне әни хәл иткән булса да, ул әти карары итеп кабул ителә иде. Мин боларны хәзер генә аңлыйм. Эшем буенча балалар белән күп шөгыльләнә дә алмыйм. Балалар карау күбрәк Люция җилкәсенә төшә. Ул да балаларга «әтиегез» дип кенә тора. Бервакыт гастрольләр озаккарак сузылды. Венера кызым әнисеннән әле тегене, әле моны сорый да Люция еш кына: «Әтиең кайткач», – дип котыла икән. Шуннан бала түзмәгән: «Кайчан кайта соң ул әти? Бәлки икенче әти алырбыз», – дигән. Баланы матди яктан тәэмин иттем дә бурычым үтәлде, дип кенә балалар тәрбиясеннән читләшү дөрес түгел. Ялымны да, буш вакытларымны да гаилә янында үткәрергә тырышам.

– Бала кечкенә вакытта аның хыялы көн саен үзгәреп торырга тиеш. Бүген космонавт булам, дисен, иртәгә – янгын сүндерүче... Моңа каршы килмәскә генә кирәк. Балалар хәзер башка, алар белән югарыдан торып сөйләшү мөмкин түгел, алар белән диалог корып сөйләшкәндә генә уртак тел табып була, – дигән фикердә әти кеше.

– Раяз, кыз баланың әтисе булу ничегрәк? – дим җырчының сәхнәдәге романтик образын күз алдында тотып. Венера турында уйлауга, Раязның йөзе тагын да яктырып китә:

– Мин аңа: «Дөньяда сине мәңге ярата торган бер ир кеше бар: ул – мин!» – дип әйтәм...

– Улыңны да үз үрнәгеңдә тәрбиялисеңме?

– Без әти-әниләрдән күреп үстек, балалар – бездән. Әлбәттә, улымны ир кеше итеп тәрбияләү – минем бурыч. Балачакта минем язуым начар иде. Менә шул Рамазанга да күчкән. Әмма мин аңа карап: «Ярар, улым, мин дә шундый идем, тырышмасаң да ярый», димим. Киресенчә, тырышсын. Минем бит педагогик белемем дә бар. Балага алай дип әйтергә ярамаганны бик яхшы беләм.

...Бигрәк идеаль герой килеп чыкты әле безнең Раяз

– Юк, алай ук түгел. Минем нинди икәнне хатыным Люция белә, – дип каршы төшә җырчы. – Концертлар алдыннан борчылуларыма да, концертлардан соң бушанып калып, сөйләшмичә йөрүләремә дә ул түзә. Түзә дип, ул минем иҗат кешесе булуымны аңлый. Онытылып, яртышар ел буе өйдә ватылган, кителгән берәр әйберне төзәтеп куя алмавыма, мәсәлән, күз йома белә. Яки үзе төзәттерә. Люция бөтенләй башка дөньядан – һөнәре буенча икътисадчы. Шуңа да аның өчен вакыт та бушка үтми. Ул балаларны укырга, түгәрәкләргә йөртә. Венера да, Рамазан да музыка мәктәбенә йөри. Димәк, иҗат кешеләрен үстерә...

Люцияне фольклор ансамблендә эшләгән чакта, «Туган авылым» ресторанында җырлап йөргәндә очрата Раяз: «Йолдызга гашыйк булмады ул. Мине белмиләр, танымыйлар иде әле ул вакытта. Ә менә Люция башкалардан аерылып тора иде. Нәрсәсе беләнме? Аны яулап алырга кирәк иде!»

Һәм яулый да. Чәчәкле-конфетлы чор да була, һәр гаилә уза торган аннан соңгы сынаулар да. Ишле гаилә килене буларак та сынатмый Люция. Әмма кайбер көннәрдә Раяз, иртәрәк торып, эшкә киткәндә калдырган: «Күптән сине сөендергәнем юк иде. Бу – сиңа бүләгем» кебек язуларны һәм бәләкәй генә бүләкләрне кадерләп йөрәк түренә салып бара ул...

TMTV ПРЕМИЯСЕ: 46 ЛАУРЕАТ – 7 СӘГАТЬЛЕК ШОУ!

Мартның ахырында ТатМузТВ телеканалының TMTV премиясе лауреатларын бүләкләү тантанасы булып узды. Бәйрәм киче кызыл келәмнән башланып китте. Традициягә кергән бу чарада җитмешләп җырчы катнашты. Башка еллардан аермалы буларак, ул ачык һавада түгел, ә «Пирамида» үзәгенең фойесында оештырылды. Яраткан башкаручыларын күрергә килүчеләр дә, кызыл келәмнән узучылар да әлеге үзгәрешне уңай бәяләде.

Тантана үзе кичке биштә бәйрәм рухы өстәүче лазерлы бизәлеш астында дәртле бию белән башланып китте. Ниһаять, соңгы ике ай дәвамында тынгы бирмәгән сорауларга җавап табылачак! TMTV-2019 лауреатлары белән танышыр вакыт.

Беренчеләрдән булып «Иң яхшы җыр театры» номинациясендә җиңү яулаган Гүзәл Уразова һәм Илдар Хәкимовны бүләкләделәр. Аннан дәрәҗәле сыннар сәхнәне әле яулап кына килүче яшьләргә – «Бәхетле» төркеменә («Ел ачышы») һәм Рената Тейга («Яңа исем») тапшырылды.

Тәбрикләү өлеше җырлар белән үрелеп барды: «Иң яхшы клип» номинациясенең җиңүчеләре Гүзәлем һәм Салават Миңнеханов һәммәсен дә күз явын алырлык образлары белән шаккаттырса, Айрат Сафин «Бу бит бәхет төне» җырының яңа версиясен тәкъдим итте, ә Хәмдүнә Тимергалиеваны алкышларга күмделәр.

Күпләр түземсезлек белән Лия Шәмсина һәм «Песни» тапшыруы катнашучысы Хәбиб чыгышын көтте. Һәм бер дә юкка түгел икән: аларның «Яратмыйсың» җыры һәм оригиналь чыгышы берәүне дә битараф калдырмады. Беренче тапкыр лауреат исеменә лаек булган шоумен Данир Сабиров та үз чыгышын кечкенә генә юмор бенефисына әверелдерергә өлгерде.

Оештыручылар номинация һәм чыгыш ясаучылар күплеге белән генә түгел, биюләр белән дә гаҗәпләндерергә сүз биргән иде. Сүзләрендә тордылар: TMTV сәхнәсенә барлыгы 60 биюче чыкты. Нинди генә образга кермәде алар, бигрәк тә Хәким чыгышында катнашкан биючеләрнең футуристик костюмнары һәм сәер хәрәкәтләре истә калган. Ә «Хит-парадлар лидеры» Ландыш Нигъмәтҗанованың биючеләре барысын да уздырып, гироскутерларда биеде.

Грандиоз шоуны Гөлназ Сәфәрова, Айваз Садыйров, Айрат Ильясов, Иркә, Рамил Шәрапов һәм Рамил Шәрәфиев алып барды. Ә җиңүчеләрне игълан итү өчен танылган шәхесләр чакырылган иде. Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова, мәсәлән, тамашачыларны җыр белән сәламләде дә, берьюлы җиде лауреатны игълан итте. Алар арасында «Иң романтик башкаручылар» Чәчкә, Артур Минһаҗев, шулай ук «Чит илдә төшерелгән иң яхшы клип» номинациясе җиңүчеләре Элвин Грей һәм Бабек Мамедрзаев бар иде. Сүз уңаеннан: Элвин Грей «Елның иң популяр җырчысы» булып та танылды.

Татарстанның Яшьләр министрының беренче урынбасары Тимур Сөләйманов барлык җиңүчеләрне котлап, яшь башкаручыларга юнәлеш бирә торган тантана уздырганнары өчен оештыручыларга зур рәхмәтен белдерде. Ә танылган дизайнер Зарина Бабаджанова бүгенге уңыштан соң, иң мөһиме – җиңүче исемен саклап калу һәм алга таба да тырышып эшләү кирәклекне ассызыклап үтте.

Бүләкләүчеләр арасында шулай ук Татарстанның халык артисты Раил Садриев, Татарстанның атказанган артисты Фәнис Җиһаншин һәм популяр җырлар авторлары Эльвира Сафина, Гүзәлия һәм Марат Мухин да бар иде.

«Гастрольләр рекордсменнары» – Зинира һәм Ризат Рамазанов дуэты, «Иң яхшы клип һәм җыр» өчен Әнвәр Нургалиевка бүләкне ТатМузТВ телеканалының баш мөхәррире Алмаз Гыйльметдинов тапшырды.

«Тамашачы мәхәббәте» (Иркә, Рифат Зарипов), «Халык мәхәббәте» (Филүс Каһиров) исемнәренә лаек булганнарны һәм «Татар сәнгатенә зур өлеш кертәкән өчен» махсус номинация җиңүчесе Айдар Галимовны «Барс-Медиа» татар медиа группасының башкарма директоры Динә Гәрәева котлады.

ИлСаф, Эльмира Кәлимуллина, Алсу һәм Азат Фазлыевлар, Азалия Зиннәт, Вадим Захаров, Алсу Әбелханова... 46 номинациядә барлыгы 55 артист җиңүгә лаек булды!

Сәхнәгә бүләкләр тапшыру өчен TMTV-2019 премиясе партнерлары «Россельхозбанк» ачык акционерлык җәмгыятенең Татарстандагы региональ филиалы директоры КОДӘРМӘТОВА Ләлә Ринат кызы, «Казанская мельница» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең коммерция буенча директор урынбасары НАСЫЙРОВ Эльвир Илдус улы, «Третий глаз» офтальмология клиникасының баш табибы, медицина фәннәре кандидаты, хирургларның Европа ассоциациясе әгъзасы ЛИПИНСКИЙ Дмитрий Андреевич, «Ваш закон» юридик компаниясе житәкчесе, Башкортстан хатын-кыз эшмәкәрләре ассоциациясе әгъзасы, Бөтенроссия күләмендәге «Ел кешесе» конкурсы җиңүчесе, юрист ХӘСӘНОВА Эльмира Газыйм кызы дә күтәрелде.

Җиде сәгатьлек тамаша лауреатлар башкаруында ТатМузТВ гимны белән тәмамланды.








Фото: Ильнар Сафиуллин

PRESSA



СИҢА ЯЗГАН ЯЗЫМ

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

* * *

Күкләр җөрьәт итмәс биеклек бар,
Кагылырга кыяр-кыймас хисләр.
Тынчу томан тулы иртәләр бар,
Ай нурына тулган якты кичләр.

Кичер мине, тормыш торгынлыгы,
Түгелергә торган чакларым ла.
Күңелемнең көйсез кыргыйлыгын
Калкан иттем, синнән сакланырга.

Яңа көннәр. Көн тулы яз менә.
Яз тулы көл исе һаваларда.
Иске хисләр яна. Ялкыныннан
Җанда яңа хисләр яралана.

Күкләр җөрьәт итмәс биеклеккә
Бары төтен генә күтәрелә.
Яз исеннән шыр исерек галәм
Көн артыннан төннәр көтә менә.

Иләс хисләр әсире без бүген.
Яз җилләре кыяр-кыймас әле.
Томаннарда таңнар адашканга,
Көннәремнең шундый кыргый мәле.

* * *

Син сөйлисең. Иренеңдә төтен тәме.
Һәм дыңгычлап тутырылган
тынлык җирдә...
Сиңа кагылырга иртә әле.

Иртәгәләр, буш киштәләр тора
Берәм-берәм, тезелешеп миндә.
Яңа көннән ятьмә үреп, таңда
ауга чыгам,
Һәм очасы килә!
Киек бер кош булып,
Биек булып.
Томырылып,
Табынасым килә.
Учак һәм үч исе сеңгән учларыңа
Кагыласым килә,
Табыласым килә.

Тулган айдан
Тансык тынлык өне зыңлап тора.
Сүзләр сынык-сынык.
Сак тынлыкка сыенып,
Таң сызыла, әнә, сынап кына,

Санап кына йөрәк тибешеңдә
Тимер чаңы катыш ефәк назын,
Хәнҗәрләргә хәтер өргән чагым.
Учларымда – сиңа язган язым.

Апрель каны тамган карашыңда,
Төнге томан тулы күзләреңдә
Бүген – корбан төсе...
Җаным ятьмәсендә бәргәләнә
Төтен тәме сеңгән синең исем...

* * *

Дөньяның күчәрен күчерә
Бер кыргый күгәрчен күкләрдә...
...Ике җыр арасын, ике җир арасын
Кирәктер елмаеп үтәргә.

Китәргә кирәктер. Җил генә
Тезләнеп ярлыкау теләнә,
Тәрәзгә терәлә карашың.
Кайдадыр офыклар тирбәлә.

Кемнәрдер таптаган, таплаган
Бу җирдә тынчу да, тыныч та.

...Исемнәр чуала. Ут чәчри –
Бәрелә кылычлар кылычка,
Кайтаваз котыра кыйблада,
Хәтердә мең караш калтырый...

Нәүрүзләр яңа кан сорыймы –
Илереп-илереп яз елый.

Күзләре елмая... Ышанма,
Аралар юл булып түшәлми...
Сәбәпләп үлчәнми бу яшәү,
Гомерләр сәгатьләп үлчәнми.

Син – миңа, мин – сиңа дигәнем –
Нибары гап-гади төш кенә...
...Күкләрдә бер кыргый күгәрчен
Дөньяның күчәрен күчерә...

* * *

Көнем ятим синсез. Нәрсә әйтим,
Таңнар атты менә тәрәзәмдә.
Март иртәсе бүген, яз иртәсе.
Көннәр җылы, диләр. Яз галәмдә.

Минем тәрәзәмне каплый әле
Узган язгы сагыш пәрдәсе.
Ачып кына булмый, күңел күнми.
Килешмәме әллә нәрсәсе.

Җетелеге уңган, тузан кунган –
Тәрәзәмдә бүген гүя томан.
Зәңгәр төстә, мин ярата торган.
Томан аша язга карап торам.

Язым ятим синсез. Синсез язым –
Салкыннардан салкын көз ише.
Сагыш пәрдәсендә – синең караш,
Дөньясында әле юк кешем...

* * *

Мин сине тапмаган дөньяда
Язларың, язларың сызлана...
Илереп җил елый, тәрәзгә
Тымызык көн нуры сылана,

Сыкранып тулыша бөреләр,
Йөзләрен яшерә кояштан.
Еламсып елгалар, каеклар —
Барысы бер язга укмашкан.

Мин сине тапмаган дөньяда
Бар да үз юлында, бар да чын.
Юклыгың сарылган тәрәздән
Каерып алалмыйм карашым...

МАРТ БЕЛӘН МАЙ АРАСЫ



Булат ИБРАҺИМ

* * *

Буранлы ай урталары иде
Ишек шакый берәү ашыгып.
Нәни кызчык туды, ишетәсеңме,
Син бит аны көттең зарыгып.
Җил җыр көйли аңа...
Ә ул анда, толымнарын
җилгә таратып
Олы юлдан олы юлга бара,
Шатлык-кайгыларын яңартып.
Җил җыр көйли аңа...
Ә ул инде күптән сабый түгел,
Җиткән кыз.
Ак күлмәген киеп узып бара,
Ак күлмәген кигән,
Тышта көз.
Көзләрдән соң җиргә ак кар ява,
Сафлык ява, пакьлек коела,
Менә шулай әкрен генә җирдә
Тормыш елгалары уела.
Җил җыр көйли аңа
Һәм чәчләрен шаян малай кебек
тарткалый.
Төнге күктән күзен кысып кына,
Ялт-йолт итеп сары ай карый...
Буранлы ай урталары иде,
Ишек шакый берәү ашыгып.
Чәчәк бәйләмнәре күтәп тора
Ишек ачылганны, зарыгып.

* * *

Бу заман шулкадәр тизләнде,
Үзгәрде яшәүнең мәгънәсе.
Әйдәле, шушында тукталыйк,
Тукталыйк һәм бераз көч алыйк.
Каядыр ашыгу, ашкыну,
Нигә соң? Кайда соң? Белгән юк,
Беләсең, без инде күптәннән,
Ихластан шатланып көлгән юк.
Югыйсә дөньясы бер көлке,
Көлеп ят мәгънәсез сүзләрдән.
Күрешәбез кебек үзебез,
Сөйләшкән генә юк күптәннән.
Югыйсә сөйләшер әйберләр
Бихисап бу салкын шәһәрдә.
Тик нигә?
Нигә соң әле дә
«иртәгә, әйдәле иртәгә».
Әйдәле, барысын ташлыйк та
Сикерик туктамас арбадан.
Нилеккә бу синең шөһрәтең?
Нилеккә бу сиңа ялган дан?
Нигә бу якалы күлмәкләр,
Нигә бу ялт(ы)равык савытлар?
Шул арба көпчәге астында
Тузанга күмелеп җан бирә
Кабатлап булмаслык вакытлар.
Утырып сөйләшик әле бер,
Утырып сөйләшик...

* * *

Беренче җәйге кар коела кояштан,
Кешеләр төренгән туннарга.
Вакытлар җиткәндер, күрәмсең,
туңарга.
Ә мин яланаяк һәм яланөс,
Өзалсаң, әйдә, өз, әй салкын.
Туңасылар килми минем бүген,
Зур кояш каплаган үз күген,
Һәм елый боз булып,
тик тәне ут булып
Кар белән нур чәчә.
Исемең түгел шул Гөлчәчәк.
Башкача, әз генә, тик үзең гел чәчәк,
Өзмичә түз генә.
Көзләрдә ни явар, анысы билгесез,
Билгеле дә кебек, ап-ачык көн кебек.
Тик миңа билгесез,
Нишләрмен мин синсез.
Нишләрмен?..
Яланөс мин бүген,
Өзалсаң, әйдә, өз, әй салкын.

* * *

Тулай торак.
Аннан ерак түгел
Үзбәк ашханәсе тирәсендә
Сине көтеп йөрим.
Тулай торак.
Гадел Кутуй тукталышы.
Тапшырасы хатлар
тапшырылды инде,
Әйтер сүзләр калды уйда
Буталышып.
Тулай торак.
Аның тирәсендә
Тупыл коя яфрак,
Тукталышка карап
Озатып кала кызыл автобусны...
Ә син хәзер ерак,
Мин дә синнән ерак.
Тулай торак тәрәзәсе
Карап тора елап.

Пейзаж

Март белән май арасы,
Тәрәзәдән үтеп кергән
Язның назлы нурларыннан
Никтер килә күңелләрнең
Иркәләнеп ятасы...
Март белән май арасы.

Кояш дигән усал йолдыз,
Кар һәм бозны ашыктырып,
Тирги-тирги су итә.
Җилкәннәр җилне сагынган,
Кораблар әзер йөзәргә,
Сабый гөрләвек көтә.

Ак кышлардан туңып киткән
Аккошлар кайткан авылга,
Яшен яшьнәп күк күкри.
Хәйләкәр авыл песие,
Тәпиен юешләтмим дип,
Коры җир эзләп йөри.

Чәчәк аткан лаләләргә
Күз сирпеп уза үткәннәр,
Бал корты серкә җыя.
Торналар күренә күктә,
Шомыртлар май аен көтә...
Язга күпме наз сыя.





О. ГЕНРИ

САРЫ РОЗА

(Хикәя)

Мисс Пози Кэрингтон мәшһүр дигән исемгә бик лаек иде. Бәләкәй генә Кранбери-Корнерс авылында Богс фамилиясе белән башланган тормыш юлы аңа дан-шөһрәт вәгъдә итмәде. 18 яшендә ул Кэрингтон фамилиясен алды һәм башкаланың варьете театрында хорда җырлау бәхетенә ирешә. Хорда «башлап җырлаучы» баскычыннан күтәрелеп, тиз арада югарырак та үрләде. Театр дөньясын шаулаткан «Алдакчылар» музыкаль комедиясендә «Кошчык» булып сайрады. «Фоль де Роль»дә исә бөҗәкләр биюендә катнашып, аерым да биеде. Һәм, ниһаять, «Корольнең коену халаты» опереттасында Тойнет роле белән тәнкыйтьчеләрнең һәм тамашачыларның игътибарын җәлеп итте. Без бәян итәчәк вакыйгалар куерган чакта мисс Пози дан-шөһрәт, макталулар һәм шампан шәрабы диңгезендә коена иде инде. Алдан күрә белү сәләтенә ия елгыр антрепренёр герр Тимоти Гольдштейн мисс Пози Дайд Ричның «Газ яктысында» исемле яңа пьесасында сезон дәвамында төп рольдә уйнарга риза дигән саллы документка мәшһүребездән кул куйдырып өлгергән иде.

Хәбәр яшен тизлегендә таралуга, яшь актер – гасырның талантлы улы, комик рольләр өчен генә яратылган мистер Хайсмит герр Тимоти янына килеп тә җитте. «Газ яктысында» пьесасында комик персонаж – баш герой Соль Хэйтосер ролен уйнарга өметләнә иде ул.

– Кадерлем минем, – диде аңа Гольдштейн, – алыгыз сез ул рольне, әгәр дә ала алсагыз. Мисс Кэрингтон мине барыбер тыңламаячак. «Авыл гыйбаты» роленә өметләнгән ярты

дистә талантлы актерны ул кире какты инде. Хэйтосерны уйнардай чын актер табылмыйча сәхнәгә аяк та басмаячакмын дип тә белдерде. Ул үзе бит авылда үскән. Чәч арасына салам кыстырып кына иркен кырлардагы үлән кебек киң сулышлы самими авыл баласының табигый образын гәүдәләндереп буламыни, янәсе. Бродвей оранжереясендә баш калкыткан ул кыланчыклар ачуымны гына китерә, ди ул. Шаярып кына, Ленмон Томпсон бу рольне тарта алмасмы, дип сораган идем. «Юк, – дип кырт кисте, – аны да, Джон Дрю, Джим Корбетны да – турнепс белән турникетны бутый торган ул көяз кыланчыкларның берсен дә бу рольдә күрергә теләмим. Ялган кирәкми миңа». Менә шулай, туган, Соль Хэйтосерны уйныйсыгыз килсә – мисс Кэрингтонны ышандырыгыз. Уңышлар телим.

Икенче көнне Хайсмит поездда Кранбери-Корнерска китеп бара иде инде. Эт олаккан күңелсез бу җирдә ул өч көн торды. Богсларны эзләп тапты һәм аларның өченче, хәтта дүртенче буын шәҗәрәләрен, гаилә тарихларын энәсеннән җебенә кадәр ятлап бетерде. Кранбери-Корнерстагы вакыйгаларны һәм җирле колоритны җентекләп өйрәнде. Авыл аның йөгерек уй-фикере артыннан өлгерә алмый иде. Хайсмит фикеренчә, театр дөньясына кереп чумган бердәнбер актриса авылдан чыгып киткәннән бирле монда энә очы кадәр дә үзгәреш-мазар булмаган. Сәхнәдә пәрдә ачылып ябылган арада гына «бу вакыйгалардан соң дүрт ел үтте» дип белдереп була ул. Төс-кыяфәтен үзгәрткән хамелеон шикелле, Хайсмит авылдан «Кранбери-Корнерс малае» булып кайтты.

Бөтенесе бәләкәй бер погребокта булды – нәкъ менә шунда Хайсмит актерлык осталыгы белән ялтырап алды да инде. Вакыйга урынын төгәлрәк күрсәтү кирәк тә түгел: бары шул бердәнбер погребокта гына «Корольнең коену халаты» спектакленнән соң мисс Пози Кэрингтонны очратырга мөмкин.

Бер өстәл артында утырган күңелле компаниядән халык күзләрен ала алмый. Җыйнак-сылу буй-сынлы, мөлаем, шат күңелле, бәхеткә коенган данлыклы мисс Кэрингтон чынлап та тирә-якта беренче чибәр дип аталырга лаек. Аның артында яңгыравык тавышлы, бөдрә башлы Гольдштейн шәйләнә, ул нindидер могҗиза аркасында күбәләкне элэктергән аюны хәтерләтә. Тагын берсе – моңсу карашлы, гел сагаеп, үзенә мөрәҗәгать итеп әйтелгән һәр сүзне язарына азык итеп кабул итәргә әзер матбугат хезмәткәре – илаһи бер тынлыкта алдындагы диңгез ризыкларын йоту белән мәшгуль. Һәм, ниһаять, чәчләрен турыга ачып тараганы – ресторанның исәп-хисап кәгазьләрендә исеме алтын кебек ялтыраган яшь, өметле егет. Болар көлешеп, сөйләшеп утырган арада, официантлар, үзләрен чакырганнарны күрмиишетмичә, аркаларын куеп әрле-бирле чабулап йөреп тора, музыкантлар күңелле музыка уйный. Тротуардан тугыз фут түбәндәрәк урнашканга, бу бинада рәхәт, күңелле иде...



Рәсем: Наталья Васильева



Унбер тулып кырык биш минутта кафега әкәмәт бирәү килеп керде. Беренче скрипка ялгышты: ля урынына ля бемоль алды; кларнет әтәч тавышлары чыгарды, көй бозылды; мисс Кэрингтон фырылдап борынын җыерды, чәче турыга ачып таралган егет зәйтүн төшен йотып җибәрде.

Керүченең кыяфәте шаккатмалы иде. Авыл баласы икәне ярты чакрымнан күренеп тора. Ябык, озын, хәрәкәтләре буталчык, җайсыз. Җитен чәчледер үзе, колагына җиткән ачык авызлы, яктылыктан һәм мондагы затлы халыктан тәмам биһуш булганга охшый. Чикләвек мае төсендәге костюмы, ачык зәңгәр галстугы, җиңеннән тырпаеп чыгып торган арык озын кулы, чалбар балагыннан күренгән тубык сөяге һәм ак носкилары шунда ук күзгә ташлана. Җайсыз бәрелеп урындыкны аударды, икенчесенә атланып утырды, озын боты өстәл аягына уралгандай булды, янына килеп баскан хезмәтчегә ялагайланып елмайды.

– Миңа берәр стакан имбирлы сыра, – диде ул официантның итагатьле соравына каршы.

Һәммәсе бу сәер килмешәккә төбәлеп, ниндидер гайре хәл буласын көтә иде. Ул яшь редис кебек тере-тазә һәм тырма сыман гап-гади күренә. Күзләрен зур ачып, тирә-якны айкады, гүя, бәрәңге арасында буразнаны актарып яткан чучка юкмы дип эзләнүе иде. Ниһаять ул мисс Кэрингтонны күреп алды. Торып басты, оялудан кызарып, балкып торган елмаюы белән аның өстәленә таба атлады.

– Ни хәлләрегез бар, мисс Пози? – дип сорады ул, каян чыкканына шик калдырмый торган акцент белән. – Әллә сез мине танымыйсыз да инде? Билл Самерс бит мин, – хәтерлисезме Самерсларны, тимерче алачыгы артында гына яшиләр иде. Аңлашыла инде, сез Кранбери-Корнерстан киткәннән соң, мин шактый үстем бит. Ә беләсезме, Лиза Перри шәһәрдә сезне очрату ихтималын юраган иде. Лиза бит Бэн Стэнфилдка кияүгә чыкты, ә ул әйтә...

– Кит аннан? – дип бүлдерде аны Пози җанланып. – Лиза Перри кияүгә чыксын инде? Сипкел баскан бите белән бит әле!

– Июньдә чыкты кияүгә, – дип, җиңелчә көлеп дәвам итте гайбәтче. – Хәзер ул Татам-Плейска күчеп китте. Ә Хэм Райли тәмам изгегә салышты. Мисс Близерс кортка үз өен капитан Спунерга сатты; Уотерсларның төпчек кызы музыка укытучысы белән чыгып качты; мартта суд бинасы янды; сезнең Уайли абзагызны констебль итеп сайлап куйдылар; Матильда Хоскинс кулына энә кадады һәм җан тәслим кылды. Ә Том Бидл Салли Лазроп артыннан йөри, – бер кич калмый баскыч төбен каравыллый, дип сөйлиләр.

– Шул шакмак күз артыннанмы? – дип кырыс кына сорап куйды мисс Кэрингтон. – Ә бит Том Бидл кайчандыр... Гафу, дуслар, мин хәзер... Таныш булыгыз. Бу минем күптәнге танышым, мистер... кем әле сез? Әйе, мистер Самерс. Бусы – мистер Гольдштейн, мистер Рикетс, мистер... о, ә сезнең фамилия ничек әле? Ярар, барыбер: Джонни. Ә хәзер читкәрәк китик, миңа тагын ни дә булса сөйләгез.

Ул егетне үз артыннан ияртеп, почмактагы буш өстәлгә алып китте. Герр Гольдштейн симез җилкәләрен җыерып куйды һәм официантны чакырды. Репортер бераз җанланып, абсент китерүләрен сорады. Чәч юлын туры итеп ачкан яшүсмер меланхолик уйларга кереп чумды. Погребоктагылар стаканнар зыңгылдатып, көлешеп, спектакльне тамаша кылды. Пози гаҗәп оста уйный дип ышана иде алар. Кайберәүләр, аңлаган кыяфәт чыгарып, «реклама!» дип пышылдашты.

Пози Кэрингтон нәни чокырчыклы сөйкемле ияге белән кулларына таянды да тамашачы турында тәмам онытты – шул сыйфаты аңа уңыш китергән иде инде.

– Нигәдер Билл Самерсны искә төшерә алмыйм, – диде ул уйчан кыяфәт белән «авылдаш»ының гөнаһсыз зәңгәр күзләренә төбәлеп. – Самерслар хәтердә үзе. Бездә әллә ни зур үзгәрешләр булмагандыр, мөгаен. Безнекеләрне күптән күрдегезме?

Һәм менә шунда инде Хайсмит үз козырен эшкә җикте. Соль Хэйтосер образы көлкеле генә түгел, күтәренке рухлы, хисле дә булырга тиеш. Ә мондый рольне уйный алачагына ничек кенә булса да мисс Кэрингтонны ышандырырга кирәк.

– Мисс Пози, – дип башлады «Билл Самерс». – Сезнең йортта өч көн элек кенә булдым. Әйе, дөресен әйткәндә, әллә ни үзгәрешләр юк анда. Аш өенә терәлеп үскән сирень куагы гына тулы бер футка күтәрелгән. Ә ишегалдындагы карама корыган, кисәргә туры килгән. Шулай да күп әйбер элеккечә түгел инде барыбер.

– Әни ни хәлләрдә? – дип сорады мисс Кэрингтон.

– Соңгы тапкыр күргәндә баскычта өстәлгә җәя торган җәймә бәйләп утыра иде, – диде «Билл». – Картаеп киткән ул, мисс Пози. Әмма өегездә бар да элеккечә. Әниегез үз янында утырып торуымны үтенде. «Ләкин, Уильям, теге үрелгән сиртмәгә тотынмагыз, – диде миңа. – Пози киткәннән бирле аңа кагылган кеше юк. Ул кисә башлаган алъяпкыч та – шул көе, сиртмәгә ул ничек ыргыткан, шулай ята. Пози кайчан да булса үзе тегеп бетерер әле дип өметләнәм мин».

Мисс Кэрингтон боеручан тавыш белән официантны чакырып алды.

– Шампан шәрабы! Корыны, – дип, кыска гына итеп әмер бирде. – Гольдштейн түләр.

– Кояш туп-туры без утырган баскычка төшкән иде, – дип дәвам итте артист, – ә яктылык нәкъ әнкәгез күзләрен чагылдыра. Мин инде үземчә хәлне җиңеләйтмәкче булам, бәлки, бераз читкәрәк күчеп утырырсыз, дим. «Юк, Уильям, – ди ул, – юл чаты күренеп торган җиргә күчеп утырсам, урынымнан кузгала да алмыйм мин. Һәр көнне, чак кына буш вакытым булдымы, минем Пози кайтып килмиме

дип, читәннәр артындагы юлны күзләргә тотынам. Ул төнлә чыгып китте, ә иртән юл тузанында аның башмакларыннан калган бәләкәй эзләрне генә күрдек. Шуннан бирле гел уйлыйм да уйлыйм, кайчан да булса шау-шулы тормыштан туяр да, карт әнкәсен сагынып, шул тузанлы юлдан кире әйләнеп кайтыр ул».

– Киткәндә, менә моны сезнең йорт каршында үсеп утырган куактан сындырып өзеп алдым, – дип сүзен түгәрәкләде «Билл». – Никтер сезне чынлап та шәһәрдә очратырмын дип уйладым мин. Ә инде туган йорттан килгән бүләкне кабул итеп алу сезнең күңелегезгә хуш килергә тиеш.

Һәм ул пиджак кесәсеннән сулып башын игән бәрхет сары розаны чыгарды. Бу вульгар погребоктагы тынчу һавада римлылар арысланнар белән көрәшкәндә җәнлекләрнең кайнар сулышыннан куырылып килгән гыйффәт туташ кебек иде ул чәчәк...

Мисс Позиның чыңлап торган матур тавыш белән кычкырып көлүе «Кыңгыраулар» көен яңгыратып маташкан оркестр тавышын да күмеп китте.

– Йә Аллам! – диде ул кәефе күтәрелеп. – Җир йөзендә безнең Кранберидан да күңелсезрәк урын тагын кайда бар микән? Чынлап әйтәм, мин анда ике сәгать тә яши алмас идем – әллә кайчан эчем пошып үлгән булыр идем инде. Ә сезнең белән күрешүгә, очрашуга бик шатмын, мистер Самерс. Хәзер инде миңа өйгә кайтып, тынычлап йокларга кирәк.

Сары розаны ул искиткеч затлы ефәк күлмәгенең түшенә үк кадап куйды да Гольдштейн әфәнде ягына боеручан караш ташлады.

Юлдашларының өчесе дә торып басты. «Билл Самерс» та, алар белән бергә, мисс Позины көтеп торучы җигүле атларга кадәр озата чыкты. Исәпсез-хисапсыз тасмалар, балитәкләр – бар да тәртиптә.

Җайлап урнашкач, мисс Кэрингтон, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайды да, күзләре белән балкып, һәммәсенә сәлам юллады.

– Авылга кайтып киткәнче, минем яныма да сугылып чыгыгыз, Билл! – дип аваз салды ул экипаж кузгалып киткәндә.

Хайсмит маскарад костюмын алыштырып та тормыйча герр Гольдштейн белән кечкенә кафега кереп утырды.

– Йә, ничек, ә? – дип сорады актер елмаеп. – Соль Хэйтосер ролен миңа бирергә туры килер бит аңа, әйеме. Сез ничек уйлыйсыз? Гүзәл мисс ялгыш та шикләнмәде. Шулай бит?

– Сезнеңниләр сөйләшкәнегезне ишетмәдем, – диде Гольдштейн. – Әмма ләкин костюмыгыз һәм сөйләшү рәвешегез – нәкъ авылча инде! Сезнең уңыш өчен күтәрик. Иртәгә иртүк мисс Кэрингтон янына барырга һәм роль хакында чын-чынлап сөйләшергә кирәк. Сәләтегезне бәяләмичә калгандыр дигәнне уема да китерә алмыйм.

Икенче көнне унбер тулып кырык биш минутта – иртәнге якта Хайсмит, энә-җептән чыккан өр-яңа, заманча мода белән тегелгән костюмнан, ышанычлы адымнар белән мисс Кэрингтонның шәп отельдәге апартаментына юл тотты.

Актрисаның горничные, француз кызы, аның янына чыкты.

Бик тә кызганыч, – диде мадемуазель Гортенз, – ләкин миңа бу хәбәрне аны сорап килүчеләрнең һәммәсенә дә тапшырырга кушылды. Аһ, ничек кызганыч! Мисс Кэрингтон театр белән төзелгән бөтен килешү-контрактларны ертып ташлады, театр, шәһәр белән араны өзеп... Яшәргә, ничек әле... Кранбери-Корнэрга кайтып китте.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА тәрҗемәсе.

Тәрҗемәчедән

О. Генри тәхәллүсе белән танылып, дөнья әдәбиятында үз урынын алачак язучының чын исеме Уильям Сидни Портер (1862–1910). Ул АКШның Төньяк Каролина штатында табиб гаиләсендә туа. Яшьли ятим кала. Ерак туганы аңа фармацевт һөнәре алырга булыша. Яшьтән үк иҗат эшенә тартыла. Өйләнә, кызы туа. Гаиләсенең матди хәлен кайгыртып, Остин Милли Банкка кассир булып урнаша. Нишлисең, табигать аңа Америка эшкуарларына хас ертлачлык бирмәгән, йомшаклыгыннан файдаланучылар табыла. Кара эт бәласе ак эткә дигәннәре рас килә. Растрата ясауда гаепләп, хөкемгә тарталар аны. Ул качарга мәҗбүр. Бәлки, бу вакыйга еллар үткәч йә онытылыр, яки чын җинаятьче табылыр иде. Әмма япь-яшь хатынының чахоткадан үләргә ятканын ишетеп, кулга аласыларын белә торып Гондурастан кайтып җиткән ирен: «Билл, мине ник ташладың?» – дип елап каршылый Атол. Сөйгәненә ул ни дип җавап бирсен соң? Курыктым, хурландым, төрмәгә утырасым, намуссыз исемен күтәрәсем килми дисенме? Гаебен ул үлгәнче танымаячак, тик гөнаһсыз икәнен исбатлый алмаячагын да яхшы белә. Хатынын җирләп, тыелгысыз елаган кызын җитәкләп зираттан чыгып барганда кулларына богау кидерәләр һәм биш елга каторга-төрмәгә тыгып куялар. Нахак гаеп, төрмә кемне генә сындырмый? Тик аны түгел. Фармацевт һөнәре ярап куя, бәлагә юлыкканнарны да ямарга, дәваларга кирәк. Төннәр буе новелла – кыска хикәяләр яза. Танышлары аша редакцияләргә җибәреп карый, өчесен генә басалар. Өч ел ярымнан аны азат итәләр. Кызы янына ашкына. Иҗат эшенә чума. Хемингуэй, Эдгар По, Джек Лондон кебек титаннар иҗат иткән илдә үзенчәлекле язучы булу җиңелме? О. Генри үз юлын таба: аның әсәрләре мавыктыргыч, кызыклы табышмак кебек юморга бай, укучының уен бөтереп ала, фантазиясен эшкә җигә, әмма әсәрнең чишелеше гаҗәпкә калдыра, характерлар һич көтмәгәнчә ачыла. Ул бик тыйнак яши, аралашмый, минем тормышым – әсәрләремдә, ди. 48 яшендә вафат була.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Кыз бала әнисенә карап үсә. Үз гаиләсен булдыргач та күп эшне әнисеннән алган үрнәк буенча башкара.

Мин дә табынны әни сыман корам, яшелчә, җиләк-җимешләрне дә тәлинкәгә аның кебек тезәм, хәтта ризыкны да аның кебек «җитәрлек һәм бетәрлек» итеп пешерәм икән. Соңгысын үзем абайламас та идем, кайнатам күреп алып, моның гаилә тормышында мөһим әйбер икәнлеген искәртте. Мин исә моның әниемнән откан гадәтем икәнен аңладым. Димәк, үзең камиллеккә омтыл, бала синнән үрнәк алып үсәчәк.

Ә менә яңа туган балага кечкенә чагыннан ук милли тәрбияне ничек бирергә, халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен ничек җиткерергә? Бу хакта мин чын-чынлап үземнең балам тугач кына уйлана башладым. Әни бу тәрбияне бирер өчен нәрсәләр эшләгән соң дип балачагымны искә төшердем. 6-7 яшьлек чагымда рус милләтеннән булган дус кызларыма ияреп, әнигә тәүге тапкыр мама, мамуль дип эндәштем. Әни елмаеп: «Миңа башка алай әйтмә, маймыл дип ишетелә бит, миңа әни дип эндәш», – диде. Әнә шулай гади һәм җиңел итеп аңлатты да бирде.

Эштән бушап ял иткән вакытларда әни татарча җырлар көйли. Мәктәптә укыганда кулыма татар халык җырлары китабы килеп кергәч тә әнигә имтихан оештырганым хәтердә. Китаптан сайлап бер бит ачам да, җырның берничә сүзен генә әйтеп, әнигә имтихан оештырам, сүзләрен белерме, көйләп күрсәтә алырмы, янәсе. Әни бөтен җырларны белә. Өлкән яшьтәге хезмәттәшем белән татарча концертка баргач, артистларга кушылып җырлавымны ишетеп, сүзләрен кайдан белүем белән кызыксынды. Әлбәттә, кечкенәдән әни тәрбиясе белән сеңгән.

Татарча мәкальләр кулланып сөйләшә, татарча табышмаклар әйтә, язучыларыбызның, әсәрләре белән таныштыра, татар милләтенең шатлыклы һәм кайгылы вакыйгалары турында урынын һәм вакытын туры китереп сөйли белә иде әни.

Кечкенә чагымда калфак та тегәргә өйрәтте. Шуңадырмы, милли кием белән кызыксыну зур миндә. Бала тугач үткәрелүче фотосессияне дә мин милли рухта эшләргә алындым. Катлауландырмый гына, фотоларда түбәтәй, калфак, гармун кебек татар милли символларын кулланып. Үскәч, ул фотоларны караганда баланың күңелендә түбәтәй, калфаклардагы бизәкләр, гармунга карата кызыксыну булмый калмас.

Балам үсә төшкәч бергә укырбыз дип алып куйган татар китапларым байтак.

Ә хәзергә, әнием үрнәгендә, сөйләшә дә белмәгән сабыйга йөрәк җылысын кушып, туган телебездә бишек җырларын көйлибез.

Гөлүсә МИФТАХОВА.
Казан шәһәре.



Рафак абый Дәүләтшин – сугыш чоры баласы. Тугызынчы дистәнең уртасын үткән мөхтәрәм затның уртаклашыр истәлекләре бик күп.

Ун балалы Шәмсениса апа һәм Зиннәт абзый Дәүләтшиннар исән чакта, аларның Сарлы авылында укытучы булып эшләргә туры килде миңа. Ветеринария институтын тәмамлаган төпчек уллары Алик (соңрак ул Татарстанның атказанган зоотехнигы булды) – яннарында, калганнары үз ояларын корып таралышкан иде инде. Уртанчы уллары Вил күрше Вахитов исемендәге совхозда сарык асраучылык белән илгә танылган «Руно» берләшмәсендә эшләдә, Татарстанның атказанган ветеринария табибы дигән мактаулы исемгә лаек булды. Ә кызларының берсе – Татарстанның атказанган укытучысы Лимуза Шәяхмәтова белән Азнакайның һөнәр училищесында бергә эшләргә туры килде. Булдыклы нәсел алар.

Сугыш беткән елны җидееллык мәктәпне тәмамлаган Рафак абыйны Мөслимгә хисапчылар курсына җибәрәләр. 16 яшеннән башлап, бөтен хезмәт юлын төрле җирләрдә баш хисапчы булып уза ул.

1950 елның июлендә Рафак абыйны өч ел ярымга армиягә алалар. Кытайда, Порт-Артур шәһәрендә артиллерист булып хезмәт итә. «Кытай-Совет дуслыгы» медален дә шунда ала. Шундый ук бүләккә Зур Сукаеш авылы егете, Порт-Артурда диңгез флотында хезмәт итүче Әнис Латыйпов та лаек була. Әлеге медаль сугышчан һәм хезмәт батырлыгы күрсәткән совет кешеләрен бүләкләү өчен Кытай дәүләте җитәкчелеге тарафыннан булдырыла. Бүләкләнүчеләр арасында Советлар Союзы маршаллары, шул исәптән, Георгий Жуков та бар.

Армиядән кайткач, Рафак Саба районындагы хисапчылар әзерләү училищесын һәм читтән торып Башкортстанның Юматов финанс техникумын тәмамлый. Яшь белгечне райбашкарма комитеты Күктәкәгә «Коминтерн» колхозына баш хисапчы итеп җибәрә, Ык елгасы аша төзелгән кечкенә гидроэлектростанция бухгалтериясе дә аңа йөкләнә. 1956 елда Урсайдагы Тельман исемендәге колхозга баш хисапчы итеп билгеләнгәч, бер көн монда, бер көн тегендә ат җигеп йөреп эшләргә туры килә. Дәүләтшиннар гаиләсе бу авылда 11 ел яши. Рафак абыйның хатыны – югары белемле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәдинә апа авылга килгәнче РОНО инспекторы булып эшләгән. Халыкка үрнәк күрсәтүче чын интеллигенция вәкилләре буларак, аларны хәзер дә онытмыйлар Урсайда.

Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы колхоз рәисе – сугыш ветераны Мират Гыйләҗетдинов ышанычлы баш хисапчыны җибәрергә теләмәсә дә, 1967 елда Рафак Дәүләтшинны район үзәгендәге колхозара төзү оешмасына күчерәләр. Анда ул пенсиягә чыкканчы эшли, Татарстанның атказанган икътисадчысы исеменә лаек була. Гомеренең иң истәлекле еллары турында сораганда, Кытайга да ярдәмебез тиде, Урсайга да, дип искә ала ветеран. Ул бу сүзләрне, КПСС Үзәк Комитеты каршындагы югары партия мәктәбен тәмамлаган агроном дусты Әнис Латыйповны да күздә тотып әйтә.

Авыл хуҗалыгын үстерүдә үзеннән лаеклы өлеш керткән Әнис аганың да хезмәт биографиясендә Урсайда партоешма секретаре һәм хуҗалык рәисе вазыйфаларын башкарган еллары төп урынны алып тора. Ул бирегә гаиләсе белән Рафак абыйлардан соң килә, җәмәгате Даимә апа мәктәптә завуч була. Урсай авылына килеп кергәндә кирпеч йортлардан гына торучы Төзүчеләр урамы каршылый икән, бу – Әнис Мәгъсүм улының хезмәте.

Дәүләтшиннар, Латыйповлар буыны әнә шулай гомерләрен авылларны күтәрүгә багышлый.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай шәһәре.

Фото: Рафак Дәүләтшин *(сулда)* журналист Ибраһим Вәлиев белән. 1959 ел.

Белемем буенча педагог мин. Ләкин бер көн дә мәктәптә эшләргә туры килмәде. Кайчак уйлап куям: эшли алыр идемме икән?

Телевизордан укытучылар белән укучылар арасында чыккан низагларны еш күрсәтәләр. Күп очракта укытучының үзен гаепләп калдыралар. Без үскәндә укытучы һөнәре иң игелекле һөнәрләрдән санала иде. Авылда иң матур киенеп йөрүче, һәркем белән тыныч, әдәпле сөйләшүче иң акыллы кеше ул булыр иде.

Укытучы апа нәрсәнедер дөрес эшләми яки дөрес әйтми дигәнне башыбызга да кертеп карамадык. Ул – безнең өчен һәрчак идеал булды. Хәзерге акылым белән укытучыларымның кайбер гамәлләре бигүк дөрес булмаганын да аңлыйм.

Бүгенге педагогларга балаларны ачуланырга ярамый икән. Ә безне ачуланалар иде. Указка таягы белән «менеп» төшкәннәре дә булгалады. Анысы малайларга эләгә иде инде. Алай да әти-әниләрнең тавышланып йөргәнен хәтерләмим.

Хәзер мәктәптә балаларны эшләтергә дә ярамый, диләр. Безне эшләтеп үстерделәр. Ә җәй көне яшелчә бакчасында чүп утау, су сибүләр... Колхоз басуында чөгендер алу, бәрәңге чүпләүләр... Урманга агач утыртырга да, басуга салам яндырырга да безне йөрттеләр.

Без укыганда «икеле» билгесе бик зур тәрбия чарасы иде. «Койрыклы «бишле» алудан котыбыз алына, ул гайре табигый хәл санала. Дәрескә әзерләнми килсәң, укытучы журналга нокта гына төртеп тора. Бүгенге укытучылар исә «икеле»гә юмартрак икән. Дәфтәрен өйдә онытып калдырган өчен генә дә «икеле» куеп кайтаралар. Шуңа күрә бала-чаганың бу билгегә артык исе китми. Әти-әнине мәктәпкә чакырту да без укыганда сирәк күренеш булды. Беркөнне хезмәттәшемне улы спорт киемен алып килмәгән өчен генә мәктәпкә чакыртып алдылар. Югач, кибеп өлгермәгән булган. Укытучысы шуның өчен «икеле» куйган, бала ризасызлык белдергән, ике арада низаг чыккан һәм... эшеннән бүленеп, әни кеше мәктәпкә йөгерде. «Укытучы булсам, шундый вак-төяктән проблема ясамас идем инде», – дип уйладым. Икенче яктан, аны да аңларга була. Дәресен санга сукмый йөрүчеләрдән гарык булгандыр, бәлки.

Нәрсә генә дисәгез дә, замана балалары белән эшләве үзгә хәзер. Күпне беләләр, дөньяны үзләренчә таныйлар, кешеләрне үзләренчә бәялиләр... Безгә яраган тәрбия чаралары аларга туры да килми бугай. Безне куркытып үстерделәр, алай итсәгез болай булыр, болай итсәгез – тегеләй... Замана баласын алай гына куркыта алмыйсың. Кирәкми дә. Куркытып кына көчле шәхес үстерү мөмкин түгелдер ул. Иң элек баланың ышанычын яуларга, аның дусты булырга кирәктер. Укучыларының ихтирамын казана алса гына абруе булачак укытучының.

Лилия ГӘРӘЕВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



«ӘНИ ҖЫРЛАП КИТТЕ...»

«Авырып яттыңмы, авыру бактыңмы?» дигән сүз бар. Мубай тәхәллүсе белән чыгыш ясаучы җырчы Илдар МӨБАРӘКШИН өлешенә аның икенчесе төшкән. «Әнине бөтен кеше дә карый. Безнең авылда, мәсәлән, картайган әнисен тәрбияләүдән баш тарткан икән дип берәү турында да әйткәннәре юк», – ди ул үзе. Шулай булсын, һәр анага олыгайган көнендә ул-кызларыннан кадер-хөрмәт күрергә насыйп итсен. Бу – балаларның алар алдындагы олы бурычы.
Ачыктан-ачык сөйләшәбез.



Дөресен әйтәм, кайчан да булса бу хакта интервью бирермен дип күз алдыма да китермәгән идем... Ул бит миңа гына түгел, туганнарыма да кагыла. Бик шәхси әйбер... Тик уйладым да, барыбер ризалашырга булдым. Әни белән шундый хәлләр башланган вакытта, моның бер безнең гаиләгә генә төшкән хәсрәт түгеллеген аңласам, аның чире турында мәгълүматым күбрәк булса, ул авырлыкларны кичерү күпкә җиңелрәк булыр иде бит. «Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә», дию белән хәзер бөтенләй килешмим. Әни мисалы моның киресен эшләргә кирәген исбатлый. Ул кирәгеннән артык сабыр иде, беркайчан артык сүз сөйләшмәде, эчендәге тышка чыгармады – авыруның бер сәбәбе шул да булырга мөмкин.

...Әнинең гайбәт сөйләгәнен ялгыш та ишеткәнем булмады. Беркайчан! Бездән дә сөйләтмәде. Күршеләр, авыл кешеләре белән тату яшәде – шуңа аны яраталар иде. Гомер буе фермада эшләде. Эшенә бик җаваплы карады. Зиһенле, акыллы кеше иде. Соңгы елларына кадәр газета-журналлар яздырып алып укыды. Безне, балаларын укыту өчен бик күп көч куйды. Әнинең башына кайгы бик күп төште безнең. Бер-бер артлы

Һәр вак-төяктән тәм табучыларга кызыгам – шулай яшәргә кирәк



диярлек ике абыйны югалттык. Хәсрәт гел көтмәгәндә килә бит ул. Беренчесе бигрәк тә шулай булды. Абыйга нибары 34 яшь иде, уңган, тырыш кеше – бөтен авылга бер балта остасы. Тыныч, хәтта артык тыныч иде – аңарда да әни холкы иде. Бу хәл 2000 елны булды, ә тагын сигез елдан – икенче абый... Әле иллегә дә җитмәгән килеш... Мондый зур югалту кичерүчеләр бер әни генә түгел, әлбәттә. Әмма күпләр барыбер сыгылмый, сынмый. Ничектер ул кайгыны күтәрерлек көч табып, алга таба атларга кирәген аңлый, ниндидер башка әйберләрдә үзенә тынычлык эзли – яшәүне дәвам итә. Ә әни бар хәсрәтен эченә җыйды, нинди утларда януын читләргә түгел, безгә дә чыгармады. Беркайчан ачылып китеп сөйләшмәде. Юк, бөтенләй кыргыйланды димим: гомер буе ничек сабыр булса – шундый булып калды. Югыйсә кайчак күтәрелеп бәрелсә дә аңлар идек... Абыйлар белән булган авыр хәлләрне онытып димим (онытыла торган түгел ул!), руслар әйтмешли, «үзеннән җибәреп», безне – калган дүрт баласын шатландырыйм дип яшәсә, үзенә дә, безгә дә күпкә җиңелрәк булыр иде.

Әтидән без бик иртә калдык. Әни авылда абыйлар һәм кечкенә сеңел белән яшәде. Хуҗалык зур иде – икешәр сыер тоттылар. Әмма абыйлар бөтен эшкә дә өлгерде. Мин авылдан туксанынчы елны ук чыгып киттем, институтта укыдым, эшкә урнаштым, өйләндем – бөтен тормышым Казанда иде.
Еш кайтып йөрмәдем: яшь тә идем, авыл дип тә исем китмәде. Ә абыйларны озаткач, бар да минем өскә калды...

Барысы да кинәт булды дия алмыйм, башта икәү генә дә әйбәт яшәде әле алар. Аннары әни әкрен генә авырая башлады. Минем дә кайтулар ешайды. Ярый ул вакыт инде рульгә утырган идем. Әкрен генә бакча эшләре миңа калды, аннан өйне сипләп-ремонтлап торулар да. Айга бер кайтуларны өч атнага бер кайту алыштырды, ике атнага – бер, атна саен... Яннарыннан атналар буе китә алмаган чаклар күбәйде: мин авыл белән шәһәр арасында яши башладым. Сигез ел тирәсе шулай узды. Эшем бик тыгыз чакларда, чиратлашып апалар кайтып йөрде.

Чире әкрен генә, артык сиздермичә генә килде. «Карале, өйалдына чыктым, ә нәрсәгә икәнен оныттым», дию кебек бөтен олы кешеләрдәге сыман хәтер начарлану аңарда да бар иде. Болары гына инде аның бездә – яшьләрдә дә булгалый. Беренче тапкыр «дерт» иттергән очракны хәтерлим. Бер кайтуда янга килеп утырды да: «Улым, бакчаны һаман сөрмәгән бит, тагын соңга калабыз», – диде. «Әни, урамга кара, кыш бит!» – дим. «Бәтәч, чынлап та шулай икән», – дип көлемсерәп куйды. Ярый, монысы онытылды... Әмма шуңа охшаш хәлләр сирәк кенә булса да, тагын кабатлана башлады. Төнге сәгать өчтә яныма килеп утыра да уята: «Улым, син мине больницага илт инде, авырыйм бит. Машинаңны кабызып торма, юлга гына чыгарып бастыр – берәрсе алып китәр әле», – ди. Аңлаткач, көлемсерәп куя да, яңадан кереп ята...

Мин өйдә аларга бөтен шартларны булдырырга тырыштым: кайнар су ясадым, бәдрәф көйләдем. Әкрен генә йорт эчендәге җиһазларны яңартырга керештем. Әмма минем әни белән сеңелгә уңайлыклар тудырам дип йөрүем киресенчә килеп чыкты: аларның тормышын катлауландырды гына. Кайткан саен, әни: «Улым, кайнар су кранының җаен белмим», – дип зарланды. Яңа газ плитәсенең дә көен тапмады. Югыйсә үзенеке кебекне, хәтта төсен дә нәкъ шундыйны алдым. Элек көннәр буе телевизорлары эшләп тора иде – яңасын исә бөтенләй карамадылар. «Ничек кабызырга белмибез», – диделәр... Күрәм, сеңел дә чамаламый. Ашарга әни үзе пешерә иде әле – әкрен-әкрен генә аңардан да кул китте... Миңа ул вакытларда әни ягыннан туганыбыз, күрше Алия апа бик булышты. Әнине инде кибетләргә җибәрмәскә тырыша идек – мин юкта ипи-сөтне шул күрше апа алып кайтты. Башка чакта да аларга гел күз-колак булып торды.

Әни кинәт газ миченнән курка башлады. Бертуктамый: «Өйдә газ исе бар», – дип аптыратты. Барысы да тәртиптә иде югыйсә, сүнмәгәнме, артык каты янмыймы, дип, Алия апа да көн дә кереп тикшереп йөрде. Әни үзе гомер буе диярлек кулланган мич иде бит инде ул... Берсендә Алия апа сөйли: «Керсәм, Бәнат апа ишегалдында йөри, өйдә кеше юк. Аптырап: «Ә Гөлназ кайда?» – дим. Өйдә газ исе бар дип, аны мунча чоланына чыгарып утырткан икән». Яз башы, салкын чак иде әле. Алия апа аларны өйгә алып керә башлагач, башта берсе егылган, аннан икенчесе... Гөлназ сеңлем турында әйтмәдем. Тумыштан гарип бала ул безнең. Диагнозлары бер кочак: Даун синдромы, балалар церебраль параличы, олигофрения, әле менә яңа гына эпилепсия дип тә куйдылар... Бик соң

Кайбер эшләрне әни усалланып эшли дип тә уйлый идек. Алай булмаган, билгеле.

гына тәпи китте ул. Безгә ияреп бераз мәктәпкә дә йөрде. Әмма өйдә үз-үзен карый иде: урын җыя, идән юа, табынны җыештыра. Хәзер ул безнең гаиләдә яши. Кызганыч, әнине кабатлый – акылы салмагая бара.

Инде аларның үзләрен генә калдырырга ярамый иде. Алып китәргә вакыт җиткәнен аңладым. Әни тыңламый башлады: барма дигән җиргә – бара, ярамый дигәнне эшли.

Без авылдан җәй ахырында, августта киттек. Бик эссе көн иде. Әнинең ахырга кадәр анда яши алмаячагын, алып китәргә туры киләчәген белеп торсам да, бу вакыйгага үземне күпме алдан әзерләсәм дә, барыбер коточкыч авыр булды. Беркайчан йозакка бикләнмәгән өйгә, мунчага, гомердә бик күрмәгән келәткә, капкага – барысына йозак салырга кирәк. Ул көнне минем хәлне күз алдына китерсәгез... Әнинең авырайган чагы иде. Өстәвенә, егылып, йөзен, кашларын җимергән. Аларны көчкә машинага алып чыгып утырттым. Әни елый башлады... Беркайчан еламый иде ул. Шунда аның беренче тапкыр елаганын күрдем. Үзенең Яңа Думадан китәсен аңлап түгел, ыгы-зыгыны чамалап кына тынычсызлануы. «Гөлназны кайда калдырасың? Аны кая миннән качырасың?» – ди. Әмма иң зур стрессны ул көнне Гөлназ кичерде бугай. 40 яшькә җитеп килсә дә, аның әле болай ерак юлга чыкканы юк иде. Гөлназга шок булды. Аптырый, курка башлады – хәле начарланды.

Ә алып китәргә кирәк иде... Мин бит бөтен дөньямны ташлап Аксубайга күчеп кайта алмыйм. Болай да тормыш калмаган иде инде. Үземнеке дә, Зөлфиянеке дә. Тиз генә җыенып авылга кайтып китәргә кирәк чаклар исәпсез булды бит. Чакыртып алулар. Үзем сизенеп юлга чыгулар...

Өйгә шулай итеп ике авыру килеп керде. Зөлфия белән бу хакта, әлбәттә, алдан утырып сөйләшкән идек. Бер ел элек тә, ике ел элек тә. Өйдәгеләргә уңайсызлык китерәм дип, болай да алып килүне булдыра алганча суздым. Икенче яктан, әниләрне күршеләр карамагында калдыру да читен иде. Янып йөрдем инде ул чакта... Улларыбызның, әле генә мәктәп тәмамлап, студент булган чаклары иде: алар башка җиргә яшәргә күченде. Аерым яшәү мөмкинлеге булмаса, миңа авылга күчеп китәргә генә кала иде. Кызыбыз Энҗе дә бик кечкенә иде әле. Ул бик көйсез булды: 3 яшькә кадәр елады да елады. Иң авыры Зөлфиягә булгандыр... Яшерен-батырын түгел, салып та йөргәләдем. Башны бөтенләй югалтып түгел, әлбәттә, әмма өч көн тоташ та эчкәнем булды, дүрт көн дә... Өстәңә проблемалар ишелеп килеп төшә дә, нәрсә эшләргә белмисең. Артыкка китүен үзем дә сизәм, тик эчүгә караш җиңелрәк иде бит элек.

Әни безгә килгәч, кинәт начарланды. Саташуы инде гадәти хәлгә әйләнде. Аларны бөтенләй ялгыз калдырырга ярамаган чаклар булды. Бер нәрсә уңай иде – мин инде ун еллап өйдә генә эшлим. Тик бу бит өйдә тик утырам дигән сүз түгел: бик еш компьютерны иртәнге сигездә кабызып, төнге уникедә генә сүндерәм. Ә минем аяк астымда – ике авыру...

Әни үз режимы белән яшәде: аңа көн ни, төн ни – барыбер иде. Аяктан калгач, утырып шуышып йөрергә өйрәнде. Кроватьтан йә егылып, йә әкрен генә үзе төшә дә китә өй буйлап. Кая тели, шунда барып җитә. Бөтен җирне актара. Бертуктамый сөйли, җырлый, йә гел бер сүзләрне кабатлап утыра: тавышы гөбедән чыккандай калынга әйләнде. Бөтен йортны яңгырата. Аңа Гөлназ да кушыла – әни бит аны да йоклатмый. Икесе бер бүлмәдә яшәгәч, ул балакайга да бик авыр булды. Төннәрен без дә бөтенләй йокламый башладык.

Әни «ярый», «ярамый»ларны бөтенләй онытты: никадәр сакласаң да, барыбер кирәкмәгән эшне эшләп куя. Зөлфия гел минем белән кайтып йөри алмады – әни белән Гөлназны юындырырга авылда ук өйрәндем. Беренче тапкырында еладым... Уңайсыз иде: үскән сеңел белән карт әнине ничек чишендерергә, ничек юындырырга? Әни дә читенсенә: «Болай ярамый бит инде», – дия иде. Күнәсең икән... Ашарга пешерергә, кер юарга, өй җыештырырга – барысына өйрәндем. Хәзер андый эшләрдән курыкмыйм.

Әнинең акылы тәмам китте, ә теле ачылды – тотынды бертуктаусыз сөйләргә. Гомер артыгын сөйләмәгән әни бу! Әллә никадәр яңа тарих чыкты, әллә ниләр белдек. Барысы да безнең гаилә турында бит. Кызык! Күз алдына китерегез: кеше йомылып яшәгән дә, хәзер ни уйлый – шуны сөйли. Бөтенләй икенче кешегә әйләнде. Ачылып киткән әни белән миңа кызык иде. «Их әни, гел шундый булган булсаң...» – дип уйлый идем. Әнинең җиңеләеп сөйләве ул чакта күпмедер безне саклагандыр да. Бер елап, бер көлеп яшәдек. Киткәненә ике ел вакыт узды менә, ни хикмәт, авыр чаклар барысы онытылды. Ә әнинең кызыкларын искә төшереп әле дә көләбез. Кайбер сүзләре, канатлыга әйләнеп, безнең гаиләдә яши. Гел авырлыкны, аның үзен имгәтүләрен, бертуктаусыз үзен җәрәхәтләүләрен, төн йоклатмауларын гына уйласаң, акылдан язган булыр идек. Болай да зомбиларга әйләнгән идек инде... Ә ул көлдерә иде!

Аннан бермәлне әни... җырлый башлады. Монысы да көтелмәгән хәл булды. Элек мин аның җырлаганын бик сирәк ишеттем. Сорасаң: «Яшьрәк чакта көем бар иде, хәзер бетте», – дия иде. Иң кызыгы шул – күп җырларының сүзләре таныш түгел. (Халык көйләрен мин үзем дә байтак беләм югыйсә.) Кайчак соңгы ике юлын җырлый да: «Монысын үзем чыгардым ахрысы, ипсез булды», – дип куя. Башта көлдек кенә. Аннары игътибар белән тыңлый башладык: җырларын бик сирәк кабатлый. Зөлфия белән икәүләп язып барырга

керештек. Ишеткән, хәтерләп калган, өлгергән кадәрсен. Шактый җыелган менә:

Су буена төшәр идем,
Су буе тирәк булса.
Ташла, дустым, бер сүзем юк,
Матурлар кирәк булса.

Агыйделгә егыла яздым,
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр җәйгән җиләк кебек,
Китмәдең йөрәгемнән.

Сандугачлар, карлыгачлар,
Минем былбылларымдыр.
Уйлар уйлап, елап-елап,
Саргаер елларымдыр.

Әни бездә яшәгән бер ел да җиде ай эчендә ни генә булмады! Бермәлне мин аның иренә «әйләндем» һәм ул мине Зөлфиядән көнли башлады. «Үзең ять-яшь, безнең арага кердең, балаларыбыз да бар бит», – ди. Зөлфия көнгә ун тапкыр астын алыштыра, кашыктан ашата, төне буе аңа су ташый, ә әни аны сүгә... Шуңа охшаш әйберләр көн аралаш кабатлана иде. Ә кайчак әни балага әйләнә. «Әйдә әле, тагын бер кашык ботка кап. Кирәк! Төкермә!» – дип аның белән үзенчә сөйләшергә туры килә...

Мондый хәлгә юлыккан кешеләр байтак икән. Хәтта үзебезнең таныш-белешләр арасында да – боларны әнине җирләгәч кенә ишеттек. Җеназасы өстенә килгәч: «Фәлән белән дә шулай булды, фәлән апа да шулай саташты», – дип сөйләделәр. Күпләр, «өйдәге сүз читкә чыкмасын», дип тырыша. Югыйсә чирнең ни ояты бар?! Якыннарыңа карата шундый шик туса, аларга бик игътибарлы булырга кирәк. Ә инде авыру бөтенләй басып алгач, синнән сабырлык кына сорала. Әмма ул берничек тә җитмәячәк... Тормыш бит туктамый: баланы мәктәпкә, түгәрәкләргә йөртергә, каршы алырга, озатырга кирәк. Эшең бар. Һәм барысы да шушы ике авыру белән үрелеп бара: бертуктаусыз табиб яки «ашыгыч ярдәм» чакырасың, очсыз-кырыйсыз кәгазьләр тутырасың... Син өлгерә алмыйсың. Арасың... Безнең дә төрле чаклар булды: тавыш күтәргән дә, катырак әйткән дә... Боларга да әзер булырга кирәк.

Икенче җәйне әнине авылга алып кайттым. Алып кайтмасам, гомер буе үкенермен дип уйладым. Өйне ул бөтенләй танымады. Бер мизгелгә генә ачылып: «Кара, йортта чирәм үскән», – дип куйды.

Җирләү мәшәкатьләрен бөтенләй хәтерләмим дә. Күңелемдә һаман да авылдашларга әйтеп бетермәгән рәхмәтем генә йөри: без кайтышка өйне ачканнар, бар нәрсәнең хәстәрен күргәннәр, зиратта урын билгеле, әзер... Элек гадәти күренеш булгандыр бу, әмма хәзер заман башка бит. Бөтен җирдә дә халык болай күмәк түгел, диләр. Нигезне ташлаганыбыз юк – кайтып йөрибез: җәен – атна саен, кышын – ике атнага бер. Гөлназ да авылны бик ярата: «әни янына кайтам» ди.

Әни безне шактый үзгәртеп китте. Беренчедән, Зөлфия белән тагын да якынайдык. 20 ел бергә яшәсәк тә, буй җиткән уллрыбыз, кызыбыз булса да, «Әниләрне алып килсәм, Зөлфия нишләр, түзәрме?» дигән уй башка кергәли иде. Куркуларым урынсыз булып чыкты. Мин аңа моның өчен бик рәхмәтле. Авыл кызы түгел, шәһәр баласы бит әле ул. Бөтенесен бергә күрдек: йокысыз төннәрне бергә кичтек, бергә көлдек, еладык...

Әни мине аракыдан арындырып китте. Ниһаять, дөньяның ямен белә башладым. Яшисе килә, кайчан тизрәк көн туар икән дип йокыга ятам – мине эшләр көтә.

Әни туганнар, апаларым белән дә араны якынайтып китте. Аларның берсе – Алабугада, икенчесе Сарманда яши. Икесе дә кияүдә – кеше кешеләре. Шулай булгач, әнине минем каравым гаҗәп түгел: төпчек малайның бурычы бит ул. Әнинең иң авыр вакытлары Флера апаның Казанга килеп эшләгән чагына туры килде. Бөтенләй хәлдән тайганда гел аңа шалтыраттым – ул хәзер килеп җитә һәм шундый җиңел була иде...

Инде иҗат турында. Мин аңардан аерылмадым. Беренчедән, елга ике-өч концерттан артыкны беркайчан куйганым юк. Бу – әни авырганда да шулай булды, хәзер дә шулай. Киресенчә, бәлки әнине караганда алар миңа ял гына булгандыр. Хәтта әзерләнү эшләре авыр барса да. Тормышта күпме күбрәк кичерсәң, эчке дөньяң шуның кадәр байый. Сынаулар сине картайтмый, олыгайта, хисләрне генә тирәнәйтә. Ә хисләр тирәнәю иҗатка уңай тәэсир итә. Нәрсә хакында җырлаганыңны аңлабрак җырлыйсың – ул тавышка да чыга.

Әнине җирләгәч, яши башладым дип әйттем инде. Кырыкны узсам да, мин һаман «әни малае» булганмын. Юк, алай ит, болай ит дип өстемдә тормады ул минем, безнең эшләргә беркайчан кысылмады, Зөлфиягә беркайчан авыр сүз әйтмәде һәм миннән дә әйттермәде. Сүз эмоциональ бәйләнеш турында бара. Күзгә күренмәгән җепләр белән гел үзенә бәйләп тотты. Әгәр әни мине вакытында «җибәрә» белгән булса, миңа җиңелрәк булыр иде, мөгаен.

Үкенечләр... Әлбәттә, бар. Мондый вакытта ансыз булмый. Үкенечләрнең берсе – әнине бер елга булса да иртәрәк үзебезнең янга аласы калган. «Фәлән вакытта дәшмәскә, фәлән вакытта икенче төрле эшләргә кирәк булган» дип тә уйлыйсың кайчак. Әнине җирләп, беркадәр вакыт узгач, мин төш күрдем. Имеш, йокымсырап ятам. Ап-актан киенгән әни әкрен генә яныма килде дә юрганымны җайлап япты. Бит очымнан гына үпте дә әкрен генә китеп барды... Уянып киттем... Бу матур төшне әнинең миннән ризалыгы дип кабул иттем.

Бик күп авырлыклар күрсә дә, әни бу дөньядан җырлап китте. Әлбәттә, аны тагын да кадерләбрәк яшәтеп булыр иде. Әмма без кулдан килгәннең барысын да эшләдек.

Гөлнур САФИУЛЛИНА язып алды.



МӘҢГЕЛЕК ТҮН ИЛЕНДӘ



Алсу ХӘЛИМОВА

Моннан ике ел элек Мәскәүдән Камчаткадан сигез сәгатьлек очыш вакытында очкычның Себер аша дуга ясап очуына игътибар иткән идем. Логика буенча, болай юл ераграк, озынрак булып чыга кебек тоелса да, чынлыкта очыш иң кыска траектория буенча бара. Бу – Җир шарының түгәрәк булуына бәйле. Ә аста иксез-чиксез Себер киңлекләре... Меңләгән чакрымнарда бер генә торак пункт та күренми... Үзеннән-үзе: Ә анда нәрсә соң?» – дигән кызыксыну барлыкка килде. Бер елдан соң инде мин Путорана яссытаулыгында басып торам һәм һавага карап Россиянең көнчыгышына таба юл тоткан очкычларны күзәтәм...

Путорана яссытаулыгы мәйданы буенча Бөекбритания территориясе кадәр булса да, Россиянең иң аз өйрәнелгән һәм зур кыенлыклар аша узып кына барып җитәргә мөмкин булган урыннарының берсе.

Сәяхәтемнең төре – поход булачак. (Тормышымдагы иң катлаулы походларның берсе булып истә калачагын мин әле соңрак аңлаячакмын!) Төркемебез Россиянең төрле шәһәрләреннән килүчеләрдән тупланды: кемдер Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, кемдер – Владивостоктан... Барысы да поход яратучы сәяхәтчеләр! Казаннан мин берүзем. Юлдашларым арасында төрле һөнәр ияләре: табиблар, it-белгечләр, хәрбиләр, эшмәкәрләр... Әлегә кадәр таныш булмасак та, дөньяга позитив караш, сәяхәтләр ярату, авырлыклар безне туганнардай берләштерде – бик тиз уртак тел таптык.

Инструктор белән бергә унау булачакбыз. Катерга шуннан да артык кеше сыймый. Таләпләр катгый: рухи яктан тотрыклы булудан тыш, физик яктан да көчле булу сорала. Физик форманы тикшереп карау өчен түбәндәге тестлар тәкъдим ителә: биек йортның илленче катына 12 минут эчендә менеп җитәргә яки шушы вакыт эчендә бишенче катка ун тапкыр менеп төшәргә; биш чакрым араны 24 минутта йөгереп узарга... Иң мөһиме: тестларны узгач, син арып егылырга түгел, ә 10–15 минут ял иткәннән соң, барысын да яңадан кабатларга әзер булырга тиеш.

Июль аеның икенче яртысы. 30 градус эсселеге белән Мәскәү болытлар астында калды, биш сәгатьтән очкыч командиры: «Норильск шәһәренә төшәбез», дип игълан итә. Борт артында җылылык нибары алты градус...

Норильск – чит ил гражданнары өчен ябык шәһәр, алар бирегә махсус чакыру буенча гына килә ала. Россия гражданнарын исә Алыкель аэропортында паспорт контроле көтә. Ниһаять, такси тотып шәһәргә юнәләбез.

Эвенк теленнән «Путорана» текә ярлары булган күлләр дип тәрҗемә ителә.


Юл кырыйларында инде кар ята... Такси йөртүче безне – «материктан килгән кунаклар»ны шәһәр белән таныштыра. Ни өчен материктанмы? Чөнки бу якларны үзәк Россия белән тоташтыручы җир юллары юк. Бирегә ике генә юл белән килеп була: беренчесе – Мәскәү–Норильск, Красноярск–Норильск һава юллары һәм икенчесе – Красноярск шәһәреннән теплоходта Енисей елгасы буенча. (Килгәндә, бу «сәяхәт»кә дүрт көн вакыт китә, кайту юлы агымга каршы булганлыктан, алты көнгә сузыла.)


Моннан берничә еллар элек завод эшчеләре елларда Мәскәүгә... сыра эчәргә очкалаган. Хәзер авиабилетлар шактый кыйммәт, эшчеләрнең хезмәт хакларын да исәпкә алсаң, мондый «батырлыклар» үткәндә калган.

Шәһәргә килеп җиткәч, иң элек инструкторыбыз һәм походка бергә барасы юлдашлар белән очрашабыз. Азык-төлек модульләрен бүлеп, рюкзакларны үлчәп карыйбыз: авырлыгы 20 килограммга җитә. Хәер, яхшы рюкзакның үзенең генә дә авырлыгы 3–3,5 килограмм инде аның. Шуңа өстәп – палатка, «спальник», каремат, аптечка, кием-салым, шәхси гигиена әйберләре, треккинг таяклары, газ баллоннары, черкиләрдән репеллентлар... Рюкзакның өчтән бер өлеше азык-төлек модульләре өчен буш калырга тиеш.

Валёк портына юл тотабыз, анда безне катер һәм Лама күле буйлап сигез сәгатьлек юл көтә. Палубаның өслеген двигатель җылыта – шунда ук барыбыз да изрәп йокыга тала...

Автор фотолары





Концлагерь тоткыннары да Путорана якларына таба качмаган – биредә исән калу мөмкинлеге юк…

Алдагы берничә көн эчендә яссытау өслегенә менәчәкбез. Шактый катлаулы булачак бу. Маршрутның туксан процентында юллар бөтенләй юк. Монда кешеләр яшәми – элемтә турында сүз дә булу мөмкин түгел. Гел ташлар буйлап йөрергә туры киләчәк. Ниндиләре генә юк аның биредә! Кайсылары бик таклар, кайберләре – кешедән дә берничә тапкырга зуррак. Тере ташлар! Тик «тере» сүзе бу очракта романтик күрсәткеч түгел, ул куркынычлылык дәрәҗәсен аңлата. Төрле төстәге лишайниклар белән капланган ташлар яңгыр яву белән шугалакка әйләнә. Син инде гадәти генә итеп атлый алмыйсың, ә чигү чиккәндәге сыман һәр адымыңны уйлап башкарасың. Югарыга менү бер авыр булса, төшүе – икеләтә авыр. Адәм затын беркайчан да күрмәгән тайга буйлап барганда, адым саен коры мүк эченә тезеңнән төшеп китәсең, ә яңгыр яугач, ул бөтенләй сазлыкка әйләнә. Кайвакыт 500 метр араны үтү өчен дә берничә сәгать вакыт кирәк. Өстәвенә, көндез дә, төнлә дә чебен-черки үзәгеңә үтә: аларны куркытыр өчен сиптерелгән спрейның тәэсире 5-6 минуттан озакка бармый. Бик күп тапкыр салкын елгалар аша кичәсең: мондый чакта тезеңнән генә булсалар да, яңгыр вакытында салкын су ташкыны билгә кадәр үк җитә. Армия складларында сатыла торган ОЗК бахилалары күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итә итүен. Биеклеге тездән югары булган әлеге резин итекләрне Казанда табу шактый кыен, әмма мөмкин. Аларның авырлыгы бер килограммнан артыграк – күтәреп йөрү мәшәкатьле, билгеле, ләкин мондый походта бу итекләрең булса әйбәтрәк шул. Ахыр чиктә без аларны ике минут эчендә киеп-салырга остарып беттек.

Тайгада учак ягып ашарга пешерү, җылыну, киемсалымыңны азмы-күпме киптерү мөмкинлеге булса да, тау массивына күтәрелгәч, монысы да бетте: агачлар юкка чыкты. Ашарга әзерләү бары тик газда гына калды.

Камчаткада син җирнең сулавын тоясың, ул парлар, фумаролалар бәреп чыгара, кайнар сулы чыганаклары белән сине шаккаттыра. Путорана тау массивы да моннан 252 миллион ел элек актив булган гигант янартау эшчәнлеге нәтиҗәсе дип санала. Метеоритның җир белән бәрелүе нәтиҗәсендә барлыкка килүе – икенче бер гипотеза. Әлеге сергә төшенү безгә бирелмәгән шул… Тектоник көчләр тәэсирендә озак еллар дәвамында әлеге базальт өслек күтәрелгән һәм хәзер дә күтәрелүен дәвам итә. Күтәрелгән өслек яргаланган. Елгалар һәм бозлыклар ул ярыкларны тагын да киңәйткән, шул рәвешле каньоннар һәм шарлавыклар формалашкан. Путорана шарлавыкларга гаҗәеп бай.

Без барганда анда поляр көн хөкем сөрә иде. Төннәрен дә яп-якты. Шуңа да без 18–19 сәгать буе гел юлда булдык – кайбер көнне 30–40 чакрым уздык.

Кояшлы матур көннәрдән соң коеп яңгыр яварга тотынды. Болыт, чын мәгънәсендә, без тукталган тау битен чорнап алды. Өч тәүлек тоташтан койган яңгырдан соң, лагерь янындагы кечкенә генә күлдә су шактый күтәрелде. Йөзләгән гөрләвекләр, таулардан агып төшеп, безнең палаткаларга таба юнәлде… Үзәгеңә үтәрлек салкын… «Агып китә калсак, корабыбызга нинди исем бирербез икән?» – дип, бер-беребезнең күңелен күтәрергә, көлдерергә тырышсак та, тынычсыз йокыга талабыз… Иртән «кичекмәстән үзәнгә төшәргә кирәк» дигән карар кабул ителә. 200 метр биеклекне артта калдыруга ук тирә-юнь күренә баш-





Путорананы юкка гына «ун меңләгән күл һәм меңләгән шарлавыклар иле» дип тә атамыйлар. Ул шарлавыкларның барысының да хәтта исеме дә юк: алар картада саннар белән генә билгеләнгән. Йөзләгән метрдан агып төшә торган суның өслегендә салават күперен күрү өчен упкын кырыена шуышып килергә генә кыюлыгың җитә…

лады. Яңгыр тамчыларына кушылып, биттән күз яшьләре ага...

Таудан төшү өч көн вакытны алды, ләкин инде күпкә җиңелрәк иде. Тайгада күк җиләкнең өлгергән мәле, ашарга яраклы гөмбәләр очрый, иван-чәй үсә. Учак ягып җылыну мөмкинлеге бар. Календарьда – 30 июль, башыңны югары күтәреп тауларга карыйсың, ә анда кар ява... Әйтерсең лә, тормышыңдагы беренче кар...

Алдан килешенгәнчә, берничә көннән катер Лама ярларыннан безне кире килеп алды. Шәһәргә юл тотабыз, ә уйларым белән әле һаман тауларда... Норильскиның һәрчак төтенләп торган торбалары, соры күге белән Путоранадагы илаһи матурлык, мәгърур таулар арасында гаҗәеп контраст тоям. Киң кодрәте, чиксез мәрхәмәте белән шуларны күрү бәхетенә ирештергән Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укыйм. Һәм... 15 көнгә беренче тапкыр, шалтыратып, гаиләмә исән-иминлегемне хәбәр итәм...

Шәһәргә кайткач, күпме генә ашасаң да, тук булуыңны һаман сизмисең. Киптерелгән болан ите – юкколаны кабып карадык. Ә менә ул чакта сгущенкалы трубочкаларны сгущенкага манып ашый алуыма әле дә гаҗәпләнәм...

Норильск шәһәре, Кайеркан, Талнах эшчеләр бистәләре белән танышырга да бераз вакыт кала. Шәһәр зур түгел, бер очыннан икенче очына барып җитәргә күп вакыт кирәкми. Җилдән саклану максатыннан өйләр бер-берсенә бик якын урнашкан, һәм алар арасында тар гына үтеп чыгу юллары бар. Йортларга номерларны икешәр метр зурлыкта язганнар – кышкы бураннарда ялгышмыйча тизрәк табу өчен. Юлларга бездәге сыман химик реагентлар түгел, ә кара шлак сибәләр икән. Эстетик яктан бик үк матур булмаса да, кешенең сәламәтлегенә, аяк киеменә, этләрнең тәпиләренә, автомобиль шиналарына аның зыяны юк.



Кышын бу якларда салкынлык 50 градуска җитә. Поляр төн исә 45 тәүлеккә сузыла. Җәй бик кыска. Җирле халык әйтүе буенча, Таймыр ярымутравы өчен бу җәй шактый салкын санала.

Шәһәрнең музеена кереп чыгарга да өлгердем. Норильск – ГУЛАГ корбаннарының сөякләреннән төзелгән шәһәр. Мәңгелек туң илендә аларны хәтта күмеп тә мәшәкатьләнмәгәннәр. Шуңа күрә кыш тәмамлану белән җир өстендә мәетләр пәйда булган... 1935 елдан 1956 елга кадәр концлагерь аша узган корбаннарның төгәл саны әле һаман да билгеле түгел. «Сталин җәһәннәменең тугызынчы боҗрасы» дип атаганнар бу якларны. Тарихның кат-кат язылып та, барлык вакыйгаларны да объектив күрсәтмәве аптырашта калдыра. Әмма халык хәтере исән әлегә... Гаҗизләнеп, музей алдындагы баскычларга чыгып утырам, куллар, әлеге җаннарга тынычлык сорап, догага күтәрелә...

Әле ике атна элек бөтенләй таныш булмаган юлдашларым белән инде якын дуслар кебек хушлашабыз. Алыкель аэропортының очыш полосасы кыска: ягулык тулы баклар белән очкыч күккә күтәрелә алмый. Шуңа күрә ул өстәмә ягулык алу өчен Яңа Уренгой аэропортында туктала. Аннан – Мәскәү һәм kояшлы Казан!

Казанга кайткач, үзеңнең бу дөньядан бик нык читләшкәнеңне аңлыйсың. Август ае – урамда иртә караңгылата: моңа күнегә алмый интегәсең... Телефон шалтырый: аның нигә шалтыраганына гаҗәпләнәсең... Колакларың шәһәр шау-шуыннан бик тиз арый... Төшләреңдә үзеңне тайгада, тауларда күреп сискәнеп уянасың... Анда күргән, кичергәннәрне бу юлларга, бу җөмләләргә берничек сыйдырып бетереп булмый...

Бераз соңрак, дуслар җәйге яллардан алган якты тәэсирләре белән бүлешә башлый: Төркия, Португалия, Кырым, Сочи... Дәшмәскә туры килә...

Нәрсә алып кайтырга

Норильск шәһәрендә сувенирлар берничә җирдә генә сатыла – сайлау мөмкинлеге чикле, бу тармак бездәге кебек үсеш алмаган. Юлдашларым күчтәнәчкә болан итеннән казылык, киптерелгән болан ите – юккола алды. Безнең өчен гадәти булмаган ризык: тәмле тоелса да, күп ашап булмый. Мин үзем Платодан төрле-төрле берничә таш җыеп кайттым. Гадәти булмаган ул ташларның әлегә берсенең генә «кальцит в хлоритовой рубашке» икәнен ачыклый алдым. Калганнарын Санкт-Петербургта яшәүче геолог дустыма күрсәтергә уйлап торам. Әмма шул берничә ташны алып кайту да маҗараларсыз гына булмады. Аэропортта безне сак хезмәткәрләре тоткарлады. Ташларны алып китәргә ярамаганлыгын аңлаттылар, ләкин бу карар язылган документларны күрсәтүебезне үтенгәч, үзара киңәш иттеләр дә... безне үткәрергә булдылар.

PRESSA

«УЛ МИНЕ ҮЗЕМНӘН ЯХШЫРАК БЕЛӘ...»



Айдар ГАБДИНОВ, җырчы, Татарстанның атказанган артисты; гаилә стажы – 27 ел; өч бала әтисе.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар кертә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Башкалар ничектер, белмим, мин янымнан үтеп киткән хатын-кызның башта буй-сынына карыйм. Хәер, бөтен ир-атлар да шулайдыр дип уйлыйм: без, үзебез дә сизмичә, хатын-кызга репродуктив яктан бәя бирәбез бугай. Ул безгә табигатьтән салынган. Шулай дим дә... Зилә белән танышканда мин бит иң элек аның тавышына игътибар иткән идем! Башкорт дәүләт университетында укып йөргән чагым. Тулай торакта яшим. Мин ул чакта каратэ белән шөгыльләнә идем. Ул көнне дә тренировкалардан арып кайтып ял итәргә яткан идем. Йоклап китәм дигәндә генә, безнең ишек төбендә ниндидер кызлар чыркылдаша башлады. Бераз тыңлап яткач, кемнәр икән болар дип карарга чыктым... Әйе, ул чакта мин аның буй-сынына игътибар да итмәдем. Иң элек чәчләрен, күзләрен күрдем...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Азрак ачу китергән яклары бар инде хатын-кызның. Әйтик, бертуктаусыз телефоннан сөйләшүе. Кайчак өйдә икәү аралашып та булмый, чөнки ул телефоныннан бушамый. Зилә мәктәптә укыта: өйгә кайткач та әллә никадәр мәсьәлә хәл итә. Дөньясы шулай бит аның хәзер... Түзәсең, әлбәттә, гафу итәсең...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Алдашуын һәм ялганлавын кичереп булмыйдыр. Андый хатын-кызга инде ничек таянасың? Ә хыянәтне менә кайсыдыр очракта гафу итәргә дә мөмкиндер. Кем нәрсәне хыянәт дип кабул итә бит?! Әйтик, чит ир белән чит хатын бер-берсенә мәхәббәтле итеп карап куя. Бәлки араларында, чыннан да, мәхәббәттер, тик алар аның ярамый икәнен аңлый. Һәм мөнәсәбәтләр шул караштан ары узмый. Йә, бу хыянәтме, түгелме? Мин «юк» дияр идем... Яки менә икенче бер мисал. Бер танышым сөйли. Туй барганда тамадалар нинди генә уен уйнатмый бит хәзер. Бу хатынның бер уенда урыны икенче ир белән туры килгән. Ә уенда хәтта күршең белән үбешергә дә кирәк булган бугай. Әлеге хатынның ире туй барганда ук зур гауга куптарган. Хатынга да эләккән, күршегә туры килгән ир-атка да...

«Ир хыянәт итсә – йортның түбәсе, хатын-кыз хыянәт итсә, өй нигезенә кадәр яна» дигән мәкаль бар безнең халыкта. Шуннан аңлашыла инде ир-атның нигә хыянәтне гафу итмәве.

4 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Әлбәттә, була ала! Әле сезнең белән очрашыр алдыннан көлеп сөйләштек. «Кайбер җавапларны синнән шалтыратып сорармын», – дим. «Әйе, мин бит сине үзеңнән дә күбрәк беләм», – ди. Димәк, ул миңа дус булмый кем була инде?! Дошман белән бергә яшәмәс тә идек... Матур гаиләләрдә хатын дус булырга тиеш дип саныйм. Дөрес, башкача яшәүчеләр дә бар. Ире зур урында эшли, зур кешеләр белән йөри, зур акчалар эшли. «Кыйммәтле тун киясең киләме – ал, иң әйбәт урында ял итәсең киләме – бар. Күңелең булдымы? Шулай булгач, тагын ни кирәк сиңа? Минем эшләргә тыгылма», – ди. Бер-берең белән киңәшләшмәгәч, нигә кирәк ул парлы тормыш?!

5 Хатынызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Безнең ничек танышканны алдарак сөйли башладым инде. Ачкычларын икенче бер бүлмәдәшләре алып киткән дә, бүлмәләренә керә алмый тора икән болар. Миңа аларның кайсы бүлмәдә яшәүләрен белү кирәк иде. Теләгемә ирештем! Икенче көнне студентларның кичен бер-берсенә чәйгә йөрешә торган вакытына туры китереп, ишекләрен шакыдым. Кемгә өстенлек күрсәткәнемне җайлап кына башкаларга да һәм аның үзенә дә сиздереп сөйләшеп утырдым. Икенче көнне киногачакырганым истә. Шуннан башланып китте инде... Кичләрен тулай торакның аулаграк почмакларында, тәрәзә төпләрендә сөйләшеп торабыз. Әкренләп кенә аңа миңа кияүгә чыкса ничек әйбәт булачак дигән уйны төшендерә һәм сеңдерә башладым. Бергә яшәү матди яктан да отышлырак дип инандырырга тырыштым. Башкортстанның икебез ике ягыннан без. Май бәйрәмнәренә мин аны үзебезгә кунакка алып кайттым. Дус дип кенә. Әмма әти-әниләргә барыбер белгертәсе килгәндер

инде. Ә 9 Майга Зилә мине үзләренә Бакалыга чакырды. Шуннан соң безнең әти-әниләр бер-берсе белән элемтәгә кереп... никах турында килешеп куйганнар. Ә безгә кызык! Ничек була икән ул, карап карыйк дибез, ризалаштык. Никах 11 июньдә булды. Август аенда туй ясадык та бергә укырга килдек. Икәү бер бүлмәдә яши башладык. Бер кичне, элеккеге гадәт буенча егетләр белән каядыр чыгып китәргә җыенганда, кинәт башка суккандай булды: «Миңа ярамый бит хәзер!» Бөтен уем, фикерем, бар булмышым забастовка күтәрде – ничек ярамый? «Син бит инде өйләнгән кеше», дим үз-үземә. Туйда утырганда моны тою барлыкка килгән иде анысы. Әмма дусларга ияреп үзем теләгән җиргә чыгып китә алмавымны барыбер ахыргача күз алдыма китермәгәнмен. Минем – өченче, Зиләнең икенче курста укыган чагы бу.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Бу хакта уйлаганым бар минем. Зилә әниемә охшамаган: йөз-кыяфәте белән дә, холкы белән дә. Әмма үзем дә сизмәстән, әнинең яшь чагын хәтерләткән кызларга карап куйганымны беләм. Яратып, үз итеп, ошатып... Зилә очрамаса, ихтимал, әни кебек кызны сайлаган булыр идем...

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Бу ситуациядә хатын белән ир үзләрен ничек тотачак – бар да шуңа бәйле. Акыллы хатын булса, ирен бөгеп маташмаячак, әлбәттә. Тормыш бертөсле генә бармый. Бездә дә Зиләнең күбрәк акча эшләгәне булды. Үз тырышлыгыбыз белән генә мал табып көн итәбез. Әти-әниләр авылдан бәрәңге, ит белән генә ярдәм итә алды – калганын үзебез булдырдык.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бик әйбәт карыйм. Әмма кыз бала егет кеше алдында үзенең дәрәҗәсен саклый белсен. Монысы мөһим фактор. Шушы көннәрдә күргән бер күренеш гел күз алдымда. Подъезд ишеге төбендә егет белән кыз кочаклашып басып торалар. Егет тәмәке тарта, төпчеген суыра да, төтенен кызның битенә чыгара. Мескен кыз...

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Үзем буйга бик зур булмаганга әллә көнләшеп сөйләвемме икән, әмма мин инанып әйтә алам – хатын-кызны ир-атларда буй-сын җәлеп итә. Аңа мәһабәт буйлы ирләр кирәк. Кайберсе хәтта акылына да карамый, ул хакта, гомумән, уйлыйсы да килми. Үзе теләгән сыйфатларны башында әлеге ир-атка «тагып» куя да...

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта...

– Юк, алайдыр дип уйламыйм. Хатын-кызлар үзе уйлап чыгарган миф бу. Ир-атлар белән аралашуда берәр фиаско булганда, «мин чибәр, көчле шул, алар шуңа миннән курка», дип әйтергә маташалар. Хәер, юл йөрү кагыйдәләре түгел бит – төрле очраклар бардыр. Көчле һәм чибәр хатын-кыз акыллы да икән, бу бит үзе бер байлык!

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Шушы көннәрдә генә булды бу хәл. Тар гына юлда ике машина очраштык. Каршыдагы машина руле артында яшь кенә кыз иде. Кагыйдә буенча, ул үтеп китәргә, аннары мин кузгалырга тиеш. Әмма ул туктады һәм беркая да китәргә җыенмый. Минем төтен булып юкка чыгуымны көтте бугай. Машинам белән бергә... Тик мин беркая да юкка чыга алмау сәбәпле, башта сабыр гына көттем. Аннары аңа юлны үзем күрсәтеп карадым. Барыбер урыныннан кузгалырга җыенмады. Әле миңа бармак белән ямьсез ишарә ясый: мин түгел, үзең теләсә нишлә дип әйтергә теләве. Нинди логика белән уйлагандыр, нигә проблема тудыргандыр, аңламадым. Карап-карап тордым да, икенче юлга чыгып, шуннан китеп бардым – ягъни мәсәлән, бу «каршылык»ны урап уздым.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Мондый хәлгә еш очрадым дия алмыйм – Зилә андый түгел. Без һәрвакытта да консенсуска киләбез. Докладларын тыңлагач, Сталин үзенең хәрби начальникларына: «Барыгыз, күрше бүлмәгә чыгып тагын бер кат уйлап карагыз», – дия торган булган. Мин дә шулай. Әгәр ул бик инанып исбатлый икән, күп очракта юл куярга тырышам – димәк, белеп сөйли.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Мин беркайчан ач калмыйм. Мәсәлән, бәрәңгене яратам – тулай торакта яшәгәндә без аны 10 минут эчендә пешерә идек. Кафега чыгып китмим, пиццага да заказ бирмим – миндә андый гадәт юк. Кул астында нәрсә бар, шуннан нидер пешерәм. Һичьюгы, чәй булса да кайнатып эчәм. Шәһәрдә яшибез ләбаса: печән чабып кайтмаган, таш ярмаган. Без күбрәк мораль-психологик яктан арыйбыз. Көннәр буе печән чабудан аерыла бу: авылда кырдан кайткач, тамак ялгыйсың да кабат нидер эшләргә әзер буласың. Ә монда каядыр барып ике җыр җырлыйсың да, өйгә хәлең бетеп, сыгылган лимон кебек булып кайтып керәсең. Энергияң бик күп китә.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Бүләк ошамаска мөмкин дип, башыма да кергәне юк иде... Зилә дә, кызым Айсылу да миңа ни кирәген белә – күп вакыт бергә үк чыгып алабыз да. Сәхнә кешесенә еш кына костюм кирәк инде... Җырчы кешегә чәчәк биргәниләр – Зиләгә шуларны алып кайтам. Сатып алганым да юк дисәм... Күптән инде бер кочак розалар бүләк иткән идем. «Нишләп акча бетереп бу кадәр алдың?» – диде. Шулкадәр зур бәйләм алмый идем. Уфада чак әле бу. Чәчәк сайлап торганда Айдар Галимовның хатыны Зилә килеп очрады. «Менә монысы матур», – дип ул күрсәтте. Аның алдында махы бирәсе килмәде инде... Соңгы чәчәк бәйләмнәрен Зиләгә малайлар тугач алган идем. Уллар туу әти кешегә зур шатлык бит. Ильяска – 15, Мансурга 14 яшь инде. Концерттан кайткан чәчкәләр белән канәгатьләнәбез. Укытучы бит – үзенә дә гел биреп торалар.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru



Ортодонтка соравым бар

Һәрберебез дә балаларыбызның тешләре сәламәт, матур булуын тели. Моңа ирешү өчен баланың казналыгын кечкенәдән үк дөрес формалаштырырга кирәк, ди белгечләр. Бу җәһәттән ата-аналарны күп кенә сораулар да борчый: баланы ортодонтка ничә яшьтән күрсәтергә, брекет системасын кайчан куярга? Шушы һәм башка сорауларыбызга Казан шәһәренең 5 нче балалар стоматология сырхауханәсенең 1 нче категорияле табиб-ортодонты Руслан ЛАТЫПОВ җавап бирә.

Казналыкның дөрес формалашмау сәбәпләре төрлечә булырга мөмкин. Болар:

- сөт тешләрен вакытында дәваламыйча, аларны иртә алдыру;
- баланың, борыны белән суламыйча, авызын гел ачык тотуы;
- 2-3 яшькә кадәр имезлек имүе яки бармак суыруы;
- нәселдәнлек;
- рационда каты ризыкларның җитмәве;
- тиешле вакытта тешләрнең алышынмавы.

Иң еш очрый торган җитешсезлек – тешләрнең өелешүе һәм аскы казналык белән өске казналыкның бер-берсенә туры килмәве.

Күпләр баланы ортодонтка 14 яшендә – сөт тешләре тулысынча алышынгач кына күрсәтергә кирәк дип уйлый. Бу – ялгыш фикер. Баланы ортодонтка беренче тапкыр 3-4 яшьлек чагында күрсәтәләр. Табиб, кирәк дип тапса, миогимнастика һәм бәләкәчне тиешсез гадәтләреннән биздерү өчен махсус аппаратлар билгели. 7-8 яшьлекләргә исә алынмалы ортодонт пластиналар һәм трейнерлар билгеләнә. Брекет-системаларны тешләр тулысынча алышынып беткәндәрәк куйдыру яхшырак. Әлбәттә, болар гомуми киңәшләр. Һәр очрак үзгә һәм һәркем өчен индивидуаль киңәш кирәк.

Ортодонтка түбәндәге очракларда күренергә кирәк:

- баланың тешләре тиешле вакытка чыкмаса;
- алар үз урыннарында утырмаса;
- өске тешләр белән аскы тешләр бер-берсенә тиеп тормаска;
- өске яки аскы казналык алга чыгып торса;
- балага ризыкны чәйнәве кыен булса;
- авазларны әйтә алмаса;
- тешләр ике рәт булып чыкса.

8-9 яшьлек балаларда тешләрнең дөрес урнашмавын алынмалы пластиналар ярдәмендә төзәтергә мөмкин. Мондый пластиналарны көн дәвамында киеп йөреп, ашаганда һәм йоклаганда салып куялар. Җитешсезлекнең нинди дәрәҗәдә булуына карап, пластина, уртача, алты айдан артыграк вакытка киелә.

Кайбер очракларда күпфункцияле трейнерлар да кулланыла. Аларын көнгә 2-3 сәгать дәвамында һәм төнгелеккә киясе. Трейнерлар балага кирәксез гадәтләреннән арынырга булыша. Әмма алынмалы пластиналар казналык белән бәйле барлык проблемаларны да хәл итә алмый. Кайчагында пластиналардан соң брекет системасы урнаштыру да кирәк була. Брекет системасы беренче мәлләрдә балага шактый мәшәкать тудырганлыктан, пациентның табиб белән даими аралашып торуын да сорый.

Кыек булып чыккан тешләр, матур булмаудан битәр, сәламәтлеккә бәйле проблемаларга китерә. Тешләре аркасында бала дөрес итеп сөйләшә алмаса, ныклап чәйни алмаса, елмаерга кыенсынса, билгеле, киләчәктә бу аңа кыенлыклар тудырачак. Әти-әниләр моңа җитди карарга тиеш.

Табиб киңәше

- Балаларның буш имезлек, бармак суыру кебек гадәтләре белән көрәшергә кирәк. Буш имезлек имүдән (соска-пустышка) баланы 6-8 айлардан ук биздерә башлагыз.
- Сөт тешләрен вакытында дәвалатырга кирәк. Аларның тәмам җимерелгәнен көтәргә ярамый.
- Тешләр дөрес формалашсын өчен, баланың кулына кишер, алма, сохари ише каты ризыклар бирегез.
- Бала борыны белән суларга тиеш, игътибарлы булыгыз.
- Тешләрнең дөрес чыкмавын күрү белән, ортодонтка язылыгыз.



Мигреньне контрольгә алабыз

Бу чир турында Михаил Булгаков хәтта үзенең «Морфий» әсәрендә дә яза: «Иртән торасың, чигәдәге авырту баш түбәсенә үрмәли, ярты башны чүки...»
Кешеләрнең эшкә сәләтен шактый киметеп, медико-социаль, һәм социаль-икътисадый проблемага әверелә барган әлеге чирнең билгеләре һәм дәвалау чаралары турында Татарстанның атказанган табибы, Россиянең сәламәтлек саклау отличнигы, табиб-невролог Диләрә АЛТУНБАЕВА белән сөйләшәбез.

Мигрень – даими кабатланучы, чигәләргә бәреп торучы көчле баш авыртуы. Гадәттә, башның бер ягы гына сызлый, авырту күзләргә, чигәләргә бәрә. Күңел болгану, яктылыкка, тавышка, исләргә сизгерлек арта. Физик активлыктан, башны игәннән, хәтта төчкергәннән дә сызлау көчәя.

Баш авыртуның барысы да мигрень булмый. Аны ачыклар өчен авыртуның даимилеген, күпмегә сузылуын, сызлау характерын, анамнездагы чирләргә карарга кирәк.

Баш кайчак артык киеренкелектән дә авырта. Бу очракта башның ике ягы да сызлый, ләкин ул физик нагрузка вакытында көчәйми.

Мигреньнең барлыкка килү механизмы катлаулы, сәбәпләре дә ахыргача ачыкланмаган. Ул тамырлар патологиясе аркасында барлыкка килә. Бу вакытта баш мие кабыгының церебраль тамырлары киңәя һәм якындагы нерв күзәнәкләрен кыса. Тамырлар тарайганлыктан, шул тирәдәге тукымаларга җитәрлек кан бармый, нәтиҗәдә, авырту барлыкка килә. Әлеге процесста серотонин матдәсе зур роль уйный. Аның микъдары артып киткәндә баш сөяге эчендәге тамырларда спазм башлана. Кан әйләнеше акрынаеп, тамырлар киңәйгәнлектән, авырту импульслары ясала, баш авыртуның сәбәбе әнә шул.

Баш өянәген кузгатучы факторлардан: көчле рухи яки физик киеренкелек, дөрес тукланмау (ләкин нинди ризык ашау түгел, ә нинди вакыт аралыгы белән күпме ризык ашау йогынты ясый), артык кырыс диета, исерткеч эчемлекләр, глютенлы ризыклар, салицилатларны (каты итеп пешерелгән яшел һәм кара чәй, бөтнек, аштәмләткечләр) да атарга була. Цитруслы җимешләрнең дә серотонин алмашы процессларын бозуы мәгълүм. Тәмәке тарту, эссе кояшта озак булу, көчле тавыш һәм ис, хатын-кызлардагы гормональ үзгәрешләр, йөклелектән саклаучы гормональ таблеткалар да – мигреньнең сәбәпчеләре. Йокы режимы бозылу да баш өянәген кузгатып җибәрергә мөмкин. Аз йоклау гына түгел, артыгын йоклау да зарарлы.

Мигрень белән хатын-кызның җенес гормоннары арасында тыгыз бәйләнеш бар. Хатын-кызларның 25 проценты гомерендә бер булса да баш өянәген кичерә, ә ир-атларда бу сан – 8 процент.

Баш авыртуы нинди генә сәбәптән килеп чыкса да, игътибарсыз калдырмаска кирәк. Иң элек терапевтка барып күренергә кирәк. Баш авыртулары даими кабатланса, ул неврологка юллама бирергә тиеш.

Мигрень дәвалый торган чир түгел. Традицион терапия ике юнәлештә алып барыла: башланган өянәкне туктату һәм мондый өянәкләр кабатланмасын өчен профилактик чаралар. Баш өянәгенең үзе бетүен көтү дөрес түгел. Вакыт узган саен, дәва чараларының нәтиҗәлелеге дә кими. Мигрень вакытында сызлануны, күңел болгануны баса торган дарулар белән ялкынсынуга каршы нестероидлы препаратлар комбинациясе кулланыла. «Алтын стандарт» дип триптаннар төркеменә керүче препаратларны атыйбыз. Көчле өянәкләр башланса, авыруны караңгы, саф һавалы, ләкин җылы бүлмәгә яткырырга кирәк. Башына һәм муенына җиңелчә массаж ясау, маңгаена салкын яки җылы компресс кую да булыша. Әмма үз белдегең белән дару эчәргә ярамый. Иң элек тикшеренергә кирәк. Фәкать комплекслы, һәркемгә индивидуаль һәм дөрес оештырылган дәва гына яхшы нәтиҗәләргә ирешергә, нәселдәнлек белән бәйле әлеге чирдән интегүче пациентның тормыш сыйфатын яхшыртырга мөмкин.

Табиб киңәше

- Мигреньне дәвалау тормыш рәвешен үзгәртүне дә сорый. Йокы һәм туклану режимын көйләү, рухи һәм физик киеренкелекне киметү мөһим. Ашау арасы биш сәгатьтән дә артык булмасын.
- Контраст душ, йөзү, диңгез тозы салынган кайнар ванна баш авыртуын киметергә ярдәм итә.
- Борчылсагыз, тынычландыручы препаратлар кулланыгыз.
- Кинәт кенә баш өянәге башланса, 15–20 минут йоклап алу булыша. Соңрак бер чынаяк каһвә эчеп, маңгайга салкын компресс куегыз.
- Чигәләргә ментол мае сылап, башны кысып бәйләү дә авыртуны киметә ала.

Чыхыртма



«Хуҗабикә» сәхифәсенең бүгенге кунагы Севда МАМЕДОВА – азәрбайҗан кызы. Бакуда туып-үссә дә, улы белән кызының туган җире булган Казан да үз аңа. «Һавасы, кешеләре, атмосферасы рәхәт», – ди ул. Балалары белән туган телләрендә аралашалар, үз халкының мәдәнияте, ризыклары белән таныштырып үстерергә тырышалар. Севда һәм аның гаиләсе белән танышкан көннәрдә алар төрки дөньяның зур бәйрәме – Нәүрүзгә әзерләнәләр иде. Бик үзенчәлекле итеп уздыра аны азәрбайҗан халкы. Февральнең соңгы сишәмбесеннән башлап 22 мартка кадәр һәр сишәмбе ишегалларында зур учак ягалар. Әлеге чорда табигатьнең дүрт җисеме бергә очраша дип санала. Беренче учакны яккан көн – Ялганчы чәршәмбе (безнеңчә сишәмбе була) диелсә, калганнары Ут, Су, Җил, Туфрак чәршәмбесе дип атала. Яше-карты: «Азарым, базарым бурда галсын», – дип, учак аша сикерә. Ел буена җыелган кара уйлардан, авыр энергиядән шулай арыналар. Соңгы учак ягылган көнне яшьләр, кулларына башлыклар тотып, күршеләрдән күчтәнәч җыя. Кияүгә чыкмаган яшь кызлар исә бу көнне киләчәген юрый. Нәүрүзгә һәр йортта сәмәнә әзерләнә. Зур подноска куеп шыттырылган солы яки бодай уҗымы ул. Поднос тирәли тәм-том тезелә. Азәрбайҗан тәм-томнары турында да аерым бер сәхифә ачарлык. Иң популяр ризык, әлбәттә, пылау. Ниндиен генә әзерләмиләр: гийме-пылау, сюдлю-пылау, ширин-пылау... Бастурма, гызартма, джиз-быз... Севда тәкъдим иткән чыхыртма шулай ук популяр милли ризыкларның берсе. Кул астындагы ризыклардан тиз генә әзерләнсә дә, бик тәмле була.



Кирәк

- 1 тавык;
- 100 г атланмай;
- 2-3 помидор;
- 1 кызыл, 1 сары баллы борыч (төсләр матурлык өчен генә);
- 2 баш суган;
- ярты чәй кашыгы куркума, шафран;
- тоз-борыч;
- 4-5 данә йомырка;
- укроп, петрушка, кинза, кыяклы суган ише аштәмләткеч үләннәр.












Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Тавыкны юып, порцияле кисәкләргә бүләбез. Тоз һәм куркума сибеп, ышкыйбыз.

■ Коры табада атланмай эретеп, тавык кисәкләрен әйләндерә-әйләндерә кыздырабыз. Суганны тураганчы, табаны капкач белән каплап, итне сүрән утта пешерәбез.

■ Каурый сыман туралган суганны ит өстенә тигезләп салабыз. Болгатмыйбыз, кашык белән җәеп кенә җибәрәбез. Кабат капкачын каплап, пешерүне дәвам итәбез. Тәм өчен бер бал кашыгы лимон суты өстәргә була.

■ 15 минуттан ит өстенә вак шакмаклап туралган помидор һәм баллы борыч салабыз. Яшелчәләр йомшарып китсен өчен капкач белән томалыйбыз.

■ Тирән эчле савытка йомырка сытып, тоз-борыч һәм шафран сибәбез. Шафран мәҗбүри түгел. Йомырканы яхшылап туглыйбыз.

■ Тугланган йомырканы ит өстенә тигезләп агызабыз. Йомырка пешеп җиткәнче капкач белән каплыйбыз.

■ Әзер чыхыртманы зур тәлинкәдә яшел үләннәр өстенә матурлап өеп чыгарабыз. Тирә-юнен помидор, борыч белән бизибез. Өстенә ваклап туралган аштәмләткеч үләннәр сибәбез.

■ Чыхыртма янына таралып торган дөге бирергә була. Үзе генә дә бик тәмле. Йомырка белән помидор тавык итен бик тә сусыл итә.

ДОВГА. Әлеге аш азәрбайҗан кухнясының йөзек кашы санала. Бер бәйрәм табыны да ансыз гына булмый.
Довга мацони нигезендә (аны катык белән алыштырып була) әзерләнә. 1 литр мацонига 1 йомырка, 1 аш кашыгы он, тоз салып, яхшылап туглыйлар да, 1 литр салкын су өстәп, сүрән утка кайнатырга куялар. Бертуктаусыз болгатып торырга кирәк. Мацони өстенә күбекләр чыга башлауга, алдан пешереп куйган дөге һәм ваклап туралган яшел үләннәр (укроп, петрушка, кинза, рәйхан, бөтнек, суган кыягы, кузгалак) өстәлә. Үләннәр төсен үзгәртүгә, ашны сүндерәбез. Довга кайнар килеш тә, суынгач та тәмле.

Кулдан ясалган эшләнмәләр модада хәзер. Хәер, аларның модадан чыкканы да юк. Дөньяда бердәнбер данәдә генә эшләнгән муенсалар, алка, асылмаларның кыйммәте һич югалмый. Шулай булмыйча, останың җан җылысы, күңел матурлыгы, якты хисләре кушылган бит аларга. Остаханәбезгә эпоксид сумаладан матур эшләнмәләр ясаучы останы чакырырга күптән кызыга идек. Андый осталар бар ул, тик серләре белән уртаклашырга теләүчеләре генә аз. Ә менә укучыларыбызга яхшы таныш Эллина КРАСИЛЬНИКОВА белгәннәрен башкаларга җиткерергә бик теләп риза булды. Эпоксид сумала белән эшләү – мавыктыргыч шөгыль. Ул «тыңлаучан», табигый материаллар белән дә яхшы яраша. Мондый эшләнмәләр затлы күренә, чын кыйммәтле ташлар сыман...



«Якут» муенса




Кирәк

• үтә күренмәле эпоксид сумала (интернет аша табарга була, хоббикибетләрдә дә бар);
• тотрыкландыргыч (отвердитель);
• турыпочмаклы шома агач кисәге (озынлыгы – 5 см, киңлеге – 1,5 см, калынлыгы – 1 см);
• эпоксид сумала өчен махсус буяулар (анысын да осталарның үзләреннән алырга була). Безгә яшел һәм ак төсләр кирәк;
• зур булмаган калын полиэтилен элпә (150 микронлы);
• наждак кәгазьләре җыелмасы;
• ялтырата торган абразив паста (аны теш пастасы да алыштыра ала);
• кирәкмәгән кечкенә савытлар;
• перчатка;
• үлчәү.



Эш барышы

■ Агач кисәген полиэтилен элпә белән урап, сумала агызыр өчен «савыт» әзерлибез. Полиэтиленның



агачны төргән очын сумала агып чыкмаслык итеп бөклибез, икенче очы ачык кала. «Савыт» таралып китмәсен – скотч белән ябыштырабыз.

■ Кечкенә стаканны үлчәүгә куеп, авырлыгын билгелибез. Үлчәүдә торган килеш савытка 10 г сумала һәм 7 г тотрыкландыргыч агызабыз. Кулга перчатка киеп эшлибез.

■ Сумаланы агач таякчык белән яхшылап болгатабыз. Тиешенчә катышсын өчен, икенче бер стаканга агызабыз. Югыйсә сумала катмаячак.

■ Әзер сумаланы ике стаканга бүләбез: берсенә – күбрәк, икенчесенә бик аз гына кирәк. Күбрәгенә таяк очына гына эләктереп яшел буяу кушабыз (таяк очын буяуга манып кына алып). Азлысына 2-3 тамчы ак буяу тамызабыз. Һәрберсен агач таяк белән яхшылап бутыйбыз.

■ Яшел буяулы сумаланы полиэтиленга төрелгән агач өстенә агызабыз. Аумасын өчен берәр савытка бастырып, сумаланың ныгып киткәнен 15 минут чамасы көтәбез.

■ Сумала бал кебек куергач, өстән бер тамчы ак буяу тамызабыз. Ак буяу яшел сумала эчендә матур рәвешкә кереп таралсын өчен, аны башы кисәү кебек бөгелгән нечкә тимерчыбык белән болгатып җибәрәбез.

■ Эшләнмә бер тәүлек буе кибә. Кайчак озаграк та вакыт кирәк. Ныклап кипкән сумаланы полиэтиленнан аралап, шомартабыз. Форманы шлифоваль машина ярдәмендә бирүе җайлырак та, тизрәк тә. Ул булмаса, тупас наждак кәгазе ярдәмгә килә.

■ Наждак кәгазе шлифоваль машинадан соң да кирәк. Иң элек җыелмадагы 220 ле кытыршы кәгазь белән шомартабыз, аннары – 400 лесе, аннары 600 лесе кулланыла. Анысын һәм соңгыларын кулланганда кәгазьне су белән юешләргә кирәк. Эшләнмәне сумала тузаныннан арындыру өчен бу.

■ Иң ахыргы этап: вискоза тастымалга ялтыраткыч абразив паста тамызып (ул автомобиль кибетләрендә сатыла), эшләнмәне яхшылап ялтыратабыз. Андый паста булмаса, теш пастасы кулланып карарга мөмкин. Ләкин эффекты кимрәк булачак.

■ Әзер эшләнмәнең өске ягында нәзек борау белән тишек тишеп, нечкә күн бау яки чылбырга тагабыз. Якут төсле асылма әзер. Ул сезнең бәхет талисманыгыз булсын!


Фото: www.pixabay.com

Күләгә гөле

Бакча – гөлләре, чәчәкләре белән ямьле. Ирек бирсәләр, күбебез бөтен җирне гөлләр белән тутырыр идек, бер генә дә буш урын калдырмас идек. Ләкин, купшы чәчкәләр күзләрне иркәләрлек булсын дисәң, аларның күпчелеген кояшлы урынга утыртырга кирәк. Ә кояш төшми торган күләгәле урыннарны нишләтәсең? Шулай буш калсыннармы? Бакчагызда кояш карамый яки көненә берничә сәгать кенә аның нурында иркәләнә торган урыннарга, бер дә икеләнмичә, хоста дигән гөлләр утыртыгыз. Ышаныгыз, сез аларны бик яратачаксыз.

Хоста – күпьеллык үсемлек. Бер урында егермешәр ел да үсә ала. Салкыннарга бирешми, күләгәле һәм дымлы урыннарны ярата.

Әлеге үсемлекнең сортлары күп. Тәбәнәге, уртачасы, биек булып үсә торганы бар. Яфрак формасы белән дә аерыла алар: бер сорты – түгәрәк яфраклы, икенчесе – очлы... Төсләре дә төрле: куе яшеле бар, зәңгәре, чуар яфраклысы, хәтта ак яфраклы сортлары да чыгарылган. Июль-августта чәчәк атса да, аны, нигездә, чәчәкләре өчен түгел, ә декоратив яфраклары белән хозурлану өчен үстерәләр.

Бу гөлләр уңдырышлы, нейтраль яки бераз гына әче туфракны үз итә. Бакчага яз көне кыраулар беткәч яки көздән утырталар. Көз көне утыртканда вакытны бик сузмагыз, тамырлары ныгып калмаса, кышын өшергә дә мөмкин. Үсемлекне утыртасы оягa 1 литр черемә һәм 1 бал кашыгы комплекслы ашлама салып, мул итеп су сибегез. Туфрак белән күмгәч, төбен вак чуерташ яки агач кайрысы белән мулчәләп куйсаң яхшы. Дымны да саклар, чүп үләннәрен дә тоткарлар. Бер-ике елдан, гөл куагы исәйгәч, чүп үләннәрен үзе үк басып китәчәк әле. Шуңа да, төркемләп утырта кмалсагыз, араларын бик якын итмәгез. Аеруча биек булып үсә торган сортларын. Хоста дым ярата, ләкин тамырлары су җыелып торганны өнәми. Әгәр дә бакчагыз артык дымлы, туфрак тыгыз булса, утыртасы оя төбенә кирпеч ватыклары, эре чуерташлардан дренаж ясап калдырырга кирәк. Купшы яфракларны үстерер өчен үсемлек җитәрлек күләмдә азотка мохтаҗ. Шуңа да аны җәй буена берничә тапкыр азотлы ашламалар белән туендырып тору мөһим. Яфракларның матурлыгын киметмәс өчен, чәчәк атып бетерү белән үсемлекнең чәчәк сабакларын кисәргә кирәк. Кышка әзерләгәндә яфракларын да төптән кисәләр. Куакларны бүлеп утыртырга теләсәгез, моны көз көне эшләү отышлырак.

Хостаның бер үзенчәлеге бар: ул үскән түтәл яз көне буш күренә. Яфраклары соңрак чыкканга, янәшәсенә иртә язда чәчәк атучы лалә, нәркиз, сөмбел гөлләре утыртырга була. Җәен исә чалмабашлар, астильба, лилияләр, бакча яраннары белән дә матур күренә. Биек булып үсүче сортларын аерым гына да утыртырга була, чөнки ул үзе генә дә теләсә кайсы урынны бизәрлек. Хоста «альп таучыкларын», ясалма күл ярларын бизәү өчен дә отышлы. Яр буена утырту өчен биек булып үсми торган сортларын сайларга киңәш итәлә.

Дымлы һәм күләгәле урында үскәнлектән, хосталарга күбесенчә гөмбәчек авыруы һәм лайлачлар зыян китерә. Гөмбәчек авыруыннан махсус фунгицидлар кулланыла. Ә лайлачларны качыру өчен үсемлеккә тәмәке тузаны, горчица порошогы, агач көле яки известь сибеп чыгалар.

Хостаны бакчада гына түгел, өйдә дә үстерергә була. Бу очракта тәбәнәгрәк сортлары кулай. Чүлмәк төбенә дренаж салып калдыру мөһим. Хоста еш күчереп утыртканны яратмый, шуңа да туфракның уңдырышлысын һәм чүлмәкнең дә иркенен сайларга кирәк. Хосталы чүлмәкне кояш нурлары үтәли карамый торган урынга урнаштыралар.

Кучкар. Гел хәрәкәттә булырга туры килер. Күп йөрерсез, күп сөйләшерсез. Мондый ыгы-зыгыга хафаланмагыз, аның файдалы яклары да булачак: язмыш сезне кирәкле кеше белән очраштырыр.

Үгезбозау. Максатыгызга ирешер өчен яхшы чор. Абруегыз артыр, ләкин үзегезгә карата тәнкыйть сүзләрен ишетергә дә әзер булыгыз. Фикерләрегезне ачыктан-ачык белдермәгез, аяк чалулары бар.

Игезәкләр. Айның энергетикасы тотрыклы түгел: хисләр түгелергә тора, күңел купкан... Ай ахырына таба эшләрегез уңайланыр, тынычлап калырсыз. Бу чорда язмышыгызга язган кешене очрату ихтималы зур.

Кысла. Низагка этәрә торган киеренкерәк чор. Үзегезне гел кулда тотарга, килешүләргә барырга туры килер. Яңа планнар кору, катлаулы эшләргә алыну өчен кулай вакыт түгел.

Арыслан. Карьерагыз үсеше белән мәшгуль булырсыз. Язмыш көтелмәгән уңыш һәм керем белән сөендерер. Авыр вакытта ярдәм кулы сузардай яңа танышыгызны очратырсыз.

Сөмбелә. Уңышлы ай. Ләкин кирелегегезне һәм мин-минлегегезне онытып торырга кирәк булыр. Эш белән бәйле берникадәр кыенлыклар килеп чыгуы бар, шуның аркасында планнарга үзгәреш кертергә туры килмәгәе.

Бизмән. Каршылыклы чор. Канәгатьсезлек хисен йөгәндә тотарга туры килер. Тормышны үзгәртергә беркайчан да соң түгел, нәкъ менә шушы айда яңа мөмкинлек чыгарга тора.

Чаян. Күңелле сюрпризлар күп булыр. Бу айда корган элемтәләр аеруча ныклы. Айның энергетикасы сезнең өчен бик тә уңай, катлаулы мәсьәләләрне шушы чорда хәл итеп калырга тырышыгыз.

Укчы. Сәламәтлекне ныграк кайгыртырга туры килер. Ай башында күзәтелгән сүлпәнлек соңга таба активлык белән алышыныр. Яңа эшкә керешү, тормышыгызны үзгәртү мөмкинлеге бар.

Кәҗәмөгез. Тормышыгызның уңай чоры, эшкә бәйле берникадәр проблемалар килеп чыккаласа да, күңелегезне төшерә алмаячак. Элеккеге үпкәләрне онытып, мөнәсәбәтләрне җайлар өчен менә дигән вакыт.

Сукояр. Фатирда ремонт башлау, яңарту, яңа әйберләр сатып алу өчен әйбәт вакыт. Катлаулы проблемаларны да җиңел генә чишү юлларын табарсыз. Низаглардан сакланырга кирәк, үпкәләрнең озакка сузылуы бар.

Балык. Позитив ай. Аралашулар, очрашулар, ерак сәфәрләр чоры. Болар бар да сезне яңа дулкынга – рух күтәренкелегенә, яңа идеяләргә алып кереп китәр. Ләкин акчагызны юкка сарыф итүдән сак булыгыз.

ХАТЫН-КЫЗ НАМУСЫ

Бервакыт казый янына яшь кенә бер ханым килгән. «Мин бер әйберне аңлый алмыйм, – дигән ул. – Ирләр хатыннарына хыянәт итсә, аны шулай тиеш кебек кенә кабул итәләр. Ә хатын-кыз иренә хыянәт итсә, аннан бөтенесе йөз чөерә. Ник шулай ул? Хыянәт – ирнеке, хатынныкы булмый, алар икесе дә бертөсле авыр бит».

Казый ханымны игътибар белән тыңлаган да, алты чәйнек һәм алты чынаяк алып килгән. Бер чәйнектәге чәйне тигез итеп алты чынаякка бүлеп салган. Аннары бер чынаякка алты чәйнекнең чәен агыза башлаган. Чынаяк бик тиз тулып ташыган. «Күрдеңме инде аерманы, – дигән казый. Бер чәйнектән алты чынаякка чәй агызырга була, ә бер чынаякка алты чәйнекнең чәен сыйдыру мөмкин түгел. Алты чәйнекнең чәен сыйдыра торган чынаяктан берәүнең дә чәй эчәсе килмәс иде».

* * *

Бәхет тугрылыкка мохтаҗ, ә бәхетсез булу өчен тугрылык саклау кирәкми.

Луций Сенека (Рим философы, шагыйрь)

Ир-ат өчен тугрылык саклау – юлбарысны читлеккә япкан кебек. Ул аның табигатенә үк ят.

Бернард Шоу (Британия драматургы, Нобель премиясе лауреаты)

Хатыныгызның хыянәт итүе ул әле сезгә бәхетегезнең хыянәте түгел.

Эдуард Севрус (рус язучысы)

Хыянәтче хатын – кагылырга да чиркангыч зур һәм салкын кәтлит кебек. Аны инде кемдер үз кулында туйганчы әвәләгән.

Антон Чехов (рус язучысы)

Мәхәббәтенә карата хыянәт кичергән хатын-кыз йөрәге яулап алып тар-мар ителгән салкын һәм буш кирмәнне хәтерләтә.

Вашингтон Ирвинг (Америка язучысы)

Кешеләр еш кына шөһрәт казану хакына мәхәббәтләренә хыянәт итәләр, ләкин мәхәббәте хакына даннарына хыянәт итүчеләр юк.

Франсуа VI де Ларошфуко (француз язучысы)

Ир-атның көче аның ничә хатын белән булганына карап түгел, ә бер хатын-кыз хакына ничәсеннән баш тарта алганына карап үлчәнә.

Фредерик Бегбедер (француз язучысы, әдәби тәнкыйтьче)

Салкын хатынның ире читтә җылына.


Александр Минченков (Россия футболчысы)

зирәк кешедән – нәрсә сүз

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА








МИЛЛИ МОҢ

Аның әсәрләрен күрүгә, «иртәгә кыямәт көне дисәләр дә, кулыңда агач үсентесе булса, аны утырт» дигән хәдис искә төшә. Татар шәмаиле галереясындагы күргәзмәсе дә юкка гына «Җир бакчалары» дип аталмаган. Картиналарындагы төп төс бар тирә-юньне яшеллеккә төрә, һәм һәркайсының композиция үзәген Хәят агачы символы тәшкил итә.

Татарстанның халык рәссамы Мөдәррис Минһаҗев татар орнаментларына булган игътибарын, үзгә бер мөнәсәбәтен тагын да арттырган. Ул киләчәктә аларны искиткеч сыгылмалыктагы гарәп язмалары белән ешрак берләштерә барачагын да искәртте. Арчада, Түбән Камада, Лениногорскида диварлары татар милли бизәкләре белән бизәлгән белем йортлары һәм башка төр биналар саны берничә дистәгә җитә. Һәм алардан рәссамның кул, күңел җылысын тоясың. Ул гомере буе милли бизәкләрне популярлаштыра. Киндергә майлы буяулар белән язылып, картина-орнаментлардан торган «Төсләрдә милли хисләр» шәхси күргәзмәсе Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә ачылып, никадәр тамашачыны сокландырды! «Әсәрләрегезгә карагач, колакка ниндидер илаһи моң ишетелә!» – дип тәэсирләнделәр, «Картиналарыгызны күргәч, уйлар яктырып китте!» – дип сокландылар. Ул рәссам-шагыйрь икән ләбаса! Мөдәррис Мөхетдин улы яттан шигырьләр сөйләргә, матур җырлар көйләргә ярата; аңлашыла ки, һәрчак күңел күтәренкелегенә ия булган ихлас зат кына яшәеш белән бәйле төс-төсмерле, якты-гамьле бизәкләр байлыгын иҗат итә ала. Билгеле, аның портрет һәм пейзаж жанрындагы хезмәтләре дә бар, авыл көнкүреше, милли зәркән бизәнү әйберләре, тарихи экспонатлар белән бәйле натюрмортлары да байтак. Тырышлыгы да нәсел-нәсәбе белән бәйле. Җиң сызганып эшләүче уңган-булган сабаларның, шәмәрдәннәрнең бер улы ул! Үз туган ягын өзелеп яратканга күрә Саба якларында берничә күргәзмәсен дә ачкан. «Җир бакчалары» экспозициясе исә Татар шәмаиле галереясында зур уңыш казанды. Рәссам эшчәнлеге иҗат белән генә чикләнми, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе урынбасары булараk, күп вакыт таләп итүче киң колачлы эшләрдә дә дә кайнап яши ул. Орнаментлар телен агымсу елга образы белән бәйләгән әсәрләрендәгечә, бу тынгысыз җанның иртәгәсе иҗат юлы да киңрәк, иркенрәк булуын телисе килә! Тирән эчтәлекле образларга, символларга бай картиналары киләчәктә күп мәртәбәләр нәшер ителеп, милли рух, затлы зәвык тәрбияләүче уку әсбапларына да кертелер, әлбәттә. Алар этник моданы алга этәрүче татар дизайнерлары өчен дә әйтеп бетергесез табыш!

Психологлар кәефе төшенке кешеләргә телләр өйрәнергә, шоколад ашарга, классик музыка тыңларга, Кояш белән дуслашырга киңәш итә. Ә без ул киңәшләргә тагын берне өстәр идек: талантлы рәссам Мөдәррис Минһаҗевның шушы бәйрәмчә рухтагы карап туйгысыз картина-орнаментларына күз төшереп, кәефегезне күтәрегез. Шундук күңелләрегезне яулар! Чөнки аларны ягымлы-якты, шат күңелле, позитив рәссам иҗат иткән, димәк, энергетика ягыннан барысы да уңай.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









МӨДӘРРИС МИНҺАҖЕВ







«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

1 апрельдән 2019 елның икенче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА